# ЗИНДАН

Бүген, 27 нче гыйнварда, 1907 нче елда, Чистай төрмәсеннән иптәшемез Гариф әфәнде Бадамшин чыгарылып җибәрелгәнгә, камерамыз иркенрәк калды да, мин язарга тотындым. Моңынча һичбер язарга-нитәргә мөмкин түгел иде. Урынымыз бик тыгыз иде, күңел бер дә тыныч түгел иде. Хәзер инде минем төрмәдә шактый гына торачагым мәгълүм булганга, эшкә тотынмакчы булам. Казанда иреккә чыгарылганнан бирле өч ай вакыт үтсә дә, төрле сәбәпләрдән моңынча кулыма каләм алып язуга тотына алганым юк иде.

Бүгенге көннән башлап үземнең төрмәдәге тормышны, төрмәдәге хиссиятемне язмакчы булам. Үземнең күргәннәремне, уйлаганнарымны укучыларның күз алларына китермәкче булам. Җитәр! Мин тотындым.

1906 нчы елны 29 нчы октябрьдә университетта карагруһлардан бер студентның рефераты (бер нәрсә хакында үзенең фикерен сөйләве) булачак иде. Ул көнне минем бәгъзе эшләрем булганга, мин рефератка соң гына килдем. Сәгать 11 ләрдә рефератны бетереп чыкканда иптәшләрем Сәгыйть әфәнде, Исхак әфәндегә очрап, алар берлән очсызлы чәйханәдә чәй эчәргә уйладык. Балык базарын бөтенләй йөреп берәр сәгать вакытымызны әрәм иткәннән соң, очсыз чәйханә таба алмавымызга ышанып, «Москва» гостиницасына киттек. Чәй бик очсыз булмаса да, бик кәефле булды. Сәгыйть әфәнде үзенең кыргыз сахраларында гомер үткәрүләрен бик кызып-кызып сөйләп, чәйнең ямен тагы арттырды. Мин дә гәзитәмез өчен шактый гына акча тапканымны вә шактый гына акча кесәдәлеген белдереп, иптәшләрне шатландырдым. Чәй янында кая куначак мәсьәләм дә хәл кылынды. Шул арада гына Казанда усиленная охрана игълан кылынганга, фатир мәсьәләсе минем өчен бик әһәмиятле мәсьәлә иде. Чөнки мин, 1905 нче елның 13 нче декабрьдән бирле (нелегальный) качып йөргәнгә, паспортсыз тота торган фатирларда гына тора ала идем. Усиленная охрана паспортсыз тотучыларны бик зур штрафлар берлән куркытканга, мин дә шул арада гына өй хуҗаларының бик каты паспорт сораулары өчен фатирымны ташларга мәҗбүр булган идем. Шунын

өчен шул арада әле анда, әле монда кунып йөреп, көндезләрен Сәгыйть әфәнде фатирында мәкаләләр язып үткәрә идем. Унбер айга якын качып йөрү, туктамаенча эшләү мине шактый гына арытканга, шул арада берәр айга күрше шәһәрләрдән берсенә китеп бераз хәл җыячак идем. Шуның өчен мин фатир эзләми дә идем, кирәксенми дә идем. Бу көнге көн өчен мин Сәгыйть әфәнделәрдә куначак булдым. Ләкин аларның хуҗалары бик кабахәт карагруһ тарафдары булганга, ничек булса да аңарга белдермәенчә керергә кирәк иде. Шуның өчен без сәгать икенче яртыга кадәр гостиницада утырырга вә хуҗа яткач кына кайтырга карар бирдек.

Вакыт җиткәч, кайтырга чыктык. Чәй пары берлән сөйләшә-сөйләшә кайтып җитүемезне сизми дә калдык. Йортка җитәр алдыннан полиция юкмылыгын карап ишек алдына кердек. Ләкин өчемез берьюлы фатирымызга керсәк, хуҗа белеп, хәзер зур тавыш чыгарачагында яисә полиция чакырачагында һич шөбһә юк иде. Шуның өчен иң әүвәл Исхак әфәнде звонок биреп керергә, хуҗаларга, кайтсалар, үзем ачармын дип әйтеп, тышка чыгарга вә шул вакытта без керергә план кордык, һәм ун-унбиш минуттан шул хәйлә берлән өйгә дә кердек. Без бераз сөйләшкәннән соң, иртәгәге гәзитәгә мәкаләләр хәзерлеклеген белгәннән соң, һәммәмез — кайсымыз гәзитә алып, кайсымыз китап алып урыннарга яттык. Мин, кунак булганга, кәнәфигә яттым. Гадәтемчә бераз гәзитә укып ятканның соңында, утны сүндереп, йокыга киттем. Төшемдә ниләр күргәнем хәтеремдә юк. Ләкин мин уянганда, баскычтан җелтер-җелтер кылыч тавышы чыгарып, полиция кешеләре берлән борынсыз хуҗа кечкенә генә лампа күтәреп менеп киләләр иде. Бу тавышка һәм дә бу ут яктысында иптәшләрем икесе дә сикереп тордылар.

Пристав, Сәгыйть әфәндегә карап: «Сезнең фатирыңызда тентү ясарга әмер булды!» — дип, тентү ясарга тотынды. Борынсыз хуҗа, мине күргәч, әллә ниләр кылынып сүгешергә тотынды. Приставка: «Миндә гаеп юк, мин ике кешегә генә бирдем», — дип, үзен йоларга юл хәзерли башлады. Тентү башланды. Мин йоклаган булып ята идем.

Сәгыйть әфәнденең фатиры безнең редакциямез хисаплanganга,

гәзитәләрнең, хатларның, мәкаләләрнең исәбе-хисабы юк иде. Шуның өчен тентү бик озак дәвам итәчәк иде. Приставның аруыннан һәм дә язуларның барысы да татарча булуыннан безнең мәкаләләрне, хатларны барысын да калдырырга булдылар. Пристав янындагы татар городовое һәр язуны әйләндереп-әйләндереп карый иде дә, берсен дә аңламагач, бер сүз дә танымагач: «Статья, ваше благородие», — дип читкә ташлый иде. Сәгать ярымнар вакыт үткәннән соң, тентү бетте. Пристав протокол язарга тотынды. Минем хакымда Сәгыйть әфәнде: ул иптәшемез, кичә театрдан кайтырга ерак булганга, монда кунды, дип җавап бирде, пристав, шул сүзгә канәгатьләнеп, мине борчымаска булды. Ләкин татар городовое үзенең егетлеген һәм дә тугры хезмәт итүен күрсәтер өчен мине уятып сорауны мәслихәт күрде. Пристав иренеп кенә: «Уят алай булса!» — дип әмер итте, городовой мине уята башлады. Мин, бераз уянмаган булып торганнан соң, күзләремне ачар-ачмас торып утырып, бик гаҗәпсенгән кебек, бер дә курыкмаган кыяфәт берлән сөйләргә тотындым. Мин хәзер мине алып китәчәкләренә тәмам ышанганга, бик акрын гына торып киенә башладым. Пристав, приставтан битәр өй хуҗасы, минем кемлегем хакында бик күп сөальләр бирә башладылар. Мин, бер дә исе «итмәгән кеше кебек, «фәлән урамда торам» дип ялганладым. Минем әйберләремне карарга тотындылар. Миннән бернәрсә дә чыкмады. Протокол яза башлагач, мин үземнең фамилиямне яшерүдә хәзер файда юклыгын белгәнгә, мине илтәчәк икенче часть полициясе барысы да мине таныганга, мин үз фамилиямне әйттем. Иптәшләр теләр-теләмәс минем күземә карадылар. Алар да минем өчен котылырга юл юклыгын белгән кебек күренделәр. Ләкин пристав яңы кеше булганга, мине, алай да, таный алмады. Протокол беткәннең соңында мин полициягә бармаска теләп әллә никадәр тартыштым.

Шулай булса да барырга мәҗбүр булдым. Кесәмдәге кичәге акчаны Исхак әфәндегә калдырып, Сәгыйть әфәнде берлән бергә полициягә киттек. Полициягә минем керүем бөтен полицияне гаҗәпкә калдырды. Алар үзләренең 11 ай эзләгән кешеләренең аяк астыннан чыгуына исләре китте. Мине бик тиз

төрмәгә җибәрергә дә вәгъдә кылып, полициянең исерекләр яба торган бүлмәсенә кертеп яптылар. Озакламаенча мине тагы чакырып, сорашып, әллә кемнәр берлән телефоннар берлән сөйләшергә тотындылар. Мин шунда безне тентегән городовойдан сорап тышка чыктым. Бәдрәфкә керү берлән исем китте. Бәдрәфнең тәрәзәсе бөтенләй ап-ачык. Тагы, өстенә, мине чыгарган стражник та тышта калды. Минем күңелемә кылт итеп качу фикере төште. Мин хәзер качарга план кора башладым. Ләкин полиция йортыннан чыккач Болакка таба китәргәме, әллә Мокрыйга таба китәргәмелеген хәл кыла алмадым. Ахырдан, Мокрыйга китәргә уйлап, качарга ниятләп, тәрәзә янына килдем. Тәрәзә аша атлыйм дигән вакытта ишек ачып стражник керде. Мин чалбарларымны рәтләгән булып, стражник алдында тагы бераз торып, политсэгә кердем. Сәгыйть әфәндене минем яныма кертмәделәр. Мин тагы приставны күреп, тизрәк төрмәгә озатсаңыз ла дип, тагы үземнең бүлмәмә кердем.

Кич берлән кояш баеганда мине тагы чакырдылар. Керсәм, Сәгыйть әфәнде дә анда икән. Безне икемезне дә җибәрәмез диделәр. Озакламады, ике городовой безне озата киттеләр. Без, иртәдән бирле бер дә ашамаган булганга, юлда кондитерскига керергә сорадык. Городовойларның рәтләп җавапларын да көтмәенчә, кондитерскига кердек. Артымыздан килә торган бер городовой бик кабахәт булганга, бик ачуланып ашыктыра башладылар. Без тиз генә аннан-моннан әйберләр алып ашарга тотындык, һәм тиз генә кондитерчыга акча бирдек. Минем кесәмдә биш сумнан башка акча булмаганга, мин биш тәнкәлек кәгазь бирдем. Кондитердагы алучылар, сатучылар һәммәсе дә полицәләр берлән кергән кешеләр күргәч үк бераз гаҗәпсенгәннәр иде. Шуның өстенә городовой сүгенә башлаганга, болар бөтенләй курка башладылар. «Зинһар чыгыңыз», — дип ялына башладылар. Минем акчамны кайтарып торырга шактый вакыт китәчәк булганга, полицейский сүккән саен сүгүе куәтләнә барганга, болар акчаны алмый башладылар. Безнең: «Алыңыз!» — дигән сүзгә дә карамаенча, «Тизрәк чыгыңыз!» — дип үтенә башладылар. Без чыгып киттек. Городовойның ачуы тиз басылмады. Ул

беренче частька барып җиткәнче сүгенә-сүгенә барды. Шуны да әйтергә онытткан икәнмен. Көн бик ямьсез иде. Бик каты җилле буран ява иде. Бураны әллә нинди йепшекле булганга, бөтен битләргә, башка, күзгә сылана иде. Кибетләрнең вывескалары, өйләрнең трубалары җил берлән әллә нинди ямьсез тавышлар чыгаралар иде. Без һаман элгәрегечә көлешә-көлешә, кондитердан алган әйберләремезне ашый-ашый бара идек. Бу начар городовой җилне, очраган кешеләрне, безне бертуктамаенча сүгеп килә иде. Безне сүгү туйдырган булырга кирәк  ахырга таба иптәшен сүгә башлады. Аннан да арыгач, беркемгә дә багышламаенча, үзенең белгән һәммә кабахәт сүзләрен тәкрар кыла башлады. Озак та үтмәде, без беренче частька кердек.

Надзиратель, бик зур эш эшләгән кеше кебек, безнең кәгазьләрне кул куеп алды. Икенче кәгазь язылганчы һәм дә төрле җирдән килгән кешеләрне кабул итеп алгалаганчы шактый гына вакыт үтте. Без икәү кәнәфигә утырып көтеп тора башладык. Безнең кәнәфидән эчке бүлмә күренеп тора иде. Бүлмәдә бик күп шкафлар тезелгән иде. Шкафлар янында чүмәлә-чүмәлә өеп куйган гәзитәләр тора иде. Бу гәзитәләр әллә ничә өемгә өелсә дә, «Волж. вестникъ» гәзитәсе барысыннан да күп иде. Бу гәзитәләрне язучылар, басучылар халык укысын, халык файда итсен дип хезмәтләрен сарыф кылсаларда, безнең полициямез мондый гәзитәләрне укуны «сайе пәнаһид әсаеш бәр кәмая» булуына зарарлы табып, боларны типографиядән чыкмас борын ук җыеп алганнар иде.

15—20 минутта төрле частьтан әллә никадәр кешеләр китерделәр. Городовойлар, килгән кешеләр һәммәсе карга буялып, битләре, сакаллары бәсләнеп керәләр иде. Городовойлар барысы да бер-берсе берлә күрешеп, барысы да җилне, һаваны сүгәләр иде, барысы да әллә нидән риза түгелләр кебек күренәләр иде. Надзиратель акыртын гына, иренеп кенә, сүз саен ъ кирәкме, Е кирәкмене уйлап кына, килгәннәрне кергән кенәгәсенә, киткәннәрне чыккан кенәгәсенә яза иде. Мондагы кешеләрнең бездән һәм тагы, өч-дүрт китерелгән кешедән башкалары һәммәсе кара киемнәр киенгән, кылычлар таккан, бер тирес сүз ычкындырсаң, сугарга кулын күтәрә торган,

кылычсыз кешене күрү берлән авызыннан тәсбих кебек бертуктамаенча сүгү сүзләрен коеп тора торган Россиядә «әсаеш бәр кәмалны» саклаучылар иде.

Болар үзләренең таза йодрыклары, каты куллары берлә, кылычларының кыннары, револьверның тоткалары берлән 17 нче октябрь манифестында вәгъдә кылынган граждански праваларны тутыручылар, Россиянең һәр гражданинының хөррияте шәхсиясен, гражданнарның каннарын, малларын, җаннарын айамаенча мөхафәзә кылучылар иде.

Боларның кыланышлары, боларның йөрешләре миңа Испаниядәге инквизиция мәхкәмәләрен хәтеремә төшерде. Мондагы һәр нәрсәдән әллә нинди золым исе тоелган кебек, яшь тавышы ишетелгән кебек иде. Мондагы һәрнәрсә бюрократия золымының әллә ничә елгы шаһиде булганга, бюрократия золымының, вөҗдансызлыгының кораллары булганга, болар һәммәсе миңа җирәнгеч, сасы, кабахәт кебек күренәләр иде. Мондагы кешеләрдә хәйванният хисеннән башка бернәрсә булмаган кебек, мондагы әйберләрдә дә матурлык-фәлән кебек ңәрсә юк иде, Боларның әйберләре һәммәсе дә тупас, җансыз, рухсыз күренәләр иде.

Озакламады, безне беренче часть янындагы арестныйга озаттылар. Безне тагы городовойлар, тагы шул мылтыклар, кылычлар таккан зобанилар каршы алдылар. Безнең пакетны кабул итеп алыр өчен старшийның «үзен» чакырдылар. Старший «үзе» тәбәнәк кенә, кечкенә генә башлы, дөньяда ашау-эчүдән башканы белми торган, үзенең шылтыравыкларын бик зур дәрәҗәгә куя торган бер Ярты гакыл иде —безне кая ябу хосусында сүзләр киткәч, арттан бер хатын: «Еврей малае янына ябыңыз!» — дип әмер итте. Мин әйләнеп карасам, старший артында шадра гына, ямьсез генә бер хатын күрдем. Бу хатын үзенең күз карашлары, сүзләре, тавышлары берлән фахешханәләр экономкасы төсле иде. Мин моңар карау берлән күңелемнән бу хатынга бер дошманлык хисен итә башладым. Бу хатын безне тентегәндә дә әмерләр биреп торганга, моның старший хатыны гына түгел, үзе старший икәнлеген, теге старший дигән әтәч төсле Ярты гакыл моның ире булган булып торганга, старший дип йөрүләрен аңладым. Безне ни өчен китерделәр дип сорый

башладылар. Мин: Россиядә торганлыгымыз өчен һәм дә башка кешеләр кебек кеше талап йөрмәгәнемез өчен, дигәч, Ярты гакылның кыяфәтләре үзгәреп китте. Аның бите пешкән шалкан кебек булып җыерчыклана башлады.

Авызыннан әллә нинди әмиранә сүзләр чыга башлады. Озакламады, старшийның ачуы басылды. Безне тентеп, акчаларымызны алып, бер бүлмәгә кертеп яптылар. Бүлмәдә без кергәндә яшь кенә бер егет кечкенә генә самавыр берлән чәй эчеп утыра иде.

Бу яшь егетнең баягы старший хатыны әйткән еврей малае идеке хәзер хәтеремә төште.

Ишек ачып җибәрү берлән борынга әллә нинди, авылларда бәрәннәр өендә була торган әчеле-төчеле искә катышкан параша исе борынга килеп керде. Теләр-теләмәс мин камераны карый башладым. Озынлыгы өч сажин чамасында, киңлеге биш аршиннар чамасында, биек кенә бер тәрәзәле бүлмә иде. Тәрәзә янында бер стенадан икенче стенага җиткән биек кенә сәке беркетелгән иде. Сәке өстеннән тәрәзә төбе дә бик якын иде. Тәрәзә шактый гына зур булганга, бүлмә көндезләрен караңгы булачак түгел иде.

Ләкин без кергәндә кич булганга күрә, бүлмә яктыртыр өчен куелган түшәмдәге электрик лампасы гына тычкан уты төсле үзенең барлы-юклы утын тирә-якка сача иде. Лампаның пыяласы әллә нишләп эреп беткәнгәме, әллә лампаның тирәсенә үрмәкүчләр матурлап-матурлап оя ясагангамы, лампа караңгы бүлмәдә бер түшәмгә асылган утлы күмер генә кебек күренеп тора иде.

Без кереп теге еврей егете берлән күрешеп сөйләшә башладык. Һәм дә шундагы коридорщикка берникадәр әйберләр алырга кушып, егерме тиен бирү вәгъдәсе берлән самавыр сорадык. Самавыр килгәнчә һәм дә кибеттән кайтканча безнең янымызга тагы бер кеше керттеләр. Бу кеше элгәредә төрмәдә надзиратель булып торган икән, шул вакытта сәясиләрнең хатларын йөрткәнлеге беленеп, төрмәдән куылган һәм дә хәзер эше судка бирелгән икән!

Без дүртәү чәй эчәргә торганда күрше бүлмәдән татарча: «Гаяз, Гаяз!» — дигән сүз ишетелә башлады. Мин бик тиз барып сөйләшергә тотындым,

ләкин сүз рәтләп ишетелми иде. Ул арада мин: «Сез кем?» — дип сорый башладым «Хөсәен!» — дигән сүз ишетелде. Мин тагы: «Нинди Хөсәен?» — дип сорадым. «Хөсәен Ямаш», — дип җавап бирделәр. Минем исем китте. «Ничек Хөсәен тотылды икән? Кайчан тотылды икән? Кая тотылды икән?» — дип уйлый башладым. Озак үтмәде, ишекнең тишегеннән бер кеше килеп сөйли башлады. Карасам, ул минем школада бергә укыган бер танышым икән. Мин: «Хәзер сезнең берлә Хөсәен бармыни дип сорадым», — дидем. Алар: «Юк. Без сезнең берегез Хөсәенме әллә дип сорадык», — диделәр. Мин иптәшем Сәгыйть әфәнделеген әйтеп, баягы Хөсәен Ямаш дигән сүзләрнең сүз аңланмаудан килгән бер ялгышлык кына идекен белдем. Яңы танышлар берлә сөйләштек. Алар шунда бер әллә нинди уголовный эш берлә кергәннәр икән.

Озак үтмәде, самавыр китерелде. Без дүртәү кайнар самавыр янында утырып, чәй эчә-эчә сөйләшә башладык, безнең күңелләр тагы ачылды. Кичәдән бирле эчмәгәнгә күрә, чәй бик урынына төште. Чәй янындагы алмалар, сырлар, булкилар берсе артыннан берсе безнең эскәтердән югала башлады. Бүлмәнең сасылыгына, бүлмәнең караңгылыгына өйрәнә башладык. Ләкин Сәгыйть әфәнде тәмәкесезлеккә һич чыдый алмый иде. Озакламады, баягы М. әфәнде Сәгыйтькә папирослар китереп биреп, аның да тулмаган дөньясын тутырды.

Озак үтмәде, Сәгыйть әфәндене полисмейстерга чакырып киттеләр. Бераздан ул кайтып: «Мине Казаннан җибәрәләр, егерме дүрт сәгать эчендә Казаннан китәргә дип кул куйдырып, бүген чыгарамыз диделәр. Ләкин судебныйдагы гәзитә эше өчен Казаннан чыкмаска кул алганнар иде, һәм дә судебный палатада беренче ноябрьдә эшнең каралырга тәгаен кылынуы эшне бозды», — дип, үзенең судебный палатадан килгән язуын күтәреп кайтып керде. Гаеп язуын укыгач, ничек итәргә, кемнәрне шаһидлеккә чакыртырга уйлап торганда, тагы Сәгыйть әфәндене чакырдылар. Берәр сәгатьтән соң Сәгыйть әфәнде яңыдан килеп, ишек тишеге аша гына: «Мине Казанда да калдырдылар, бөтенләй дә чыгаралар», — дип күрешеп китте.

Мин ялгыз калдым. Мине, ялгыз калгач, кайгыргандыр-фәләндер дип

уйламаңыз! Һич юк! Сәгыйтьнең чыгуына минем шатлануым үземнең монда калуымны бөтенләй оныттырды. Чөнки Сәгыйть «Таң»ның редакторы булганга, ул ябылу берлән гәзитә туктала иде. Ул чыккач гәзитә, сонга калса да, чыгачак иде. Мин Сәгыйтькә: «Гәзитәне туктата күрмәңез», —дип күрешеп калдым. Мин инде хәзер үземнең бүген үк, йә иртәгә төрмәгә җибәрелүемне көтә башладым. Иптәшләр берлән сөйләшеп шактый вакыт үткәннән соң, мин тишенмәенчә генә сәкегә менеп яттым. Бу көнгә минем мендәрләрем, юрганнарым булмаганга, минем өстемдәге пәлтәм, теге экияттәге кешенең капчыгы кебек, мендәр дә булачак, юрган да булачак, пәлтә дә булачак иде.

Күпме йоклаганны белмим, безне уяттылар. Ишекне ачып, безгә әллә нинди кешеләрнең әйберләрен ташый башладылар. Озак та үтмәде, безнең бүлмәгә баягы минем танышларым килеп керделәр. Аларның әйтүенә караганда, әллә нинди бер барышняны китергәннәр икән дә, аңарга урын булмагач, боларны безгә кертәләр икән.

Безнең бүлмә тагы җанланды. Килгән алты кеше урыннар җәя башладылар. Минем танышларым, минем әйберләрем юкны күреп, мине уртага яткырдылар. Озак үтмәде, безнең күрше бүлмәдә бер кеше бик каты басып маршавайт итә башлады. Без, аның кем икәнлеген белергә теләп, стена сугып сөйләшмәкче булдык. Ләкин ул аны аңламады, ахырдан без ярыктан кычкыра башладык. Ул ишетте. Ул бүген сәгать 11 ләрдә генә тотылган бер кыз булды. Фамилиясен дә әйтте. Мин бу безнең таныш түгелме дип уйласам да, үз танышларымның бик азының гына фамилиясен белгәнгә, фамилиясеннән кем идекен белә алмадым. Без тагы бераз сөйләшеп, ятып йокыга киттек.

Тыгызда «әлиф ятып» сасы бүлмәдә, әлбәттә, йокы бик шәп булмады. Алай да иртә торганда мин бик исән булып уяндым. Тышка чыкканда мин күршемнең ишек тишегеннән карадым. Карасам — минем шактый якын танышларымнан А. исемле бер кыз икән. Ул да мине күреп гаҗәпкә калды. Тиз генә без үземезнең хәлләремезне сөйләштек. Мин үземезнең бүлмәгә кереп, теге кызның кемлеген сөйләдем.

Безнең бүлмәнең кешеләре арасында ливалвир өчен ике атна ятарга ясалган бер студент һәм дә ливалвир өчен өч ай ятарга ясалган бер эшче, һәм дә ливалвир өчен өч атна ятарга ясалган бер хәреф җыючы татар егете бар иде. Боларга башкалары искеләр һәм дә өч минем танышларым иде. Без барымыз бергә бик һәйбәтләп чәй эчәргә утырдык. Бик озаклап чәй эчтек. Чәйдән соң тышка чыкканда теге кыз миңа укырга бернәрсә дә юк дип зарланды. Мин, бездә гәзитәләр бар, дип, бирергә вәгъдә кылдым. Һәм шул минутта ук ике гәзитә чыгарып тоттырдым. Бер-ике минут вакыт үтмәде, әлеге старший дигән этәч кебек Ярты гакыл кереп, бу гәзитәләрне кайдан алдың, дип сорый башлады. Ул гәзитәләрнең берсе студентныкы, берсе төрмәдә надзиратель булып торган кешенеке булса да, мин аларга авырлык булмасын дип: «Белмим, без кергәндә шунда иде», — дидем. Теге шул сүзгә канәгатьләнгән булып чыгып китте, тагы бер биш минут та вакыт үтмәде, тагы кереп: «Каян алдың?..» — дип, миннән сорый башлады. Мин тагы шул җавапны бирдем. Теге миңа этәчләнергә тели башлагач, мин дә каты-каты сүзләр берләп җавап бирә башладым. Теге тагы ачуланды. Үзенең зобаниларын чакырып, мине ялгыз бүлмәгә күчерергә кушты. Мин ялгыз бүлмәне барып карагач, аның караңгы бүлмә икәнлеген күреп, монда кермим дип тартышырга тотындым. Ләкин минем сүземә карамаенча, мине илтеп яптылар. Мин барганда старшийга: «Мин сине өйрәтермен. Мин синең бу кабахәтлегеңне бөтен гәзитәләрдә язармын!» — дигәч, старший бераз каушады, тагы бер биш минуттан мине элгәреге танышларым янына китерде. Руслар мине: «В борьбе обретешь ты право свое!» — «Тартышуда гына табарсың син үзеңнең хакыңны!» — дип каршы алдылар. Ун-унбиш минуттан соң тагы старший килеп, мине баягы бүлмәгә итеп япты. Бу бүлмә элгәреге бүлмәгә караганда шактый гына кечкенә булса да, кечкенәлегенә риза булмаслык түгел иде. Моның миче якмаган булганга, бу бик салкын иде. Тагы бу бүлмә — һәрвакыт ягар-якмас торган булырга кирәк — бик юеш иде. Моның стеналарыннан тамчылар тамып торган кебек, түшәмнең буявы да, юешлектән кубып, бертуктамаенча кар яуган кебек явып тора иде. Сәкесе булмаганга, тәрәзәсе

бик биек иде; үзе бер генә кат булганга, бертуктамаенча суык агып тора иде. Тәрәзәсендә тимер решетка булса да, ни өчендер бик юан агачтан ясаган агач решетка да куйганнар иде. Бу агач решетканың буш йерләре бик аз булганга, бүлмә бик караңгы иде. Тәрәзәнең тәмам янына килеп тә язу укырлык түгел иде. Моннан элгәре дә тимер караватт булып йөргән, хәзер дә, аяклары сынганга, талчуктан башкага ярамый торган, ике аягы урынына утын пүләннәре куйган бер караваттан башка бернәрсә дә юк иде. Бу караватның да матрацы-фәләне кебек нәрсә һич юк иде. Үзеңнең матрацларың-фәләннәрең булса да, аяклары юкка ятарга мөмкин булмаячак булганга, әлбәттә, бу тимер кисәкләренә миңа да ятарга мөмкин түгел иде. Шуның өчен теләр-теләмәс идәнгә ятарга тиеш идем. Тагы бу караватка башка ишек янында гына параша бар иде. Төрмәдә полициядә ятуның күңелне иң җәрәхәтли торган, кешенең хөббе нәфсен иң мыскыл итә торган нәрсә шул парашадыр. Бу параша шәһәрләрнең мунчаларындагы кебек бер шайка (агач савыт, кечкенә лакан) дыр. Шул шайканы кояш баю берлән шунда ятучыларга тышка чыгарга дип кертеп куялар. Яткан кешеләргә чыгарга мөмкин булмагач, әлбәттә, шунда эшләрен бетерәләр. Шуның өчен, бу параша әллә ничә вакытлардан бирле шундый кабахәт нәрсәләр берлән тулып торганга, моның һәммә йереннән әллә нинди әчеле-төчеле, төрмәгә кереп иснәмәгән кеше күңеленә китерә алмаслык кабахәт исләр чыгып торадыр.

Шуның өчен кертеп кую берлән бик тиз вакыт эчендә бөтен бүлмәне шул кабахәт ис берлән тутырадыр. Көндезләрен парашаны кую гадәт булмаса да, тышка чыгарга чыгарып йөртсәләр дә, старшийның мине җәзалыйсы бик килгәнгә булырга кирәк, минем парашамны иртә сәгать 9 дан ук кертеп куйганнар иде. Мине сүгә-сүгә бикләп куйдылар. Мин эчемнән шундый кабахәт кешеләрнең мине җәберләр өчен ниләр кылырга теләүләрен, шундый кешеләр кулында идарә булганда һәрвакыт шул золымнар бетмәячәген уйлап, ары-бире йөри башладым. Утырырга, ятарга урын юкка, мин көнемне йөреп үткәрәчәк идем. Озак үтмәде, минем кызулыгым сүрелде. Мин теге кабахәт старпшйны, бертуктамаенча сүгенеп йөри торган ачкыччыны хәтеремнән

чыгардым. Үземнең төрмәдә ничек торуларымны, ссылкага җибәрсәләр, кая китәргәлекләрне, «Таң»ның туктамавын уйлый башладым. Хәзер минем күз алдымда ике шатлык бар иде. Берсе — тиз көннән төрмәгә бару, берсе — «Таң» тукталмау иде. Төрмәгә барырга шатлануымның сәбәбе, әлбәттә, төрмәнең бик кәефле җирлегеннән түгел! Мин төрмәнең начарлыгын, аның кызыгырлык җир түгел икәнлеген бик күптән белә идем. Шуңарга кермәс өчен унбер ай чарлактан подвалга, подвалдан чарлакка качып та йөргән идем. Минем төрмәгә баруны шатлык итеп каравымның сәбәбе төрмәдә укыр өчен иде. Соң вакытларда минем эшем бик күп булганга, мин гәзитәгә башка нәрсә укырга бушамый идем. Гәзитәне ташлап укырга тотынырга тагы гәзитәне ташлый алмый идем. Шуның өчен мине гәзитәне көчләп ташлатырга кирәк иде. Төрмәдә гәзитә булмагач, мин теләр-теләмәс укырга тотыначак идем. Шуның берлән төрмәдә торудан тагы киләчәк хезмәтләрем өчен әллә никадәр файда итәчәк идем. Тагы төрмәдә вакытта мин, отставкага чыккан николайский солдат кебек, үземнең эшләгән эшләремнән шатланып вөҗданә бәйрәм ясап торачак идем.

Гәзитәнең һәр як эше яхшы булганга, минем урыныма язучылар калганга, аның дәвам итүендә дә шөбһә юк иде. Менә мин хәзер шул караңгы, юеш, суык, сасы бүлмәдә шул якты, кызу, татлы фикерләрне башымнан кичереп кальбән рәхәтләнә идем. Минем фикерем бик тиз йөргәнгә, мин кызу-кызу атлап йөри идем. Арып, аяклар авырткач, стенага сөялеп тора идем. Тагы йөрергә китә идем. Минем тынычлыгымны монда сүгешергә яратучы ачкыччы берлән старшинага башка бер кеше дә бозмый иде. Ачкыччы үткән-барганда сүгеп китә иде, старший: «Бүлмә яхшымы?» — дигән булып, көлеп, минем ачуымны китерергә тырыша иде. Ләкин минем боларның берсенә дә ис китми иде, боларның берсенә дә илтифат кылмый идем. Ләкин минем илтифатсызлыгым тагы боларның ачуын китерә, тагы гайрәтләрен арттыра иде. Һәркөнне ике мәртәбә: «Ни аласың?» — дип сорау полициядә гадәт булса да, болар миннән бер мәртәбә дә сорамадылар. Мин үзем бер мәртәбә әйтеп карасам да, сүгеп җавап биргәнгә, ачка үлмәм әле дип, яңадан сорамаска карар

бирдем. Көндез тышка чыгару гадәтләре булса да, мине чыгармаячакларын белгәнгә, ишек янына барып та карамадым.

Шулай итеп кичке чәй вакыты җитте. Старший бер-ике мәртәбә миннән «гафу» теләтмәкче булып килеп китте. Ләкин мин аны күрмәгәнгә салынып, һаман йөрүемә дәвам иттем. Башкаларга чәй бирделәр, мин чәйсез дә калдым. Мин һаман үземнең йөрүемдә, үземнең уемда идем. Сәгать тугызларда мине тагы алып чыгып киттеләр. Мине тагы ачуланып, тагы зуррак җәзалар өчен исерекләр янына кертеп яптылар. Мин тагы үземнең уема, үземнең йөрүемә дәвам иттем. Бераздан соң старший килеп миңа: «Сиңа тегендә ялгыз күңелсез иде, менә монда иптәшләр берлән күңелле булыр», диде. Аның бу сүзне әйткәндә пешкән шалкан кебек йөзе тагын әллә нинди төсләргә кереп китте. Ул мине шуның берлән зур мыскыл итәм, яра өстенә тоз сибәм дип уйлады. Ләкин мин бер дә кыяфәтемне бозмаенча: «Рәхмәт, миңа дөрест тә монда бик яхшы, боларга никадәр фикер таратып була бит», — дип җавап бирдем. Пешкән шалкан үзенең җиңелүен тагы сизде. Аның тагы ачуы килде. Ул әтәч кебек урынында сикергәләргә, сүгенергә тотынды. Озак үтмәде, ул ишекне ачып кереп, куллары берлән кизәнеп мине сүгәргә тотынды. Мин һич илтифат кылмаенча һаман йөри идем. Минем илтифат кылмавым тагы аның ачуын китерә иде. Сикереп, кычкырып арыгач, шунда җыелган биш-алты городовойга әйберләремне алырга кушты. Алар әйберләрне алдылар, мине көл кебек очыртып коридорга алып чыгып киттеләр. Мин кыйнарга алып чыгуларын белсәм дә, бертөрле дә каршы тора алмадым. Чөнки коралланган 5—6 городовойга мин бер эш эшли алмаячак идем. Күз йомып ачканча мин яңадан элгәреге караңгы бүлмәмдә булдым. Кергәндә бер городовой артымнан әллә сукты, әллә типте, мин ишектән өч сажин ерактагы стенага барып бәрелдем. Күз ачып карарга да өлгермәдем, төрле яктан городовойлар мине кыйный башладылар. Бер киенгән кара городовой колагыма сугып җибәрде. Мин шул секундта егылып киттем. Икенчеләре эчемә тибәргә, күкрәгемне таптарга тотындылар. Ләкин мин кулларымны йомарлап, күкрәгемә менгермәдем. Городовойлар арыдылар, туктадылар. Мин, туйдылар күрәсең,

дип, тагы тордым, тагы сугып ектылар. Тагы тибәргә тотындылар, тагы таптарга тотындылар. Мин тагы үземнең күкрәгемне сакларга бар гайрәтемне сарыф кылдым. Городовойлар тагы арыдылар. Тагы туктадылар. Баягы тәҗрибәгә карап, бу юлы мин тормадым. Городовойлар сүгенә-сүгенә чыгып китеп, ишек бикләп куйдылар. Мин тордым. Өстемдәге казакием стенаның сыростена буялып беткән иде. Колагым бертуктамаенча самавыр кайнаган кебек чыңлап тора иде. Эчем авырта, аркаларым сызлый, сөякләрем сыкрый иде. Битләрем ут кебек яна иде. Күңелемдә әллә нинди әйтеп бетерә алмаслык ачу килүе, әллә нинди ниһаять дәрәҗә хурлану хисләре кайный иде. Күңелем берлән бу кабахәтләргә нинди җәза да аз төсле күренә иде. Боларның җинаятьләренә, золымнарына каршы үземне саклар өчен бертөрле дә юл юклыгы минем тагы кәефемне җибәрә иде.

Бара-тора минем тагы уйларым рәтләнә башлады. Минем күз алдыма Мария Спиридоновалар күренә башлады. Мин: «Шулай шул, сугыш вакытында шәфкать көтәргә ярамый. Халык берлән бюрократия арасында сугыш башланган. Мин, халык гаскәреннән бер солдат, бюрократия гаскәренә әсир төшкәнмен. Әлбәттә, алар ни теләсәләр шуны эшлиләр. Шуның өчен бу эш бик табигый, бик мантыйкый эш. Боларны бетерер өчен боларны саклый торган идарәне бетерергә тырышырга кирәк», — дип, тагы үз уема кайттым.

Теге городовойлар мине тишектән карап торалар икән, тагы сүгешергә тотындылар. Ләкин ни өчендер тагы кереп кыйнамадылар. Боларның кыйнаулары миңа ике яктан файда бирде. Бердән, бу идарәнең кешеләренә минем тәмам ышануымны бетерде, боларга кеше җәберләр өчен куелган машиналар дигән фикерне урынлаштырды. Икенче, боларның кыйнаулары ни өчендер минем канымның кызурак хәрәкәтләнүенә сәбәп булды. Мине бик җылытты. Шул салкын бүлмәдә дә тирләтте, һәм дә бик арытты. Шуның өчен мин озакламаенча пәлтәмне киеп салкын идәнгә яттым һәм дә татлы-татлы йокыга киттем.

Мин уянганда бик туңган идем. Тәннәремнең һәрбер әгъзасы сызлый, сыкрый иде. Колагыма кулны тиерер хәл юк, авырта иде. Эчем, әллә нинди

кеше эче куйган шикелле булып, авыраеп авырта иде. Күңелдә әллә нинди ямьсез фикерләр, караңгы уйлар йөри иде. Мин бик тиз сикереп торып тагы йөрергә тотындым. Йөри-йөри тагы фикерләрем җайга салынды. Йөри-йөри тагы җылындым, тагы арыдым. Шул җылым берлән тагы ятып йокладым.

Шулай итеп, биш-алты мәртәбә торып йөреп җылынып яткач, иртә булды. Халык та торып, арлы-бирле йөри башлады. Миңа килгән-киткән кеше юк иде. Баягы иптәшләрдән берсе килде. Аңарга хәлне сөйләдем. Хәзер карандаш, кәгазь китерде, иптәшләргә хат яздым, һәм дә ул ашарга әйберләр, эчәргә чәй китерде. Мин баягы салкын идәндә чәй эчәргә тотындым. Чәй вакытында теге кыз килеп минем хәлемне сорашты. Миңа ашарга әйберләр китерде. Минем бер тәүлек чамасы ашаганым юкка, ашарга-эчәргә тотындым. Бик тәмле итеп ашап-эчеп, тагы идән буенда йөрергә тотындым. Тышка чыгарга-фәләнгә мин хәзер берсенә дә сорамый идем. Чөнки шул көннәрдә төрмәгә җибәрерләр дип уйлаганга, боларның кулларыннан тиз котылырмын дип өметләнә идем. Чәйдән соң минем теге танышларыма кеше килде. Хат язамсың дип кәгазь, карандаш китерделәр. Мин иптәшләргә мендәрләр, юрганнар китерергә яздым. Шулай итеп, бүгенге көннең күбесе үзенә бертөрле генә үтте.

Сәгать өчләрдә старший минем яныма кереп тагы әллә ниләр кылынмакчы булган иде. Ләкин мин керүе берлән: «Монда полисмейстерда фәлән кеше бармы?» — дип сорадым. Ул бар дип җавап бирде. Мин бер дә илтифат кылмаган булып кына: «Аңарга миннән сәлам әйт», — дидем. Минем бу сүзем аңарга яшен кебек тәэсир итте. Аның кыяфәте үзгәрде. Аның «мин старший» дигән фикере кинәттән югалып китте. Ул, нишләргә белмәенчә, минем алдымда генерал алдында торган солдат кебек аякларын шык-шык баса башлады. Мин, сүземнең шулкадәр тәэсир кылуын күреп, күңелемнән бюрократиянең бер кешесенең шулкадәр куркуына, аларның эшләренең шулкадәр әсассызлыгына исем китер, борылып киттем. Старший, нишләргә белмәенчә бераз торганнан соң, минем кәефемне алыр өчен, үзенең кичәге кабахәтлеген оныттырыр өчен: «Господин Исхаков, безне кайчанга чыгаралар

инде, менә бит хәзер замана нинди булды, гаеплене дә, гаепсезне дә ябалар. Мин сезнең эшеңезне белешим әле!» — дип, бик кызуланып чыгып китте. Чыккач ул хәзер хатынына, мине кыйнаган городовойларга кызуланып-кызуланып сөйләргә тотынды.

Әллә нинди городовойларның хатыннарын ачуланып, әллә нәрсә юарга кушты. Ярты сәгать вакыт үтмәде, теге старший тагы килеп кереп: «Господин Исхаков, сезгә мин тегендә бер бүлмә юдырдым, аның сәкесе дә бар, анда күчмисезме? Сезгә әйбер кирәкмиме? Кибеткә җибәрмисезме? Самавыр сорамыйсызмы?» — дип, минем күңелемне алыр өчен үзенең бар куәтен сарыф кылырга тотынды.

Мин аңарга: «Шулай итеңез! Болай итеңез!» — дип әмерләр кыла башладым. Озак үтмәде, мин үземезнең әүвәлге камерамызга барып кердем. Камера ап-ак иттереп юылган, парашкалары чыгарылган, карболкалар сибелгән иде. Бераздан мин кушкан әйберләрне алып кибеттән дә кайттылар. Самавыр да китерделәр. Мин тагы үземнең «җиңүемнең» файдаларын күрә башладым. Бераздан миңа юрганнар, мендәрләр китерделәр. Танышларым гәзит бирделәр. Мин тагы үземнең төрмәдәге тормышларымны уйлап йөри-йөри сәгать уннарны җиткердем. Тамагым тук, күңелем көр булганга һәм дә өч көннән бирле рәтләп йоклаганым булмаганга, мин бик тиз үлгән кебек йокыга киттем.

Мин уянганда бүлмә яктырган иде, коридорда кешеләр кызуланып-кызуланып йөриләр иде. Күрше бүлмәдә дә сөйләү тавышы ищетелә иде. Коридорның ары башында фамилиясе берлән кычкырып-кычкырып исерекләрне чыгаралар иде. Мин көндезгә әллә нинди үзем аңламый торган шатлык берлән уяндым. Теге кыйнау, бер тәүлек ач тору, бер-ике көн рәтләп йокламау хәзер минем күңелемә дә килми иде. Мин уянгач ук мине чыгаралар уены беркетеп куйдым. Минем күңелемә, әллә нигә, бу көннән төрмәгә мине җибәрмәүләре, мине тиз чыгарулары урынлашты.

Мин урынымнан тору берлән минем ишегемне ачып, парашамны алып чыктылар. Миннән нәрсәләр алдыруымны сорап, самавыр китерергә вәгъдә

кылдылар. Мин тышка чыгып юындым. Теге барышняны күреп: «Мине чыгаралар!» — дидем. Ул: «Бер-бер җирдән хәбәр алдыңмыни?» — дип сорады. Мин: «Күңелем шулай тоя!..» — дип җавап бирдем. Теге кыз: «Карыйк, кәрамәтең дөрест чыгармы», — дип, үз бүлмәсенә керде. Мин дә бүлмәмә кереп, кайнаган самавыр янына утырып чәй эчәргә тотындым.

Чәйдән соң теге танышымнар аша миңа аш китерсеннәр дип хат язып җибәрдем. Алардан гәзитә алып укыдым. Гәзитәдә Сәгыйтьнең судебный палатада гаепсез табылуы язылган иде. Мин тагы шатландым. Ни өчендер бүген минем башыма бер дә ямьсез уйлар килми иде. Минем алдымда киләчәкнең иң матур яклары гына күренә иде.

Сәгать икеләрдә миңа әллә никадәр әйберләр китерделәр һәм дә, иртәгә күрешергә киләмез дип әйттеләр, диделәр. Ләкин мин, үземнең иртәгә кадәр монда булуыма күңелем ышанмаганга, аңарга бер дә әһәмият бирмәдем. Кич булды. Минем иртәге кәефем аз гына да кимемәде. Минем чыгам дигән фикерем аз гына да урыныннан кузгалмады.

Сәгать тугызлар җитте. Менә минем камерама старший килеп керде. Минем өчен бик тырышып йөрегән кебек итеп: «Мин сезнең эшне казып чыгардым. Сезне хәзер полисмейстерга чакыралар», — диде. Мин киендем.

Полисмейстерга киттек. Мине секретарьга керттеләр. Ул миңа язган язуын укып: «Сезне полисмейстер егерме дүрт сәгать эчендә Казаннан китәргә куша. Кая барасыз?» — диде. Мин: «Үз авылыма—Яуширмәгә кайтам», — дидем. Мине егерме дүрт сәгатьтә китәргә дип кул куйдырдылар, Һәм дә: өч тәүлеккә ашар өчен бишәр тиеннән унбиш тиен акча алдым, дип тә кул куйдырдылар. Шуннан соң миңе полисмейстерга алып киттеләр. Полисмейстерның бүлмәсеннән бер кеше чыгып мине: «Сез Исхаковмы?» — дип сорады. «Әйе», — дигәч: «Кормовой алдыңызмы?» — диде. Мин бу нәрсә икән дип аптырап калдым. Теге чиновник: «Унбиш тиен алдыңызмы?» — диде. Мин: «Алдым», — дидем. «Алай булса, барыңыз, кайтып китеңез», — диде.

Мин камерага кереп әйберләрне җыештырдым. Теге кыз берлә, кала

торган танышларым берлән күрешеп, әйберләремне күтәреп урамга чыктым. Бу вакытта ни уйлаганым рәтләп хәтеремдә юк. Ләкин чыгу берлән авызымны тутырып-тутырып саф һаваны суларга тотындым. Извозчик булмаганга, Проломныйга кадәр җәяү төшим дип уйлаган идем, тагы бер-бер городовой тотып, әллә ниләр алдап, тагы ябып куймасыннар дип, извозчикка кычкыра башладым. Извозчик килде. Бер-ике минуттан мин үземезнең редакциягә барып кердем. Редакциядәге малай мине күреп исе китте. Ул нишләргә белмәде. Ул мине бөтенләй дөньядан башы китте инде дип уйлап куйган булгандыр ахры. Шуның өчен минем кайтуым кабердән үлек кайтуы кебек тәэсир итте. Ул: «Гаяз абзый, синме? Гаяз абзый!» — дип сикерә иде. Мин үземнең Гаяз икәнлегемне дә исбат кылып тормаенча, әйберләремне калдырып: «Мин «Болгар»га керәм, син хәзер Хөсәенгә барып әйт!» дидем.

*29 гыйнвар, сәгать 8, кич.*

Дүрт көннән бирле шурпа ашаганым юкка эчем әллә нишләп катып киткәнгә, «Болгар»га шурпа ашарга кердем. «Болгар» татарның бик кайнаган җире булганга, һәр татар үзе нишләгәнен белмәенчә генә шпион булганга, элгәре миңа «Болгар»га кереп йөрү, әлбәттә, бик авыр эш иде; Шуның өчен мин «Болгар»га бик сирәк керә идем. Һәм мине анда танымыйлар иде. Шулай булса да, бу юлы мине бик тиз таныдылар. Хәзер «Болгар»ның буена минем чыгу хәбәрем китте. Миңа бик тиз генә бик күп иттереп солянка да китерделәр. «Болгар»дагы кешеләр минем берлән күрешергә керә башладылар. Боларның һәммәсе дә миңа кабердән терелеп кайткан кешегә караган күз берлән карыйлар иде. Боларның бу кадәр гаҗәпкә калуларын аңламаенча торганда бер половой: «Сине бит гәзитәдә корбан булды дип язганнар иде, менә гәзитәсе», — дип күрсәтте. Мин тиз генә гәзитәне карадым. Дөресте дә, минем хакымда язган мәкаләнең ахырында сәяси эш өчен мәшәкать күргәннәр намәнә җырлана торган «сез хак корбан улдыгыз тугры юлда» бәетен кушканнар икән. Шуның өчен бертөрле кешеләр, корбан гаетендә сарык корбан булган кебек,

мин дә корбан булган, минем канымны да сарык каны кебек бюрократия үзенең реакция бәйрәменә агызган дип белгәннәр икән.

Озак үтмәде, Хөсәен килде. Аның да шатлыгының иге-чиге юк иде. Без тиз генә ашап, мин тотылган Сәгыйтьләр фатирына Сәгыйть берлән Исхакны алырга киттек. Сәгыйть, Хөсәеннең сүзенә ышанмаенча, киенмәенчә генә чыкты. Мине күзе берлән күргәч, дөресте дә минем чыкканлыгыма ышанып, киенергә кереп китте. Бик тиз киенеп чыкты. Исхак өйдә булмады. Без мин тотылудан элгәреге көнне чәй эчкән «Москва» гостиницасына киттек. Хөсәен Шакирны эзләргә китте.

Мин Сәгыйтькә үземнең ниләр күргәнемне сөйләргә тотындым. Ул үзенең судын, гәзитәнең ничек баруын сөйләде.

Без бер-ике чынаяк чәй эчкәнчә Шакир берлән Хөсәен дә килеп керделәр. Без һәммәмез чын күңелемездән шатланганга, һәммәмезнең дә эчендә бер-беремезгә сөйләргә бик күп сүзләр тулганга, бер-беремезне бүлеп-бүлеп сөйли идек. Бу минутта безнең һичберемезнең бер кайгысы да юк иде. һичберемезнең дә күңеленә матур киләчәктән башка нәрсәләр килми иде. Без шат идек. Без мәсгуд идек. Иптәшләр минем тотылуның ничек авыр булганлыгын, ничек бөтен халыкка тәэсир иткәнлеген, бөтен татар гәзитәләрендә минем хакымда мәкаләләр булуын сөйләделәр. Минем чыгуымнан хәзер никадәр шат идекләрен, безнең гомуми эшемез булган «халыкка хезмәт»нең никадәр куәте артуын әллә нинди буяулар берлән борып-борып, төрле ягыннан карап бәян иттеләр. Мин дә күңелемнән үземнең чыгуымнан, тагы элгәреге сөйгән хезмәтемә кайтуымнан, әлбәттә, шат идем. Ләкин үземнең төрмәгә кереп укый ала алмау өчен бераз кәефем китми хәле юк иде. Чөнки хәзергә гәзитәдән аерылып китап тотып укулары, мәгълүмат арттырулары тагы «киләчәк»кә калдырылачак иде.

Сәгать икеләрдә без гостиницадан чыгып фатирларымызга таралдык. Мин Хөсәеннәрдә кундым. Иртәгесен миңа китәргә тиеш булганга, иртүк тагы иптәшләр килеп, мине тагы бер тәүлеккә калдырырга ясадылар. Ләкин болай калуның куркынычлы бер ягы да бар иде. Полиция минем егерме дүрт сәгать

эчендә китмәгәнемне белсә, мине тагы тотып алып, йә төрмәгә җибәрәчәк, яисә мине этап берлән озатачак иде. Этап озатканда мин йөз егерме чакрымлы үз авылымызга бик тиз булганда унынчы көндә кайтып керәчәк идем. Чөнки Казан берлән Чистай арасында этап җиде тәүлек йөри. Чистайда, әлбәттә, бер кич куныла, безнең авыл Чистайдан егерме биш чакрым булганга, анда ике тәүлек барыла иде. Шулай булса да, минем бәгъзе әйберләрем хәзер булып бетмәгәнгә, тагы бер тәүлеккә калырга булдым. Бу көнем минем килгән танышларым, иптәшләрем берлән күрешү, сөйләшү, утырышу берлән үтте. Мин авылга кайтып бер-ике атна торып, тагы Казанга килергә дип уйлаштык. Икенче көнне, дүртенче ноябрьдә, сәгать сигезләрдә кич берлән Казаннан чыгып киттем.

Бишенче ноябрьдә кич берлән, икенде-ахшам арасында, сәгать дүртләрдә Яуширмәгә килеп кердем. Халык мине күреп исләре китте. Чөнки аларның фикеренчә, мин тотылсам, мине тимер губуга салалар имеш, караңгы төрмәләрдә ашатмаенча, эчертмәенчә тоталар имеш! Минем шулай итеп кайтып керүем һәм дә көндез кыңгырау берлән кайтуым аларның бер дә башына сыймый иде. Шунысы да онытылмасын, бүген руза гаете көне иде. Шуның өчен халыкның бик күбесе мәчеткә килгән һәм мине күргән иде.

Йортка керүем берлән миңа иң әүвәл сеңелем йөгереп чыгып муеныма асылды: «Абзый, кайттыңмы? Бөтенләй кайттыңмы? И абзый, канатым, синме? Мин ышанмыйм! Абзый, сине алып китмәсләр микән?» — дип, яшенә карыла-карыла еглый иде. Ул үзе еглый, үзе көлә, үзе тагы минем муеныма асылына иде. Әни каршы чыкмаганга, әнинең өйдә юклыгын белдем. Безнең өйдә гомер буенча хатыннар өзелмиләр, гает көн булганга, бүген, әлбәттә, тагы күп иде. Боларның барысы да мине карыйлар, барысы да дөрестен дә минем кайтуыма күзләре ышанмаган кебек кылыналар иде. Сеңелем һаман елый иде. Һаман минем кайтуыма ышанмый, һаман үзенең сагынуын сөйли иде. Хатыннарның карчыклары минем берлән күрешәләр, сөйләшәләр, еглашалар иде. Бөтен өй кыямәт купкан кебек иде. Бөтен өйдә шатлык берлән хәсрәт бергә катышкан, бөтен өйдә минем бөтенләй кайтуым, бөтенләй котылып

кайтуым шатлыгы балкый иде. Менә миңа үземнең кызымны алып чыктылар. Минем хатыным шуннан өч-дүрт ай гына элек аерылганга, кызым да аның берлән бергә булганга, кызымның миңа чыгуы элгәреге хатынымның да мондалыгын белдерә иде. Мин кызымны хакыйкать тә сагынганга кулыма алдым. Шул арада карчыклар: «Балаңны ятим итмә! Анасын ал!»—дип вәгазьләргә тотындылар.

Хатыным берлән минем аерылуымда безнең беремезнең дә гаебе булмаса да, мин үземнең ул эшкә ничек каравым хакында һәм дә ни өчен аерылуымыз хакында монда бер сүз дә язмаска телим! Чөнки бу мәсьәлә минем өчен зур мәсьәлә булганга һәм дә хәзерге зиндан тарихына артык катышы булмаганга, мине аны язмавым өчен гафу кылырсыз дип уйлыйм.

Мин кызымны сөяргә тотындым. Кызымны күргәнемә өч-дүрт ай вакыт үтсә дә, ул миннән бер дә ятсынмаенча килде. Карчыклар тагы: «Әй бала, атасын таный! Алла эшкәртә, әнисе генә бик кызганыч шул! Әллә аламсың!» — дип, туй ясарга да хәзерләнә башладылар. Ул ара да булмады, әни кайтты. Кияү килде, кияүдәге сеңелем килде. Алар да шатлыкларыны әйтеп бетерә алмыйлар, алар да үзләренең хиссиятләрен аңлатырга сүз таба алмыйлар иде. Самавыр кайнады. Йортка халык тула башлады, һәммәсе күрешергә килгәннәр, һәммәсе күзе күреп минем кайтуыма ышанырга килгәннәр иде. Барысы да еглый, барысы да әллә никадәр теләкләр тели иде. Кайсы мине кочаклый яисә үбә иде. Мин, нишләргә дә белмәенчә, сораган сүзләренә җавап биреп тора идем. Бераздан соң эти дә кайтты. Ул да бик шатланган иде. Ләкин никадәр шатланса да, икенде-ахшам арасында мәчеттән чыгу гадәте булмаганга, ул үзенең ахшамын укып, ахшам артыннан укый торган намазларын укымаенча чыкмаган иде.

Чәй хәзерләнде. Әллә никадәр кеше чәй янына тезелеп утырды, әллә никадәр кеше табынга сыймаенча, артка утырды. Әллә никадәр кеше күрешеп чыгып киттеләр. Шулай итеп, кичке сәгать сигезгә кадәр берсе кереп, берсе чыгып тору берлән мин рәтләп чәй дә эчә алмадым, ашый да алмадым. Төнлә берлән юлда рәтләп йокламаганга күрә, үземезнең бер өй суыкка күрә,

яхшылап ашап-эчеп, йокларга дип, кияүләргә барырга булдым.

Без — кияү, мин, сеңелем — барырга чыктык. Ярты юлда ике ат берлән бик күп кешеләр утырган чаналар очрады. Карасак, алар стражниклар икән. Бездән бераз узып киткәч, туктадылар да: «Мулла, мулла!» — дип кычкыра башладылар. Ул ара да булмады, мине стражниклар чолгап алдылар. Урәтниге: «Руки верх!» — итенгәләгән булды. Мине тентергә тотындылар. Мин котылып кайтуымны сөйләсәм дә, мине чанага утырта башладылар. Минем өстемдә казаки берлән толып кына булганга, мин кайтып киенергә теләдем. Җибәрмәделәр. Мине тагы чанага утыртып алып киттеләр...

Салкын җил себергәнгә, юл рәтләп күренми иде. Көн дә салкын булганга, минем эчемә бик тиз суык үтте. Тагы стражниклар, бер унбиш чакрым еараграк ясап, олы юлдан киттеләр. Күрше авылга барып, аның үрәтнигенә кереп чәй эчтеләр. Мин юлда бик ватылганга һәм дә өйдә әллә нинди хиссиятләр башымнан кичкәнгә, бик арыган идем. Мин юл буе туңа-туңа йоклап бардым. Төнлә берлән сәгать дүртләрдә мине Чистай полициясенә алып килделәр. Бик озак дөбердәтеп полициянең подвалына кертеп яптылар. Мине керткәч, өч-дүрт кеше күтәрелеп карады да тагы ятты. Бу шактый гына зур, ике тәрәзәле бер бүлмә иде. Түшәме бик тәбәнәк булганга һәм дә стеналары бик юеш булганга һавасы бик начар иде. Казандагы кебек, монда да параша тора, монда да үзе мәгълүм исе берләң бөтен дөньяны тутыра иде. Мин, күп исәпләп тормаенча, толыбымны кигән көйгә яттым һәм бик тиз йокыга киттем.

*29 гыйнвар, сәгать 10.*

Мин уянганда көн яктырган иде. Мин, торып, шундагы кешеләр берлән сөйләшә, сораша башладым. Боларның берсе Бурнаш урысы иде. Әллә ничә мәртәбә полиция тентү ясаса да, берни таба алмагач, револьвер ыргытып, шуны тапкан булып, исправник шуның өчен өч ай ятарга ясаган икән дә, шуның өчен ята икән. Икенчесе үткән ел авыл халкы арасындагы җир һәм ирек хәрәкәтләрендә катышканы өчен өч ай төрмәгә ятырга хөкем ителгән

Змеевоның яшь кенә бер рус егете иде. Берсе урлау берлән тотылган бер солдат иде.

Мин торгач та, салкын бүлмәдән безнең янга карт кына бер татарны керттеләр. Мин үземне чакыруны көтә башладым. Сәгать уннар җиткәч, бүген чакырмыйлармы әллә дип, чәй эчәргә хәзерләнә башладым. Шундагы стражник аркылы ашарга-эчәргә алдырдым. Шул вакытта бер бот буе гына малай бер кәгазь тотып килеп керде. Миннән форменный сорау башланды. Мин теге малайга син белә торган эш түгел, мине югары чакырсыннар дип әйтеп җибәрдем.

Чәй эчәргә өлгерә алмадым, мине югары алып менделәр. Помощник стражник мине сорый башлады. Минем эшемне эзләделәр-эзләделәр, йөдәп беттеләр. Ахырдан минем сүзем буенча Казан берлән телефон берлән сөйләштеләр. Сәгать бер ярымга кадәр маташканнан соң, миннән Яүширмәдән чыкмаска дип кул куйдырып чыгарып җибәрделәр.

Мин тагы иреккә чыктым. Озак үтмәенчә, минем артымнан килгән үз авылымызның кешесе берлән авылга да кайтып киттем. Аларның сөйләвенә караганда, мин кайткач ук, авылымызның бер куштаны, мин аның сүзе берлән йөрмәгән өчен, мин аның халыкны талавының һәммәсенә дә каршы килеп, аңарга, бик күп зарар иткән өчен, үзенең киявен үрәтниккә җибәреп әйттергән икән. Үрәтникләр-фәләннәргә шул вакытларда авылларны бик карарга әмер булганга һәм, дә былтыр да алар әллә ничә айлар мине эзләп йөргәнгә, минем кайтуым, мине тоту, әлбәттә, алар өчен үзләренең начальствога ихласларын күрсәтергә бик зур сәбәп иде. Шуның өчен алар аны-моны карамаенча, әлбәттә, мине тотып полициягә җибәрергә тиеш иде.

Бу тотулары мәгънәле чыкмаганга, алар яңадан тоттырырга да тырышачаклар.Яңадан әлләниләр алдап, көн дә донослар ясап торачаклар иде. Шуның өчен үрәтникләр баягы Шәйхи атлы куштанга килеп, мине бөтенләй каравыллап тора башладылар. Яүширмәдә өч-дүрт стражник өзелмәенчә тора башлады. Боларның эшләре мине, бездә бер-бер җыелыш-фәлән булса да барып әйтү, мин бер-бер сүз сөйләсәм, тагы донос ясау, авылдан чыксам, мине

хәзер тотып алып кайтып тагы полициягә китереп ябу иде. Авыл халкы минем кайтуыма шатланганга күрә һәм дә бәйрәм арасы булганга күрә, әлбәттә, мине бөтен авыл буена ашка йөртәләр иде. Һәркөнне күрешергә кешеләр килеп, бездә дә утырышлар ясыйлар иде. Тирә-күрше авылдан да дуст-иш, танышлар, кардәш-кабилә киләләр иде. Шуның өчен теге куштан берлән киявенең аты бертуктамаенча Чистай берлән Яүширмә арасында донос ташып йөриләр иде. Үрәтникләр да көн дә минем хакымда әллә ниләр язалар иде. Куштан һәркөнне: «Бүген килеп алалар, бүген!» — дип хәбәр чыгарганга, авыл халкы җыелып мине саклый башладылар. Безнең урамда, безнең капка төбендә, безнең күршеләрнең йортларында утыз-кырык кеше саклап торалар иде. Иртә-кичтән башлап таң атканчыга кадәр каравыл өзелми иде. Көндезләрендә берничә кеше, каравыл калдырып, андый-мондый эш булса үзләренә әйтергә кушып, өйләренә тарала иде. Шуның өчен минем бу көннәрем сугыш сафында торган кебек үтте. Бераздан соң, теге шпионнар йөреп-йөреп булдыра алмагач, стражниклар да туеп беткәч, миңа иркенрәк булды. Мин һаман поднадзор полиция торсам да, күрше авылларга барырга рөхсәт булды. Ләкин кая барсам да, тагы үрәтникләр килеп җитә, тагы минем хакымда донос язалар иде. Өйдә вакытта да һәркөнне стражниклар килеп карап китәләр иде. Шуның өчен мине яңадан тотмаслар дип уйларга бер дә ярамый иде. Һәм мин үзем дә тотмаслар дип уйламый идем. Алай булгач, мин ник тагы Казанга, йә башка шәһәргә китми идем диярсез? Тагы, шуның өстенә, шул арада гына Мәскәүдән «Тәрбиятел-әтфаль» журналының идарәсеннән Заһид әфәнде Шамил исеменнән шактый гына вазыйфә берлән мине чакырып хат та бар иде. Шулай булгач, мин ник китми идем соң? Минем китмәүнең сәбәбе сайлауларның якынлыгы һәм дә үземезнең волостьның мине сайларга теләүләре иде. Мин китсәм, шундагы куштаннар, старшиналар, земский начальниклар төрле хәйләләр берлән халыкны алдап мине сайлатмаячаклар иде. Минем сайлануым үзем өчен мәшәкатьтән артык бернәрсә булмаса да һәм дә үземнең канымны, җанымны айамаенча шул юлга корбан булуны лязем итсә дә, волостьта башка кеше булмаганга һәм дә начар кеше җибәртү ватан вә халык алдында бик зур

җинаять булганга, әлбәттә, мин үземне сайлауга тирес тормаячак идем. Шуның өчен мин үземнең сайлау праваларымны карап эшләремне тикшерттем. Минем сайлану правам бар иде. Ләкин ул праваны сакларга мотлак үзем булу лязем иде. Чөнки үзем булмаганда шул тирәдә бөтен карагруһ генераллары мине төшерер өчен бөтен куәтләрен сарыф кылачаклар иде. Менә шуның өчен мин Яүширмәдән китмәенчә тордым. Менә шуның өчен стражникларның көн дә килеп, бөтен өй җәмәгатемезне дә бимаза кылуыны күтәрдем.

Яүширмәдә болай итеп тик тору көн буе эш эшләргә өйрәнгән кешегә, әлбәттә, бик җиңел булмады, нә исә мин киләчәк өмете берлә һәр мәшәкатьне күтәреп тордым. Яуширмәдә торганда телгә алып сөйләрлек эш булмады. Минем гомерем вак-төяк китаплар уку, карендәш-кабилә берлән, дуст-иш берлән утырышу берлән үтә иде. Мин көн буе өйдә тора идем, көн буе идән буенда йөреп вакытымны уздыра идем. Язарга утыра алмый идем. Казаннан рәтләп хәбәр килми, гәзитә-фәлән бик сирәк килә иде. Шуның өчен Казанның казан кебек кайнаган тормышыннан соң мондый тын, җансыз тормыш, табигый, мине арыта, мине вата иде. Шуның өчен һәркөнне авыру идем, һичбер вакыт кәефле булып тора алмый идем. Бу көнге көн кичәгегә, иртәге берсекөнгә охшаган тормышым иттифакый бер вакыйга берлән бераз үзгәрде.

Беркөнне кич берлән сәгать уннарда минем элгәреге хатыным кызын күтәреп килде. Моңынча да әллә ничә мәртәбә килмәкче булса да, агасы берлә анасы тыеп калдырганга, бу килүе, әлбәттә, өйләрендә бер зур революциядән соң булган эш иде. Шуның өчен миңа килер өчен шулкадәр фидаилык кылган элгәреге хатынымны кабул итмәү минем тарафтан бик зур оятсызлык булачак иде. Тагы, арамыздагы бала һәрвакытта безне бәйләп тора иде. Шуның өчен аның килүе берлә никях укытып, мин тагы үз хатынымны алдым. Бу вакыйга минем тормышымны бераз үзгәртте. Мин хәзер элгәреге кебек үк ялгыз түгел идем.

Шулай итеп көннәр, атналар үтеп китте, миннән һаман надзорны алмадылар. Декабрь кергәч, сайлаулар якынлана башлагач, Чистай

полициясенең котыруының иге-чиге булмады, ул Чистайның карагруһлары берлә бер сүзле булып, сайлауларда карагруһларны гына үткәрер өчен күзгә күренгән бер кешене арестовать итәргә тотынды.

Декабрь башларында Гариф Бадамшинда тентү булды. Дамелла Нәҗип хәзрәтне чакырып исправник арестовать итәм дип куркытты. Чистайның карагруһлары үткән сайлауларда бер кешеләрен дә үткәрә алмауларын мөселманнарның кадетлар берлән блок ясауларыннан идекен белгәнгә, ул блокның ясалуына сәбәп булган кеше дамелла Нәҗип хәзрәт дип белгәнгә, әлбәттә, сайлауларда җиңәр өчен аның сайлау эшенә тәэсирен бетерергә кирәк иде. Аңарга башка татарлардан карагруһлы тарафлы кешеләр— Мәхмүд Уразгилдиев берлән Зәңгәр Сәлах, Гариф Бадамшин берлән дамелла ябылганда халык, Зәңгәр Сәлах сүзен тыңлап, карагруһларга шар салырлар дип күрсәткәнгә, карагруһлар боларның икесен дә ябарга әмер иттеләр.

Полиция карагруһларга каршы килә дә алмый, киләсе дә килми иде. Шуның өчен унөченче декабрьдә дамелла берлән Гариф Бадамшин арестовать ителделәр. Бу минем өчен бер сабак булса да, мин тагы югарыгы сәбәпләр өчен Яуширмәдән китә алмадым. Боларның ябылулары бөтен татар халкына тәэсир итте. Бөтен авыллар да шул хакта сөйли башлады. Мин, әлбәттә, мөмкин булган кадәр бу вакыйганың сәбәпләрен хәзерге бюрократиянең законны һич илтифатка алмаенча исерек городовойлар сүзе берлән теләсә нишләвен аңлатырга тырыштым. Дамелланың ябылуыннан халыкның ачуы, табигый, тагы кабарды. Халык элгәре колагы берлән ишеткән золымнарны күзе берлә күрә башлады. Дамеллаларының ябылуы безнең Яүширмә өчен дә тәэсирсез калмады. Безнең эти, җитмеш яшьлек мулла, мәҗлесләрдә каты сүзләр сөйли башлады. Теге Шәйхи куштан үзенең кияве берлән Зәңгәр Сәлах аша тагы безнең эти, кияү, минем өстемнән донос ясый башладылар. Халыкның моңарга бик ачуы килеп, беркөнне мәчеттә бик зур тавыш кубардылар. Теге куштан тагы донос ясап үрәтникләрне алып килде. Авыл тагы бик чуалды. Мин, әлбәттә, бу доносларга каршы бер эш тә эшли алмый идем. Нинди юл берлән дә үземне аресттан саклый алмый идем. Чөнки бу вакытларда Чистайда закон-

фәлән дигән нәрсә бөтенләй беткән иде.

Дамелла берлән Гариф абзыйны япкач, мин Чистайга килдем. Чистай халкының бертөрлесе, куркып, Чистайдан качкан, бертөрлесе бүредән курыккан кебек үзенең өенә кереп бикләнгән иде. Бик аз гынасы элгәреге кебек сайлау хәсрәтләрендә, ябылганнар кайгысында йөриләр иде. Мин Гариф абзыйны, дамелланы ябылган өчен бик кызгангандыр дип уйламагыз! Аз гына да юк. Чөнки аларның ябылуларыннан үзләренә бераз зарар булса да, алар ябылуы аркасында халык аңлавы артуы файдасы ул зарардан йөз өлеш артыклыгында һич шөбһә юк иде. Халыкның аңлавы артуга сәбәп булулары өчен аларны түгел кызганырга, аларга гыйбта кылырга, шул эшләр башкаларга насыйп булсын дип теләргә, боларны ябылулары берлән тәбрик кылырга тиеш иде. Вакыйган да, мин аларны тәбрик кылып хат яздым.

Чистай халкы, мин Чистайга килгәндә, барысы да ябылганнар өчен елыйлар иде. Мин сәяси тартышуларда елауларның бер дә мәгънәсе юклыгын белсәм дә, туплар, мылтыклар берлән коралланган дошманга каршы ачы күз яше берлән генә берни кылып булмаганны бик яхшы аңласам да, боларның елауларына шатлана идем. Чөнки бу елауның ахыры ниһаять дәрәҗә ачу килү, аның нәтиҗәсе дошманга каршы дошман коралы берлән кораллану, аның берлән чынлап тартышу икәнен белә идем. Шуның өчен бюрократиянең бу гакылсызлыгына, уртада тора торган бер зур халыкны үзенең мәгънәсез тәдбирләре берлән революция тарафына күчәргә хезмәт итүенә мин чын күңелемнән шатлана идем. Чистай полициясенең бу золымы унбиш ел мөдәррис булып торган бер мөдәррисне алты баласын калдырып исерек учитель Зәңгәр Сәлах сүзе берлән төрмәгә ябулары һәр татарның хөкүмәткә актык игътикадын, актык мәхәббәтен бетерә торган эш иде. Моннан берәр ай гына элек безнең «Тартышуда гына табарсың син үзеңнең хакыңны!» дигән сүзебездән көлеп, хөкүмәткә ышанып йөрегән кешеләр үзләре хәзер бездән битәр тартышуга халыкны димлиләр, тартышусыз халыкның җиңә алмавын сөйлиләр иде. Һәр килгән-киткәнгә аларның ни өчен арестовать ителүен, халык яклы булган кешеләрнең һәрвакыт шулай халыкның дошманнары

тарафыннан нинди бәла вә җәбер күрүен сөйлиләр, аңлаталар иде. Боларның картлары хәзрәти Йосыф та тугрылык өчен зинданда яткан, хәзрәти Муса тугрылык өчен үзенең туган-үскән җиреннән качкан дип, яшьләре халык өчен егерме дүрт ел төрмәдә яткан Морозовлар, Вера Фигнерларны мисалга алып, Созоновлар, Каляевләр халык өчен үзләренең җаннарын, каннарын фида кылганнар дип сөйлиләр иде. Хасыйле, белгән белгәнчә шул мәсьәләне мөляхәзә кыла, шулар хакында сөйли, шул эшнең бүген булмаса иртәгә булачагын аңлата иде. Чистайның һәр кибете, чәйханәсе, постоялый дворлары, мәҗлесләре хәзер һәммәсе дә бер митинг хәлен алган иде. Мондагы сөйләүчеләр мәшһүр хатибләр-фәләннәр булмасалар да, боларның сүзләренең тәэсире егерме ел сөйләгән хатибнең сүзенең тәэсиреннән артык иде. Чөнки болар күз алдындагы золымны, күз алдындагы кабахәтлекне күрсәтәләр, шуның сәбәпләрен бәян кылалар, шуны бетерүнең юлларын сөйлиләр иде. Мин, әлбәттә, безнең хезмәтемезне җиңеләйтүләре өчен, халыкка аңларга шулкадәр зур юл ачулары өчен Чистай полициясенә рәхмәтләр укый идем. Мөселманның күп җирләрендә шундый бюрократларның күбрәк булуын чын күңелемнән тели идем. Чөнки шундый эшләр күбрәк һәм ешрак булганда алар үзләренең эшләре берлән халыкның хәрәкәтләнүенә, халыкның үзен үзе саклар өчен үзенең иптәшләре, дустлары берлән бергә булырга тырышуына, шулай итеп, безнең халыкның да тугры булган тартышу юлына керүләренә сәбәп булачаклар иде.

Чистайда моңарга башка тагы бер сүз булса да, ул да дамелла берлән Гариф абзый өстеннән торган кешеләрне сүгү, аларның кабахәтлекләрен очраган бер кешегә аңлату, шпионлыкның никадәр начар-сәфил бер эш идекен әллә нинди дәлилләр берлән исбат кылу иде. Бу кешеләр, чи-стайларның сүзләренә караганда, Зәңгәр Сәлах, Чарныш Мәхмүди, учитель Мирсәет иде. Болар, халыкның бу кадәре күтәрелүеннән куркып, кайсы анда качкан, кайсы монда качкан, кайсы өендә бикләнгән иде. Боларның һәммәсе дә үзләренең кабахәтлекләренең җимеше шулкадәр тиз өлгерүенә һәм дә шулкадәр ачы булуына гаҗәпкә калып, нишләргә белмәенчә торалар иде. Боларга, урамга

чыксалар, «шпион!» дип кычкыралар, кеше янына килсәләр — сүгәләр, өйләренә кайтсалар — исемсез хатлар берлән боларның шулкадәр дошман булуы аркасында, үзләре төрмәдә булмасалар да, сөйләшергә кеше таба алмыйлар, үзләренең өйләрендә торсалар да, тыныч йокы күрмиләр иде.

Мин килгән көнне Бөгелмәдән, Уфадан, Әлмәттән берникадәр кеше ябылганнарның кайгыларын кайгырышырга килгәннәр иде. Чистайда бер-ике-өч көн торганның соңында мин тагы авылга кайтып киттем. Бер-ике көннән соң, егерме өченче декабрьдә, шимбә көн сәгать икенче яртыда, мин тавышка уяндым, тавыш—әти тавышы иде. Әти әллә кем берлән сөйли иде. Мин дә тордым. Ул арада әти дә килеп безнең ишекне какты, һәм: «Килделәр!» —диде.

Мин тордым, ут кабыздым, хатыным торып егларга тотынды. Шул арада мылтыклар күтәреп дүрт-биш стражник, бер урәтник килеп керделәр һәм миңа киенергә куштылар. Әти үзенең белер-белмәс русчасы берлән тегеләрне сүгәргә тотынды. Мин гомеремдә этинең ул кадәр ачуланганын, ул кадәр каты сөйләгәнен күргәнем юк иде. Ул әллә кайдан русча сүзләр табып бертуктамаенча сүгә иде. Куллары берлән бутый иде. Әни миңа киемнәремне китерергә тотынды. Мин киенә башладым. Хатыным бер эш эшләмәенчә елавын гына белә иде. Әти һаман сүгә, һаман кыза бара иде. Әти дөньяның әчесен-төчесен бик күп татыганга, үзен-үзе бик илтифатсыз тота иде. Урәтник, этинең басылмавын күреп, револьверын чыгарды. Әтине куркыта башлады. Әти корсагын киереп: «Ат! Ат!» — дип һаман янына бара иде. Ахырдан мин аны туктаттым.

Бер биш минуттан мин киенеп чыгып стражниклар чанасына утырдым. Әтиләр, әниләр, хатыным, сеңелләрем озатып калдылар. Хәзер минем шикләнгәнем боларның кырда кыйнаулары иде. Чөнки бик күп вакытта стражниклар алып барганда кыйныйлар иде. Авыл халкыннан курыктылармы, мине кыйнамаенча гына илттеләр. Иртә берлән сәгать җиделәрдә Чистайга илтеп, беркөн Казаннан кайткач китергән бүлмәгә яптылар. Мин берәр сәгать йокладым да чәй эчәргә хәзерләндем. Шундагы стражник аша чәй-шикәр, ашамак-эчмәк әйбере алдырдым, һәм чәй эчәргә тотындым.

Бу бүлмәдә миңа башка бер рус, бер татар малае бар иде. Рус—старшина берлән орышышкан өчен, татары — агасын кыйнаган өчен яталар иде. Алар миңа шул көндә генә бер учительне, прокламация табып тотып китереп, үтергәнче кыйнауларын, камчы берлән кыйный-кыйный өстендәге драп пәлтәсе телем-телем булып бетүен һәм дә бер чуашны ике көн бербуйдан кыйнап үлек кебек ясауларын сөйләделәр. миңа да шулай булыр дип сөенче алып куйдылар.

Чәйдән соң сәгать унберләрдә мине исправникка чакырдылар. Полициянең алдагы бүлмәсендә әллә никадәр стражниклар җыелган иде. Мин боларны карарга да өлгерә алмадым, берсе сугып җибәрде. Минем бәхетемә каршы, шулкадәр каты сукты, мин икенче ишеккә барып бәрелдем, һәм ишек ачылып китте, минем бүрегем шунда калды. Утыз-кырык кешеләр арасында бүрек эзләп тору  мөмкин түгел идекен белгәнгә, мин исправник янына яланбаш мендем. Исправник яңа гына йоны чыгып килә торган бер рус иде. Допрос башланды. Әүвәлге сөаль: «Син Думага бармакчы буласыңмы?» — диде. Мин аңарга: «Минем Думага барырга теләвем генә җитми, халык мине җибәрергә теләргә кирәк», — дидем. Тагы шундый әллә нинди безнең «идарәи мәшруталы» мәмләкәтемездә генә гаеп хисаплана торган сөальләр бирде дә мине төшерергә кушты. Мин: «Төрмәгә җибәрмәссезме?» — дидем. Бик зур кеше булган булып: «Анысы минем эшем!» — диде. Мин: «Стражниклар ник кыйныйлар? Менә мине суктылар. Кыйнамаска кушыңыз», — дидем. Үрәтниккә карап, күзен кысып: «Кыйнамаңыз!» —диде. Бу күз кысу, әлбәттә, тугрыдан-тугры мине кыйнарга әмер иде. Шуның өчен мин хәзер кыйналырга хәзерләнеп төштем. Ләкин ни өчендер мине чыкканда кыйнамадылар. Шулай булса да, мин кыйнауны көтә башладым. Ишектән дөбер-дөбер керү берлән мине кыйнарга керәләр дип куркып китә идем. Ләкин ул минем өчен булмаенча, бер-бер яңа кешене китергән булалар иде дә, аны кыйныйлар иде. Бу көннәрдә русларның рождество бәйрәмнәре булганга, әллә никадәр исерек китерәләр иде. Һәммәсен үтергәнче кыйнап, салкын подвалга ябалар иде. Боларны кыйнаганда минем котым очып тора иде.

*31 гыйнвар, сәгать 10нар, кич.*

Подвалда мин өч көн тордым. Ләкин гомеремдә бу кадәр кешеләрнең җәберләнүен күреп, бу кадәр ачуым килгәнен белә алмыйм. Бу өч көндә һәр минутта мине чакырып, камчылар, мылтыклар берлән кыйнауны көтә идем. Бөтен куәтем берлән, ничек кыйнасалар да, тавыш та чыгармаска хәзерләнә идем. Ләкин ни өчендер мине кыйнамадылар.

Чистай танышларым миңа ашарга-эчәргә китерделәр. Күңел җәрәхәтен исәпләмәгәндә, мин монда бик яхшы тордым. Мондагы тормышта артык яңа эш булмады. Ята торган кешеләр һәммәсе дә шул элгәрегеләр иде. Тыштан да артык җәбер килми иде. Городовойлар килгән бер кешене кыйныйлар иде, алар чыккач, без җыелышып сүгә идек, аларның кабахәтлекләрен тикшерә идек. Алай булса да, актык көнне кич берлән безгә тагы бер яңа кеше керттеләр. Бу кеше этап берлән килде. Үзе ап-ак сакаллы, киң маңгайлы, Толстой кыяфәтле җитмеш биш яшьлек бер карт иде. Бу карт бик туңып килгәнгә, мин аны хәзер чәй эчәргә чакырдым. Карт чәй эчәргә утырды. Мин алдына куйган нәрсәләрне ашарга тотынды. Ашамак-эчмәк әйберләрен бик тиз җийуы моның күптән бирле тамагы туйганы юк идекен белдерә иде. Ашап-эчеп туйгач, бабайдан сораша башладым. Бабайны Мамадыш өязендә рөхсәтсез китаплар тараткан өчен тотканнар икән. Мамадыш төрмәсендә бераз яткырганнан соң, үзен Чистайга китергәннәр икән. Бабай безнең кем идекемезне белмәгәнгә, ул сакланыбрак сөйләде. «Ни өчен соң Мамадыш уездына бардың?» — дигәч: «Атым югалган иде, шуны эзләп йөрдем», — диде. Бераздан миңа аш китерделәр, мин тагы теге иптәшләрне һәм бабайны ашаттым. Аштан соң тагы чәй эчтек. Бабайны югарыга алып менделәр. Анда иртәгә чыгарачакларын әйткәннәр. Бабай хәзер, бер яктан, безгә ышануы артудан, икенче яктан, үзенең чыгуына шатланудан, безгә ап-ачык сөйләргә тотынды. Аның аты әллә кайчан югалса да, мәкъсуды һичбер ат эзләү түгел икән. Ат эзләү дигән сүзе бертөрле полиция күзеннән генә югалу икән. Ул ат эзләү хәйләсе берлән авылдан авылга йөреп сөйли, халыкны аңлата, әллә

кайдан алган китаплар, гәзитәләр тарата икән! Ул Чистай өязендә, Бөгелмә өязендә әллә кайчаннан бирле йөри, шул тирәдә әллә кайчаннан бирле «җир һәм ирек» фикерен таратучы мәгълүм карт икән. Бабай үзе николаевский солдат булганга һәм дә флотта хезмәт иткәнгә, шактый гына мәгълүматы бар һәм дә күп мәмләкәтләрдә йөргәнгә, Европа падишаһлыкларының идарәсе хакында, андагы халыкның тормышы хакында бик күп нәрсә белә иде, аның өстенә тагы, сүзгә дә шактый гына оста иде. Шуның өчен ул шул үзе алган юлда халыкка бик күп файда итүендә шөбһә юк иде. Минем янымдагы рус аңарга: «Син, бабай, төрмәгә керсәң дә кайгырырга ярамый, анда чиркәү бар, көн дә гыйбадәт кылып торырсың!» —диде. Карт: «Юк, дустым, минем урыным чиркәү түгел, теләгән кеше барсын. Минем урыным хәзер авыл җыеннары, минем динем чиркәүгә барып гыйбадәт түгел, авыл халкына «җир һәм ирек» фикерен аңлату», — диде.

Мин картның шулкадәр гакыллы сүзенә исем китте. Ул үзе дә миңа карап: «Минем хәзер угылларым өйләнгән, кызларым киткән, халыкка мин хезмәт итмәенчә кем итсен, менә синең балаң калган, хатының калган, ата-анаң калган, аларны тәрбиягә кешең юк! Мине төрмәгә япсалар, минем кемем кала! Юк инде, мин актык гомеремне шул юлда үткәрәм», — диде. Мин: «Хәзер чыккач нишлисең?» — дидем. «Менә хәзер чыккач ук фәлән авылга барам. Анда танышларым бар, аларны җыям. Менә мине ничек йөртүләрен сөйлим, шунда халыкка файда итә торган кешеләрнең ничек ябылуларын аңлатам. Халыкка «җир һәм ирек»не ничек алып булуның юлларын күрсәтәм, анда кунам, икенче көн фәлән авылга барам, өченче көнне фәлән авылга», — дип, ун-унбиш авылның исемнәрен әйтте.

Иртәгесен бабай миннән элек чыгып китте. Бәлки, ул тагы хәзер бер-бер җирдә тотылгандыр да тагы бер-бер җирдә ята торгандыр, ләкин кая булса да үзенең «динен», үзенең хезмәтен ташламагандыр. Мин бу бабайны күреп, руслардан шундый тырыш, аңлы кешеләр чыгуына исем китте. Үзем таныган татар картларының моның кебек яшьләрендә йә мич башында ятып киленен тиргәп торуын, яисә угылының бердәнбер атын өшәндереп, лырт-лырт күрше

авыл ишанына хәтемгә йөргүен хәтеремә китереп, боларны чагыштырып карадым. Вакыйган, бу ике төрле халык арасында никадәр аерма: берсе үзенең карт гомерен халыкка хезмәт итеп үткәрмәкче булып, бала-чагасыннан аерылып, төрмәдән, полициядән курыкмаенча, халык арасында фикер таратырга чыга! Икенчесе дөньядагы һәрбер яңа эшкә каршы тора, үзенең файдасы кайда, зарары кайдалыгын белмәенчә, үзенең җәмәгатенең маңлай тиресе берлән табылган малын әллә нинди әрәмтамак ишаннарга сарыф кыла! Минем, әлбәттә, боларның кайсысын артык күргәнемне беләсез, гакылыңыз булса, сезнең дә минем берлән бу фикердә мөштәрәк булуыңызда шөбһәм юк!

Һәр нә исә фәлсәфә җитәр! Вакыйгага кайтыйк. Егерме җиденче декабрьдә сәгать унберләрдә мине тагы исправникка алып менделәр. Бу юлы миннән бер допрос та, фәлән дә булмады. Фәкать үзләренең мине ничек гаепләүләрен генә бәян кылдылар. Мин үзебезнең авылның теге Шәйхи куштанга һәм дә дөньяга да килмәгән бер Мөхәммәдиев исемле Чистай татарына: «Мин революционерлар партиясе кешесе», — дигән имешмен! (Шуны да онытмаңыз, дөньяда «революционерлар партиясе» дигән бер партия дә юк.) Шуның өчен мин бу сүзне әйткән булсам да, бу партия булмаганга, бу сүз бер кешенең: «Мин Казан ханының кызын урладым»,—дигән кабилдән генә булачак иде дә, минем гакылсызлыгымны яисә ялганчылыгымны күрсәтә торган бер эш кенә булачак иде.

Ләкин полиция алай карамады. Алар мине шуның өчен 129 нчы статья берлән гаепләп төрмәгә яптылар. Боларны укыганда мин, әлбәттә, көлеп тора идем. Чөнки монда аз гына да колакка ятарлык сүз юк иде. Актның гыйбарәләре хата булган кебек, мине ябарга күрсәткән дәлилләре дә үрмәкүч оялары гына иде. Әгәр бу язу кисәген, башка мәмләкәтләрдәге кебек, хакимнәргә бирелсә иде, бу язуга карап, түгел мине төрмәгә ябу, гакылдан язган дип исправникны сумасшедший домга җибәрерләр иде. Монда гаепләү дә, хөкем итү дә полициянең үз ихтыярында булганга, әлбәттә, мине төрмәгә җибәрделәр. Сәгать 12 ләрдә мине бер городовой Чистай төрмәсенә китерде. Капканы шалтыратып ачкач, мине конторага алып кереп тентеделәр.

Янымдагы акчамны алып калдылар. Аның соңында исемнәремне, яшьләремне язып алып, мине төрмәгә керттеләр.

Төрмә йорты бик биек таш койма берлән әйләндереп алынган шәһәр читендә бер йорттыр. Капкасының өстендә төрмәнең чиркәве булганга, чиркәү астының ике ягында ике капкадыр. Урамга чыга торган капка агачтыр, төрмә йортына керә торганы —тимердер. Ике капка арасында, чиркәү астында, ике контор һәм старшийның фатиры бардыр. Төрмәнең бинасы соңгы капкадан 10—15 сажин ераклыгында өч катлы, акка буялган таш өйдер. Өч катының да тәрәзәләре тышкы каттан тимер рәшәткәләр берлән беркетелмештер.

Мин килгәндә сәяси кешеләр тышка йөрергә чыкканнар иде. Гариф абзый берлән дамелла дә йөреп торалар иде. Мине бер надзиратель алып кереп китте. Тар гына, караңгы гына, боргаланып беткән таш баскычлардан менә башладык. Өченче катка менгәч, караңгы гына коридорга кердек. Мине озатучы мондагы, кулына бик күп ачкычлар тоткан надзирательгә: «Бадамшиннарга керт!»—диде. Теге надзиратель ачкычларын алып, шалтыр-шолтыр китереп, бер бүлмәне ачып кертте.

Бүлмә бер дә искиткеч түгел иде. Бу, өстеннән генә караганда, Казанның Бәди карчык нумирларының берсе иде. Шундагы кебек сәкесе бар иде, шундагы кебек мебеле юк иде, шундагы кебек буяулары искергән иде. Бәди карчык нумирыннан аермасы булса, ул да моның тәрәзәсенең бик ямьсез киң булуы, пыялаларының кырык корама, йөз ялгаудан булуы һәм дә тәрәзәсенә тимер рәшәткә куелуы иде. Идәндәге таз, комган, сәкедәге юрганнар, мендәрләр моны тагы Бәди карчык нумирына охшата иде.

Минем полициядә дүрт көндә бер мәртәбә дә рәтләп юынганым булмаганга (чөнки анда юына торган җир юк), мин комганда су күрү берлән юынырга тотындым. Бераздан соң әллә нинди кыңгырау тавышы чыкты. Аның артыннан ук тышта: «Бер вакыты үтте!» — дип кычкырдылар. Шуның артыннан ук гөрләшеп-кычкырышып сәясиләр югары менделәр. Алар берлән бергә Гариф абзый, дамелла да менде. Мин яңа кеше булганга, «ирек»тән хәбәрләр сораша башладылар. Һәм, кунакны сыйлыйк әле дип, чәйнек берлән

кайнаган су алырга төшерделәр. Бер ике-өч минуттан соң без тәмам Бәди карчык нумирына товар алырга килгән кешеләр кебек, яисә угылларын мәдрәсәгә китерергә килгән муллалар кебек сөйли-сөйли чәй эчә башладык. Миндә сүз күп булганга, күбрәк мин сөйли идем. Озак үтмәде, тагы звонок булды. Надзиратель: «Ашка төшеңез!» — дип кычкырды. Үзе чаңгырдатып авыр ишекләрне ачып йөри башлады. Коридорда халык анда да, монда да чаба башладылар. Бераздан безгә дә аш китерделәр. Аштан соң берәр сәгать вакыт үткәч, тагы йөрергә чыгарга кычкырдылар. Бу юлы мин дә йөрергә чыктым. Төрмәнең йортында җир эшләре берлән кергән авыл кешеләре, политическийлар, төрмә киемен кигән жуликлар (монда аларны шпана дип атыйлар) йөриләр иде. Кайсылары бер-берсе берлә көрәшә-сугышалар, кайсылары сөйләшәләр иде. Мин, дүрт көн полициянең сасы һавасында торганга, әлбәттә, бу саф һаваны рәхәтләнеп сулый идем. Мин шул көнне үк шундагы политическийларның күбесе берлән таныштым. Монда Государственный думаның члены Герасимов та бар иде. Һәммәсе дә ачыклар, уйныйлар, сөйлиләр, көләләр иде. Сәгать тулгач, тагы безне керттеләр. Бераздан соң тагы звонок булды. Тагы: «Ашка төшеңез! Суга барыңыз!»—дип кычкырдылар. Без дә яңадан чәй эчәргә тотындык. Чәй вакытында безгә әлеге парашаны керттеләр. Аның сасы исе керү берлән бөтен бүлмәне тутырды. Моның исе монда да шул полициянеке төсле, Казаннныкы төсле иде.

*1 нче февраль, кич сәгать 10нар.*

Бераздан соң утлар керттеләр. Аннан да бераз үткәч, сәгать 6 ларда, бик озак звонок булды. Камераларның ишекләрен бик каты итеп яба башладылар, зур йозаклар куркынычлы тавышлар чыгара башладылар. Берәр минуттан соң бөтен төрмә тып-тын булды. Бераз вакыт үткәч, камераларның ишекләре берәм-берәм ачыла башлады. Поверка (тикшерү) башланды. Кәгазь-карандаш тотып, юньсез генә бер солдат безгә кереп, кәгазенә өчле цифр куеп чыкты. Озакламады, поверка да бетте. Төрмә тагы кайный башлады. Анда да, монда

да тавышлар ишетелә башлады. Сәясиләр волчок (ишектәге тишек) аша сөйләшә башладылар. Бер шпана (жулик) сызгырырга тотынды. Ераграк камералардан сүзләре аңлашылмаган тавышлар ишетелә башлады. Ерактагы татарлар җырларга тотындылар. Төрмә әллә нинди төрле тавышлар берлән гөрләргә тотынды. Безгә кичке ашны китерделәр. Без ашап-эчеп, сөйләшеп, кичке сәгать уннарга кадәр утырып, йокларга яттык. Төрмә бик озак йокламады. Ул бер тынга калган кебек була иде, бер зур машина кебек төрле тавыш берлә гөрләргә тотына иде. Полициядә йокы рәтләп булмаганга, мин, әллә нинди зур кайгысыннан котылган кеше кебек, тирән йокыга киттем.

Иртә берлән күземне ачып җибәргәндә, төрмә тагы уянган иде. Аның төрле тарафыннан төрле тавышлар чыга иде. Төрле почмагында татарча, русча сүзләр ишетелә иде. Мин уянгач ук үземнең кайдалыгымны белә алмадым. Мин школада, пансионда кебек тә булдым, мәдрәсәдә кебек тә булдым. Шалтырап ачылган авыр ишек тавышы мине бөтенләй уяндырды. Мин үземнең төрмәдә идекемне хәтеремә төшердем. Бераздан соң өчемез дә торып беттек. Озак үтмәде, юынып, киенеп чәй эчәргә утырдык. Без чәй эчә башлагач, кичәге кебек тагы бик озын звонок булды. Тагы бик кызу-кызу ишекләр бикләнде. Тагы төрмә тып-тын калды. Тагы поверка башланды. Тагы безгә кичәге юньсез урыс кереп кәгазенә өчле цифр куеп чыкты. Озак үтмәде, поверка бетте. Тагы авыр ишекләр бик ямьсез чыгырдап ачыла башладылар. Коридорда халык кайный башлады. Без чәй эчеп бетердек. Шул арада тагы звонок булды. Звоноктан соң, надзиратель: «Хөкем ителгәннәр, йөрергә!» — дип кычкырды. Безнең коридорның берничә кешесе чыгып киттеләр. Бер сәгать вакыт үткәч, тагы звонок булды. «Сәясиләр, йөрергә!» — дип кычкырдылар. Без барымыз да киенеп йөрергә чыктык. Бер сәгатьтән соң звонок булды. Камераларымызга кердек. Тагы кичәге кебек аш килде, чәй булды, поверка бетте, параша керде. Төрмә гөрли башлады. Шулай итеп, безнең бу көнге көнемез иртәгәгә, үткәне берсекөнгә охшап гомеремез үтә башлады.

Төрмәгә мин унынчы сәяси булып кердем. Миңа кадәр чын сәясиләр

тугыз гына иде. Аларга башка җир эшләре берлә кергән авыл халыклары һәм дә, попларын, дьяконнарын стражниклар үтергәч, крәстиәннәрне бунтовать итте дип күрсәтер өчен китерелгән 17 Мамыйк руслары бар иде. Боларның арестовать ителүләре барыбер безнеке кебек үк низамсыз-нисез булса да, боларны, төрмәдәге укыган сәясиләргә катыштырмас өчен, начальство жуликлар берлән бергә утырткан иде. Укыган сәясиләр арасында өчесе авыл учительләре иде, икесе типография хезмәтчеләре, берсе авыл писаре, икесе Дума члены, берсе Чистай мулласы — дамелла иде. Болар арасында унбиш яшьлек малай булган кебек, кырык берлә илле арасындагы йортлы-җирле, бала-чагалы кешеләр дә бар иде. Боларның күбесе фәкыйрьләр булганга, төрмә ашларын ашап торалар иде. Төрмә ашының начарлыгын төрмәгә кереп чыкмаган кешегә аңлату мөмкин булмаганга, аның начарлыгын язар өчен диңгезләр кара булса, күкләр кәгазь булса да язып бетерерлек булмаганга, болар тугрыдан-тугры ач торалар иде. Төрмәнең эчә торган суы төрмәнең коесыннан гына алына иде. Бу су шулкадәр каты, шулкадәр куе иде, моның стаканына чиреге балчык дисәң дә ялган булачак түгел иде. Мамыйкларның озак торудан (алар биш айдан бирле утыралар) һәм буйлы ачлы-туклы торудан төсләре ямьсезләнгән, кыяфәтләренә ачлык төсе чыккан иде. Һәммәсе дә һәркөнне фельдшерга эч авырта, баш авырта дип зарланалар иде. Тагы, шуның өстенә, алар безнеке кадәр ике зурлыгы бүлмәдә 18 кеше торалар иде. Шуның өчен аларның бүлмәләрендә кич берлән параша исе берлән Алла ризасы өчен дә һаваның заты калмый иде. Тагы, шуның өстенә, бик күбесенең эче киткәнгә, камералар кеше тора торган бүлмәдән битәр әбрәкәйгә охшый иде. Аларның камераларының тугрысында коридорда да әллә нинди сасы дуңгыз абзарыннан чыккан исләр чыга иде. Төрмәдә буш камералар булса да, боларны мичкәгә төягән тозлы кыяр кебек, берсе өстенә берсен төяп, сасыда эштән чыгаралар иде. Кечкенә генә золымга да чыдый алмый торган, кешене мыскыл итүнең һәркайсы өчен эчтән хурлана торган минем күңелем моны күреп бик кайгырды. Ләкин боларга бертөрле дә ярдәм итәргә юлның юклыгы тагы кәефемне җибәрде. Мин боларның хәлләрен сорашып, фәкыйрьлекләрен

белеп, кайсына 20, 30, 50 тиен акчалар бирдем, ләкин минем үземнең дә акчам бик аз булганга, ул акчалар; аларның ихтыяҗына караганда ком сахрасына бер тамчы ягъмур кебек кенә булганга, күзгә күренмәенчә бетә дә китә иде. Мин, уйлап-уйлап, Казанга, Оренбургка, Мәскәүгә телеграм бирергә уйладым. Ләкин телеграм бирергә үземнең акчам булмаганга, ул фикерне беразга кадәр кичектердем.

Мин, төрмәгә килгәч, үземнең якыннарыма күрешергә килергә рөхсәт сорап жандармскийга телеграм биргән идем. Аңарга бик тиз җавап килде. Аны мин әйтеп өйгә хат та яздым. Ләкин өйдән шактый гына килмәенчә тордылар. Мин кергәннең икенче атнасында дүшәнбе көн әни берлән хатыным күрешергә килделәр. Мине алар янына керттеләр. Аларның икесенең дә күзләреннән яшьләр ага иде. Мин көлеп чыккач, алар да бераз ачылдылар. Мине бик каты кыйнаганнар дигән хәбәрдән бик куркуларын сөйләделәр. Иртәгесен тагы килергә булып киттеләр. Иртәгесен мин Казанга җибәрергә хат һәм телеграм язып бирдем, һәм дә хатынымны берәр атнага калырга куштым. Аларның сөйләүләренә караганда, мине волостной сходта уполномоченный итеп сайларга хәзерләнәләр иде. Шулай итеп, көннәр үтеп китте. Хатыным Казанга ике телеграм бирде! Ләкин берсеннән дә ашыгып акча килмәде. Чөнки андагы кешеләр иректә булганга һәм дә тамаклары бик тук булганга, мондагы ач кешеләрнең хәлләрен аңлау ихтималлары бик ерак иде. Шулай итеп, көннәр үтте, атналар үтте. Корбан гаете җитә башлады. Мин, төрмәгә тәмам өйрәнеп, укырга тотындым. Бүлмәмез бик тыгыз булганга, язарга-фәләнгә мөмкин түгел иде. Корбан гаете җитәр алдыннан без начальниктан гает өчен мәчеткә чыгарырга сорадык. Начальник, мин чыгара алмыйм, жандармскийдан сораңыз, диде. Без телеграм берлән жандармскийдан сорадык. Бөтен Чистай безнең гаеткә чыгуымызга ышанып көтәргә тотындылар. Гаеттән бер-ике генә көн элек безгә отказ килде. Иректәге кешеләр безне министрга телеграм бирик дип йөдәттеләр. Без аннан да шул җавап киләсен белгәнгә, акча әрәм итүгә риза булмадык. Чистай халкына гаеткә чыгармау бигрәк авыр булды. Үзләренең унбиш еллык муллаларын исерек учитель Зәңгәр Сәлах сүзе берлән

гаепсез-нисез ябып куеп та, гаеттән мәхрүм кылулары бик ачуларын китерде. Тагы, аңарга башка, шул көннәрдә генә губернский сәбәпсез-нисез дамелланың указы алынуын да халыкка белдерткән иде. Шуның өчен Чистайларның ачулары килүнең иге-чиге юк иде.

Гает җитте. Мөселман арестаннарын мәчеткә алып киттеләр. Алар кайсы ат урлаган гына булганга, кайсысы кеше генә үтергәнгә, кайсысы биш-алты кибет кенә басканга, безнең кебек үк куркынычлы түгелләр иде.

Шуның өчен төрмә начальствосы вә бөтен хәзерге Россияне идарә кылып килә торган кешеләр каршысында алар унбиш еллык мөдәрристән, Дума членыннан артыграк иде. Аларга бюрократларның ышанычлары боларга караганда күбрәк иде. Без, бер дә булмагач, ике көн күрешергә килергә рөхсәт сорадык. Начальник рөхсәт бирде. Гает көнне безнең өчен күңелсезрәк булды. Гариф абзый бу көнне көн буе үзенең моң тавышы берлән коддуси укып үткәрде. Дамелла берсе артыннан берсе өзелми торган намазларын, догалыкларын укып гомерен үткәрде. Мин камерадан камерага йөреп вакытны уздырдым. Төрмәдәге бөтен сәяси безне бәйрәм берлән тәбрик кылдылар. Чистайдан да тәбрикләр килде. Мин дә үземчә, шактый гына хезмәтем бар, дустларым бар, иптәшләрем бар дип, күңелемнән генә тәбрик көттем. Ләкин дустлар, танышлар, иптәшләр мондый вакытта үзләренең шатлыклы бәйрәмнәрен үткәрү берлән мәшгуль булгангамы, үзләренең мәсгуд минутларын минем тугрымда уйлап сәгадәтен киметмәс өчен, бервакытны үзләренең дустлары, үзләренең иптәшләре булган төрмәдәге бер кешене уйламадылар да күңелләренә кертмәделәр. Аның да күңеле барлыгы, аның да алар кебек үк бәйрәмнәр итәсе килсә дә, бюрократиянең золымы сайәсендә шул вакытларын зинданда үткәрергә мәҗбүр булуы хәтерләренә дә килмәде. Чөнки ул хәзер алар арасында юк иде, чөнки хәзер алар аңарга мохтаҗ түгелләр иде. Чөнки аның берлән алар арасында бик калын төрмә стеналары бар иде.

Сәгать 12ләрдә безгә Чистай кешеләре килә башладылар. Чистай төрмәсе бүген төрмәлектән чыкты. Бүген бу, бер зур әүлия зияраты кебек,

кешелеген югалтмаган һәр татарның килә торган урыны булды. Монда Чистайның күзгә күренерлек кешеләре һәммәсе килделәр. Туксан яшьлек картлар, ун яшьлек малайларга кадәр, халыкның рәхәтләре, халыкның ирекләре өчен җәза күрә торган үзләренең корбаннарын күрергә, аларны күреп шатланырга, аларны шатландырырга килделәр. Һәммәсе дә күңелләреннән әллә никадәр дустлык, әллә никадәр хәер хаһлык, әллә никадәр туганлык алып килделәр. Һәммәсе дә күзләреннән яшьләр агызып, үзләренең безнең өчен никадәр кайгырткannarын күрсәттеләр. Без елаган, яшьле карт бабайларны, еларга күзләре яшь берлән тулган яшьләрне үземезнең кәефемез берлән, үземезнең сүземез берлә юатып җибәрә идек. Һәммәсенә төрмәнең алар уйлаган кадәр үк начар түгеллеген, безнең тормышның бигрәк яхшылыгын исбат итә идек. Боларның берсе дә безнең сүземезгә ышанмасалар да, безнең кәефемезне күреп шатланыбрак китәләр иде. Бу ике көндә безнең берлә күрешергә килгән кешеләрнең күплеге Чистай төрмәсенең тарихында беренче эштер. Мондагы хезмәтчеләр капка ача-ача йөдәп беткән кебек, килгәннәрдән бәйрәм котлавы ала-ала да кесәләре тулып бетте. Ашарга-эчәргә китергән нәрсә берлән безнең дә камера бөтенләй тулды.

Бәйрәм үтеп китте. Без хәзер 15 нче гыйнвардагы волость сайлауларын көтә башладык.

*2 нче февраль, сәгать 10нар, кич.*

16 нчы гыйнварда иртә берлән сәгать уннарда тәрәзәдән безнең кияү берлән безнең авылның бер кешене күрдек. Мин чыгып, бик сорап күрешергә алдым. Алар мине сайлау хәбәрен китерделәр. Мине волостьта беравыздан сайлаганнар. Ләкин земский начальник бик кәефсезләнгән һәм дә, боздырмаенча калмыйм дип, Шәйхидән прошение бирдерде, диделәр. Мин төрмәдә булганга, әлбәттә, хәзер земский начальник, предводитель дворянства берлән тартышырга куәтем юк иде. Тагы, шуның өстенә, земский сүзе берлә, протоколларында да хата бар иде. Шуның өчен мине төшерүләре бик ихтимал

иде.

Шулай булса да, бүген бөтен сәясиләргә зур бәйрәм булды, һәммәсе мине тәбрик иттеләр. Без үземез дә бүген чәйне бер мәртәбә артык эчтек. Тагы берәр көннән Фуадның сайлануы да ишетелде. Берәр көннән бөтен Чистай өязендә яхшы татарлар сайлануы ишетелде. Озакламады, бөтен Чистай өязенең сайланган кешеләрен белдек. Сайлауларда русларның татарларга караганда наданраклыклары яисә куркаклыклары беленде. Руслар арасында карагруһлар да бар иде. Һәр нә исә, күбесе яңа фикерле халык яклы кешеләр иде. Элгәреге Дума члены Герасимовны сайлатмас өчен земский начальник, стражниклар берлән становой барганлыгы, шуның өчен аны сайлый алмаулары мәгълүм булды. Бу вакытта бөтен төрмәнең авызында сайлау сүзләре иде! «Кем сайланган? Нинди партия кешесе?» сөальләре, шуларга җаваплар берлән бөтен прогулка вакыты үтә иде. Хәзер һәммәмез, үземезнең төрмәдә иде берлән кереп киткән идек. Тагы 21 нче гыйнварда Чистайда шәһәр халкыннан сайлаулар булачак иде. Шәһәрдән сайланырга дип тәгаен кылынган кешеләрнең өчесе дә — ягъни Гариф Бадамшин, Иван Кунучев, доктор Дерагин төрмәдә булганга, боларның бүген-иртәгә әллә нинди хәйләләр берлән сайлау правалары алыну ихтималы булганга, төрлечә планнар корып куя идек. Һәм шул планнарны иреккә язып чыгара идек. Шәһәр сайлауларында мөселманнар бик зур роль уйнаганга, Гариф абзый мөселманнан ике кеше, рустан бер сул кеше кертергә уйлый иде. Бу фикергә русларның социалист революционерлары риза булсалар да, социал-демократлары разый түгелләр иде. Һәм дә мин дә бу вакытта, тавышлар бүленеп, карагруһлар җиңәр дип курка идем. Икенче мөселманны — дамелланы кую фарыз булганга, аның ризалыгы кирәк иде. Ул бу эшне бик үк мәслихәт күреп бетерми иде. Доктор Дерагин (кадет) безнең барымыздан да соң ябылганнан, без анда эшне бетердек. Дерагин, Димрат, Бадамшинга карар бирдек. Социал-демократлар да, безнең берлән дип, безнең һәр эшемезгә каршы килә иде. Без Чистайда татарлар тавышы берлән үзләренең членнары унбиш кеше дә булмаган ике кадетны җибәрергә риза булмый идек. Без иреккә

шулай кирәк, болай кирәк дип хатлар яза идек. Сайлау алдыннан Чистай исправнигы тагы дүрт-биш мөселманны ябарга хәзерләнгәнгә, эш башында йөри торган кешеләр бары да шәһәрдән шуып торалар иде. Русларның да сулларының кайсылары качкан, кайсылары коты очкан булганга, тышта, иректә кадетлар гына калганнар иде. Шуның өчен алар мөмкин кадәр мөселман тавышы берлән үзләренең ике кадетларын җибәрер өчен татарлар янында төлкеләнеп йөриләр иде. Һәм дә, аерылсаңыз — карагруһлар җиңә, дип, Иван Кунучевның правасы бетсә, ике кадет ясарга сүз дә алганнар иде. Сайлаудан берничә көн генә элек Кунучевның сайлану правасы алынды. Без тышка аның урынына тагы сул кешене күрсәтеп хат яздык. Ләкин кадетлар алдап-йолдап аның урынына үзләренең Димратларын тыкканнар. Фуад килгәч, без аңарга берьюлы ике эш куштык. Берсе минем эшемне белешү, берсе ике кадет сайлатмау иде. Ул тиз генә минем эшемне белешә алмады, ике кадет сайлатмау өчен бик тырышса да, татарлар арасында бу фикер бик таралган булганга һәм дә хәзер, язуны алыштырсалар, күп халык бүленеп чуалу ихтималы булганга, аңарга каршы килә алмады. Тагы Фуадның үзенең дә эше бик шәп түгел иде. Чөнки Фуадның авылында бик зур сакаллы, бик кечкенә башлы бер татар Фуадны сайлатмыйча, үзе сайланасы килгәнгә, халык аны сайламый Фуадны сайлаганга, теге мужик куштаны бик хурланып Фуад өстеннән жалобы биргән. Һәм дә, һәр татар куштаны кебек, әллә ниләр алдап, аның өстеннән донос та ясаган иде. Шуның өчен Фуад үзе дә кыл өстендә генә тора иде. Һәм дә бик сакланып йөри иде. Сайланган-фәлән иткән дигән сүз Чистай полициясе өчен бер тиен дә тормаганга, ул награда алыр өчен яисә исправникның дәрәҗәсен үстерер өчен Думага сайлангач та ябудан чирканачак түгел иде. Шулар өчен минем эшем артыннан йөрүче һәм дә аны боздырмаска теләүче, бозылса, сәбәпләрен белешеп төзәтергә керешүче юк кабиленнән иде. Безнең ирекtәге кешемез бер Фуад булганга, без аңарга үзен төшертмәскә, мине төшертмәскә, ике кадет җибәртмәскә куша идек. Шуның өчен аның эше бик күп иде. Һәм дә бик авыр иде.

20 нче гыйнварда ул минем төшерелгәнемне язды. Шулай булса да,

өметләр бетмәгәнгә, минем өчен бик тырышырга тотындылар. Комиссиядәге кешеләрнең бик күбесе карагруһ тарафдары булганга һәм дә аның башы карагруһ генералы Якубович мине яптырыр өчен дә шактый хезмәтләр иткән кеше булганга, мине төшерүдән саклый алмадылар. Без инде, минем төшүемә разый булып, Фуадка үзе өчен һәм дә Чистайдан бер мөселман, бер кадет, бер сул китсен өчен тырышырга куштык.

Егерме берендә шәһәрдә сайлау башланды. Ләкин безнең теләгәнчә булмаенча, ике кадет куелганга, безнең бик кәефемез киткән иде. Шул хосуста төрмәдәге социал-демократлар берлән социалист-революционер арасында шактый гына тавыш та булган иде. Без сайлауларның нәтиҗәсен көтә башладык. Чөнки Чистай шәһәрендә староверлар бик күп булганга, алар һәммәсе октябристлар булганга һәм дә кадетларның Димратлары бер дә мәгълүм түгел кеше булганга, без боларның өчесенең дә чигүенә ышанып бетми идек. Кичкә таба безнекеләр чигә дигән хәбәр килде, ләкин катгый хәбәр түгел иде. Шул көнне, ничек булса да төнлә берлән беленер дип, без төн буе хәбәр көттек. Ләкин бернәрсә дә беленмәде. Иртәгесен сәгать берләрдә октябристлар чигелгәне мәгълүм булды, һәм дә сәгать дүртләрдә кемнең күпме тавыш алуы да беленде. Безнең күңелемезнең йөздән бере генә октябристлар чигелгәнгә шатланса да, үз тавышымыз берлән ике кадет җибәрүемез өчен күңелемезнең туксан тугыз өлеше кайгырта иде. Төрмәнең кешеләре барысы да социалистлар булганга, һәммәсе дә безнең кебек бер яктан шатланып, бер яктан кайгырып йөриләр иде. Социал-демократлар да үзләренең гаепләрен белгән кебек халыктан читтә йөрилә иде. Төрмәдәге кадет Дерагинга бүген бик зур бәйрәм булды. Ул үзләренең җиңүләренә чын күңеленнән шатлана иде. Вакыйган, шатланмаслык та түгел. Унбиш тавышлары берлән ике кеше үткәргәч ник шатланмасыннар?!

22 гыйнварда тагы бер хат алдык. Минем эшем бөтенләй бетмәгән икән. Хәзер әллә нинди юллардан төзәтергә телиләр, бәлки төзәтә алырлар, дигәннәр. Мин боларга, әлбәттә, ышанмадым. Алай да өмет дигән нәрсә тагы уяна башлады. Шулай итеп, бу көнне үткәрдек. Хәзер без Гариф абзый

Бадамшинны калдырыр өчен нишләрләр икән дип көтеп тора идек. Вакыйган, комиссия аны калдырыр өчен бик тырышачак иде. Чөнки ул төшерелгәндә, аның урынына октябрист городской глава китәчәк иде. Бу кабахәт старовер, Бадамшинны калдырып, үзе керер өчен әллә нинди усаллыклар кылырга да разый иде. Тагы Бадамшинны донос ясап яптыручы да шул кеше иде. Вакыйган, иртәгесен үк комиссиядә бик зур тавыш чыккан. Гариф абзыйны төшерер өчен карагруһлар бик тартыша башлаганнар.

22 нче гыйнвар шулай үтте. Кич берлән без яттык. Бу көн сәгать 12дән волостьтан сайлаган кешеләр арасында Казанга унөч кешене сайлау башланганга, без шул сайланудан хәбәр көтә идек. Минем дә правам кайтарылса, сайлануымда шөбһә юк иде. Тагы Фуадның өстеннән бирелгән прошениеләр мәгънәсезгә чыкканлыгы белдертелгәнгә, аның да сайлануында сүз юк иде. Шуның өчен бу көн без бик озак хәбәр көттек. Ләкин хәбәр булмагач, йокларга яттык.

Сәгать беренчеләрдә безнең ишекне кактылар. Без уяндык. Ишек ярыгыннан хат бирделәр. Без өчемез дә торып укырга тотындык. Хат Фуадтан иде. Әүвәлге хәбәре: мин тәмам төшерелгән идем. Икенчесе — Фуад сайланган иде.

Без, Фуадның сайлануына шатланып, минем төшерелүемне кайгыртырга да оныттык. Хатның теге ягын карадык. Тагы язу. Ләкин монысы соңрак язылган. «Мин сайланып беткәч һәм дә миннән соң биш кешене сайлагач, губернатордан, Фуад Туктаров авылында тормый икән, шуның; өчен аны төшерегез, дип телеграмм килде дә, мине төшерделәр»,—дип язган. Без, бу хәбәрне укыгач, яшен суккан кебек булып киттек. Чөнки бу эш сайлауларда законның аз гына да ригайә кылынмавын бедерә иде. Һәм дә Гариф абзыйны төшерү ихтималыны да бик якынлата иде.

Без урыннарымыздан торып, нишләргә белмәенчә, сөйләшергә тотындык. Безнең кайгымызның хәзер иге-чиге юк иде. Бу хәбәр безнең бөтен өметләремезне бозды. Бу хәбәр безнең Дума яхшы була дигән казыямезне

җимерде. Чөнки губернатор телеграм берлән һәр яхшы кешене чыгара барганда, әлбәттә, Думаның яхшы булу ихтималы юк иде. Гариф абзый кызыпкызып сүгә иде. Мин, сайлау эшләре шулкадәр бюрократларның үз кулларында булгач, бу сайлауларга да бойкот ясамау фикере хата түгел микән дип уйлый идем. Дамелла стенага сөялеп бер сүз дәшмәенчә уйлый иде. Аның йөзенә чиксез ачу килү, иксез хәсрәт, бик зур хурлану әсәре чыккан иде. Ул безнең Чистай өязеннән минем дә, Фуадның да китмәве өчен кайгырта. Безне төшерү правасы шундый карт бюрократлар кулында булуына хурлана иде.

Без бер-ике сәгать шулай нишләргә белми утырганнан соң, яттык. Беремез дә йокыга китә алмадык. Мин әйләнә- әйләнә йөдәп бетеп, сәгать бишләрдә генә йокыга киттем.

*4 нче февраль, сәгать 10 нар, кич.*

Иртә торганда баш авырый, күңел кайгырта иде. Без өчемез дә бик кәефсез идек. Өчемез дә бик зур өметләремезне югалткан идек. Торгач ук руслар берлән үземезнең  хәсрәтемезне бүлештек. Гариф абзыйның хәзер үзен утвердить итүгә тәмам ышанычы беткән иде. Безнең дә өметемез бик аз иде. Бөтен төрмәдә: «Монда болай булгач, бөтен Россиядә шулай инде. Алай булгач, Думаның начар булуында, Думаның карагруһ тарафлы булуында, Думаның халыкка зарарлы булуында шөбһә юк инде», —  диләр иде. Шуның өчен барысы да кайгырышалар, барысы да бу эшләргә исләре китә иде.

Бүген безнең төрмәдәге кенемезнең иң кәефсезе булды. Без алай-болай итеп сәгать 12ләргә кадәр гомер үткәрдек. 12дә безгә күрешергә килә башладылар. Фуад минем берлән күрешергә килде. Ул үзенең эшенең бөтенләй үк өметсез түгеллеген һәм дә губернаторның ул телеграммасы берлә сайлану правасын алу Дума хакындагы низамга хилаф булганга, мондагы карагруһ комиссиясенең, бигрәк тә предводитель дворянстваның усаллыгыннан гына төшерелүен сөйләде. Һәм дә, авылына барып, үзенең анда йорты-җире барлыгына приговор алып килеп, губернский комиссиягә

прошение бирәчәген белдерде. Безнең тагы бераз өметемез артты. Бүген тагы без Чистай комиссиясенең Гариф абзыйны төшерер өчен бик тырышуын белдек.

Бүгенге көндә төрмәдә бер ят эш булды. Ул да төрмәдән доктор Дерагинны чыгарулары иде. Чистай полициясе ноябрь башыннан бирле өязнең төрле тарафыннан Думага сайлауда тәэсире булырлык кешеләрне тотып япса да, моңынчага кадәр берсе дә чыгарылганы юк иде. Дерагин чыгарылуы халыкка тагы бераз өмет бирде. Күп кеше тиздән чыгарылуын көтә башлады. Ләкин, Дерагинны чыгарып, Гариф абзыйны калдыру тагы безнең күңелемезгә шөбһә төшерде. Без Гариф абзыйны ничек булса да бер юл берлә төшермәделәр микән дип уйлый башладык. Бу көннәргә Гариф абзыйга бик авыр булды. Күңеленә әллә нинди шөбһәләр килә иде. Тагы, шуның өстенә, аның бу арада тешләре бик сызлаганга, һәм дә тегеләй дә бер дә кәефе юк иде. Дерагинның чыгарылуы төрмәнең тормышына бертөрле дә тәэсир итмәде. Чөнки, бердән, ул соң гына кергәнгә, тәмам төрмә иптәше булып бетмәгән иде. Икенчедән, аның кадетлыгы һәрвакыт үзен башка сәясиләрдән аерып тота иде.

Сәясәт галәмендә ике атна бербуйдан әле буйга, әле аркылыга йөзгәннән соң, сәясәт сугышында бик күп өметләремез бетеп, үземезнең югалткан праваларымызны кайгыртып арып беткәннән соң, безнең күңелләр дә дулкыннан соңгы диңгез кебек тагы тынычлый башлады. Без тагы Гариф абзыйны, Фуадны Думага җибәрү өметләре берлән ләззәтләнә башладык. Думага баргач, аларга нинди партияләр берлә бергә хәрәкәт итүләре, нинди эшләр эшләргә кирәкләре тугрысында сөйләшә башладык. Шулай итеп, өч-дүрт көн вакыт үтеп китте.

Беркөнне өйләдән соң, сәгать 3ләрдә, яңа гына алынган гәзитәне укып (гәзитә төрмәгә кертелми, ләкин без итәк астыннан алып, һәркөнне гәзитә алып тора идек) торганда, бик кызуланып старший килеп керде. Мин бик тиз гәзитәмне сәке, астына ташладым. Керү берлән: «Бадамшин, сөенче, сине чыгаралар!» — диде. Безнең исемез китте. Гариф абзый: «Мин чәемне эчеп бетерим әле»,—дип, безнең берлә актык мәртәбә тышта нишләргәлеген

сөйләшмәкче булды. Ләкин старший һич ирек бирмәде: «Анда, конторда, хәзер начальник көтеп тора, алай булса, конторга төшеп кул гына куеп мен», — диде. Гариф абзый чыгып китте. Бер биш минуттан соң Гариф абзый, аның артыннан начальник килеп керде. Гариф абзыйга ясаган чынаягын да эчәргә ирек бирмәенчә, киендереп алып чыгып киттеләр. Мин коридорга чыгып сәясиләрнең һәммәсенә дә Бадамшин чыгарыла дип әйтеп чыктым. Барысы да чыгып күрешеп калырга теләгәнгә, ишекләрне дөбердәтергә тотындылар, ләкин берсен дә чыгармадылар. Без дамелла берлән боларның ут капкан кебек кыланып йөрүләренә исемез китте. Без хәзер тәрәзәгә мендек. Гариф абзый акыртын гына төрмә юлы берлән китеп бара иде. Бер атлаган саен бер артына карый иде. Безне тәрәзәдән күргәч, яулык селкә башлады. Без дә яулык селектек. Бөтен тәрәзәләрдән сәясиләр яулыклар бутый башлады. Гариф абзый, бер-ике мәртәбә тукталып торганнан соң, безнең күздән югалды. Моннан ун минут кына зур тимер йозак берлән бикләнгән Гариф абзый иреккә чыгып китте. Аның шулай тиз чыгып китүе, аның төрмәнең теге тарафында иректә күренүе безнең гакылга сыймый иде. Төрмә янындагы стражниклар аны тотып китерерләр кебек тоела иде. Ләкин аны яңадан тотып китермәделәр. Чистайда әллә никадәр стражник булса да, никтер аны тагы полициягә илтеп ябып куймадылар. Гаебе беткәндер диер идек, аның элгәре дә гаебе юк иде. Шуның өчен, гаепсез кешене ябып, кырык көннән соң гаепсез дип чыгарып җибәрүне безнең гакыл аңламый, безнең мантыйк сыйдырмый иде.

Ни булса булды, Гариф абзый иреккә чыкты. Ул хәзер үзе теләгәнчә йөри, үзе теләгәнчә тора, үзе теләгәнчә йоклый ала торган, звоноксыз-нисез чәй эчә ала торган, көненә ике мәртәбә поверкасыз гомер кичерә торган кеше булды. Ул качырмаенча гәзитә укый ала торган, өстеннән ун кадаклы йозак берлә бикләмәгән өйдә тора ала торган, надзирательләрнең әмерләреннән башка да теләсә кая бара ала торган, көннең теләсә кай вакытында саф һавада чыгып йөри ала торган кеше булды. Ул хәзер бу тар бүлмәнең сасы һавасыннан, бу сасы парашаның һәркөнне исен иснәүдән котылды. Ул бу сасы коридорның исеннән, бу былчырак бәдрәфнең кабахәтеннән котылды. Аның

хәзер урамда йөрүе, үзе теләгән вакытында капканы ачып чыгып, теләгән вакытында ябып керүе безгә гаҗәп төсле күренә иде. Чөнки безгә хәзер урамнарда кешеләр йөремиләр, капкаларда стражниклар саклап бикләп торалар кебек күренә иде.

Шулай итеп, без дамелла берлән икәү калдык. Дамелланың иртәдән үк бүген кәефе юк иде. Шуның өчен аның үзе берлән бергә кергән иптәшенең чыгып китеп, аның калуы тагы, әлбәттә, кәефе килергә сәбәп булмады. Аның кайгырганы үзенең өй җәмәгате өчен иде. Ул Гариф абзыйның чыгып, монын калуы аларга бик авыр булыр дип уйлый иде. Аларның тагы бик зур өметләрен җимерер дип хәсрәтләнә иде. Ләкин никадәр хәсрәтләнсәк тә, монда әллә нишләр хәл юк. Бу төрмә! Монда синең хәсрәтең, синең кәефен берлә эш йөри. Син үлсәң дә яисә синең күңелеңдә җәһәннәм утыннан кызу кайгылар булса да, болар вакытлары җитсә — поверка ясыйлар, вакытлары җитсә — ишекне бикләп куялар, вакытлары җитсә — парашаны кертеп куялар, бу—төрмә!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Миңа Гариф абзыйның чыгуы бер дә артык тәэсир итмәде. Чөнки үземнең бик тиз чыкмауны бик яхшы белгәнгә, төрмәдә тору ниятең бик еракка куйган идем. Гариф абзыйның чыгуы миңа бер яктан файда да итте. Мин шул көнне кич берлән үземнең төрмәдәге тормышымны язарга тотынырга муаффәкъ булдым. Чөнки ул юкка хәзер камерамыз шактый иркен иде. Кара, кәгазь куярга урын бар иде. Мин көндезен каралар, кәгазьләр табып эшкә керештем. Монда кара, кәгазь алыр өчен хосуси рөхсәт алырга, язганыңны бер начальникка күрсәтә барырга, язганың русча булырга кирәк булганга, мин, әлбәттә, рәсми сурәттә йөрмәенчә, аннан-моннан кәгазь, кара алып, урланып язарга тотындым. Урланып язуыңны белсәләр, хәзер язган нәрсәңне алып жандармскийга җибәреләчәк булганга, язу шактый авыр иде. Көннең һәр вакытында язарга мөмкин түгел иде. Көндезләрен начальниклары, старшийлары бик күп йөргәнгә, мин аяк асты шил булгач кына, поверкалар

беткәч кенә яза идем. Бу вакытта да ишектән бер кеше керүе, коридорда аяк тавышы ишетелүе минем фикеремне бүлдерә, каләмемне ташларга мәҗбүр итә иде. Тагы, шуның өстенә, язганнарны саклау да бик авыр иде. Монда төрмәдә сакласаң, тентү булса-нитсә, бөтен язганнарың харап булачак, бөтен хезмәт әрәм китәчәк иде. Шуның өчен боларны иреккә чыгарырга кирәк иде. Анда чыгару да итәк астында хезмәтчеләр аша һәм дә эшкә чыгучы арестантлар аша гына булганга, аларны да кай вакытларда тентеп чыгарганга, бу кәгазьләр иреккә чыгып җиткәндә җиде сугыш сафыннан котылган гаскәр кебек булалар иде. Шуның өстенә тагы, иреккә чыккач та югалмасын дип бик курка идем. Чөнки Чистай халкы һәммәсе безнең ничек торганны бик беләсе килгәнгә, һәммәсе дә укырга тырышачаклар иде. Укый-укый кулдан-кулга йөреп, башы югалуы да бик якын иде. Мин шуларның берсенә карамаенча яза башладым һәм дә тышка чыгарта  башладым. Моңынча әле андый-мондый каза ирешкәне юк.

*5 нче февраль, сәгать 10нар, кич.*

Язганымны күреп алганнары юк иде. Иреккә чыгарылганнары югалды дип хәбәр бирелгәне юк иде. Гариф абзый чыккач, февральнең башларында миңа эшемнең жандармскийдан чыгып, бер яктан губернаторга, икенче яктан прокурорга бирелгәне белдертелде. Мин 23нче декабрьдә арестовать ителсәм дә, бу көнгә кадәр минем эшемнең жандармскийда торуы миңа жандармнарның бик әһәмият бирүләрен, минем эшемне бик җентекләп тикшерүләрен белдерә иде. Мин Казанда вакытта минем фатирымнан бик күп кәгазьләрем, бик күп язган әсәрләрем алынган булганга, шуларны да карап, шуларның да барын бергә бутап, җыенысыннан әллә нинди жандармский боткасы ясауларында шөбһәм юк иде. Минем шикләнгәнем андагы кешеләрдән минем хакымда алган мәгълүматлары мине әллә нинди эшләргә бутап, мине Казанга алдырмасыннар фикере иде. Эш каялыгын миңа мәгълүм итүләре минем Чистай төрмәсендә калуымны белдерү булганга, мин бу яктан

шатлана идем. Тагы, шуның өстенә, минем эшемне икегә бүлеп, бер яктан мәхкәмәгә бирелүе, бер яктан губернаторның ихтыярына калдырылуы миңа сылтый торган гаепләрнең бик аз идекен, мәхкәмә алдында минем гаебемне исбат мөмкин түгеллеген белдерә иде. Шуның өчен мәхкәмә мине гаепсез тапса, алар губернаторның үз куәте берлән мине ссылкага җибәрергә юл хәзерлиләр иде. Миң моны бик яхшы аңласам да, аңарга бик исем' китми иде. Чөнки шул арада җыела торган Думаның халык яклы булуы шул арада алына торган телеграмнардан бик ачык мәгълүм иде. Шуның өчен Думаны куганча бюрократия бераз йомшап торачак иде, реакция кимиячәк иде дә, безне шул вакытларда чыгарачаклар иде. Әгәр Думаны тиз куып, безне чыгарырга өлгерә дә алмый башласалар, Дума өчен халык арасында тагы чуалулар башланачак иде. Табигый, бик зур арестлар башланачак, төрмәләрдә яңа сәясиләргә урын кирәк булачак иде дә, безне тагы кайсымызны чыгарачаклар, кайсымызны читкә җибәрәчәкләр иде. Шуның өчен хәзер миңа булачак җәзаның иң зурысы — мине читкә җибәрү иде. Россиядә хөрриятләр игълан кылынганнан бирле шул хөррияттән файдаланырга теләгән кешеләрдән илле мең кеше Себерләргә җибәрелгәнен бик яхшы белгәнгә, әлбәттә, мин мине Себергә җибәрәләр дип елап торачак түгел идем. Җибәрсәләр, китәчәк идем. Чыгарсалар, чыгачак идем. Себергә җибәрү тагы кеше арасына җибәрү булганга, мин, әлбәттә, анда да үз эшемдә булачак идем. Минем авызымны пичәтләп кую, каләмемне сындырып ыргыту мине үтермәенчә мөмкин булмаганга, әлбәттә, мин анда да язачак идем. Анда да үземнең фикеремне таратырга тырышачак идем. Шуның өчен читкә җибәрү мине үземнең хезмәтемнән аера алмаганга, аның өчен бик үк кайгыртып торырга тугры килми иде. Һәм мин бер дә кайгыртмый идем. Этап берлән бару шактый авыр эш булса да, этапта йөрегәндә бик күп мәшәкатьләр күрергә тугры килсә дә, бу мәшәкатьләр, бу авырлыклар һәммәсе дә минем киләчәк язуларым өчен бик кыйммәтле материал булачак булганга, монда да минем күргән зарарымнан иткән файдам артык булачак иде. Шуның өчен бюрократлар нишләсәләр дә, мин җиңгән булып калачак идем. Мин үз фикерем берлә мине җибәрүне уйлап куйганга, аңарга хәзерләнергә тиеш

идем. Шуның өчен мин Казанга хат язып, мөмкин кадәр шул «Зиндан”ымны бастырып сатып, акча хәзерләтергә тырышырга үтендем. Үземнең хатыныма юлга чыгарга хәзерләнеп торырга куштым. Әниләрне дә: «Җибәрсәләр дә, минем өчен бер дә авыр булмаячак», — дип, күңелләрене юата башладым.

Шулай иттереп, көннәр үтте, атналар үтте, безнең тормышта бер үзгәрү дә булганы юк. Без һаман дамелла берлән бер бүлмәдә, һаман элгәреге кебек көннәрне, кичләрне үткәрәмез. Элгәреге кебек күрешү көннәрдә Чистайдан килгән утызар-кырыгар кеше берлән күрешәмез. Элгәреге кебек поверкалар ясала. Элгәреге кебек парашалар кертелә, элгәреге кебек зур йозаклар берлән бүлмәләремез бикләнә. Тыш яктан караганда һичбер үзгәрү юк. Ләкин рухымызда бераз ару сизелә башлады. Дамелла бу көннәрдә бик начар йоклый башлады. Аның йокысы качты. Мин дә элгәреге кебек татлы йоклый алмый башладым. Ятканнан башлап торганчыга кадәр әллә нинди төшләр күреп, эштән чыга башладым. Төрмәнең һавасы, аның табигате акыртын гына безне җиңә башлады, без бер туктамаенча томау берлән авырый башладык. Бер туктамаенча борынымыз мыкырдап йөри башлады. Менә шулай итеп бүгенгә кадәр (7 нче февраль) тордык. Бу көн Гариф абзыйның Казанда Думага сайлануын ишетеп шатландык. Фуадның төшерелеп калдырылуы өчен бик кәефемез китте. Моннан соң тагы нинди кәефсез хәбәрләр ишетеләчәген киләчәккә багышлап, без һаман бер көйгә төрмәдә ятамыз.

* * *

Төрмәдә торганда Гариф абзыйның гомеренең иң күбесе авыру берлән үтте. Аның нервалары бик изелде. Ул бик тиз ачуы килә торган, бик кызулана торган булды. Кечкенә генә дә суык тию аны бөтенләй авыруга саптыра торган булды. Тагы, шуның өстенә, теш сызлавы аны өчәр көн бербуйдан ятып торырга мәҗбүр итә иде. Елның начарлыгы, сәүдә эшләренең бик авырлыгы аның тагы кәефен җибәрә иде. Чөнки аның кибетендә караучысы булмаганга,

төрмәдә яткан һәр көн аңарга материальный да зарар китерә иде. Чыгуның очы күренмәве, әлбәттә, аның кәефе китүен тагы арттыра иде. Шуның өчен төрмәдә яту безнең барыбыздан битәр Гариф абзыйга авыр булды.

Дамелланың эше башкача иде. Аның сәламәтлеге яхшы булганга, табигате сабыр булганга, ул һәр авырлыкларны бер дә авырсынмаенча күтәрә иде. Ул үзенең ябылуына, үзенең указы алынуга исе китми иде. Үзенең ябылуының халыкка тәэсире бик зур булуына, халыкның бюрократиягә ышануының кимүенә сәбәп булганга, ул ябылудан бер дә зарар күрми иде. Аның кайгырткан нәрсәсе үзенең өй җәмәгатьләре иде. Вакыйган, аның өй җәмәгатьләре кайгыртмаслык та түгел иде. Аның өендә берсеннән-берсе кечкенә алты бала аның хатынының кулына калган иде. Хатыныннан башка аларны караучы өйдә беркем дә юк иде. Тагы, шуның өстенә, алар һәммәсе дә һәркөнне бүген чыга, бүген чыга дип көтеп, чыкмый калгач, яңадан кайгыртырга тотыналар иде. Үзенең якыннарының кайгысын күрү, аларның шул хәсрәтләрен бетерергә йә киметергә ярдәм итә алмау, әлбәттә, дамелланың кәефен җибәрә иде. Тагы, шуның өстенә, күрешергә килгән чит кешеләр аның кәефен бик җибәрәләр. Бу кешеләрнең иң күбесе хәкыйкатән дамелланы кызганучылар булганга, алар кызганган кеше өчен елауны гадәт итеп алганга, дамелланы күрү берлән, дамелланың кайгыларын сөйләп-сөйләп еларга тотыналар иде. Әлбәттә, үзләренең бу эшләре берлән дамелланың йөрәгендә яшеренеп яткан кайгыларын уяталар иде. Кайсылары тагы, бик гакыллы булган булып, дамелланы бик юаткан булып: «Юк, хәзергә кайгырырга ярамый! Чыгаралар, шул көндә чыгаралар, менә күреп тор, чыгаралар!» — дип, дамелланы тиз көндә чыгарырга өметләндерәләр иде. Әлбәттә, алар вәгъдә кылган көннәр җитә иде. Үтә иде. Алар берлән бергә дамелланың тиз чыгарга өмете дә бетә иде. Килгән кешеләр тагы яңа күз яшьләре алып киләләр, тагы яңа вәгъдәләр берлән юатмакчы булалар иде. Шуның өчен дамелла күп көнне күрешүләрдән соң бик кәефсез була иде. Аңа иректән килгән шул кешеләрдән аерылып калу авыр тоела иде. Аларның аны гакылсыз бала кебек итеп, юк сүзләр берлән юаткан булып маташулары аңарга

мыскыл иткән кебек тоела иде. Төрмә тормышының аның өчен авыр ягы булса, ул да — аның русча рәтләп сөйли белмәве һәм дә сөйләгәнне аңлый алмавы иде. Шуның өчен ул без сөйләшеп көлешкәндә, кычкырышканда аңламаенча тик тора иде. Шуның өчен ул төрмәдә үзенең хиссиятен, үзенең уйларын бездән башка кешеләр берлән бүлешә алмый, үзенең шатлыгын, хәсрәтен башкалар берлә уртаклаша алмый иде. Минем үземнән соң иректә кешесез-нисез магазиным калмаганга, төрмәгә кергәннән соң указым алынмаганга, әлбәттә, минем төрмәдә югалткан нәрсәм бөтенләй башка иде. Иткән зарарым бөтенләй икенче төрле иде. Өйдәге җәмәгатем, әтиләр, әниләр, туганнарым, хатыным минем өчен кайгыртсалар, алар минем ябылуымны ике елдан бирле көтеп килгәнгә, әлбәттә, бу кайгы аларга дамелла җәмәгатьләре кебек үк авыр тоелмаган иде. Тагы, шуның өстенә, минем үземнең алар берлән күрешкәндә һәрвакыт ачык булуым аларның күзләренә тулган яшьләрен, күңелләренә җыелган хәсрәтләрен бөтенләй туздырып җибәрә иде. Шуның өчен алар миңа күз яшьләре төяп килеп, минем күңелемә үзләренең хәсрәтләрен аударып китмиләр иде. Алай булса да, мин алар өчен бераз кайгырта идем. Килгән вакытта мөмкин кадәр аларны үз янымнан шат иттереп чыгарырга тырыша идем. Минем күбрәк кызганганым хатыным иде. Чөнки аның миңа килгәненә өч ел булса да, ул шул өч ел эчендә бер дә рәтләп минем берлә тора алганы юк иде. Бу гомернең күбесендә мин качып йөргәнгә, ул ялгыз торырга мәҗбүр булган иде. Тагы быел бер ай тормас борын да мине төрмәгә япкач, тагы ялгыз калган иде. Шуның өстенә, киләчәктә аңарга тагы әллә нинди этапларда баруларны, төрмәдән төрмәгә күчеп йөрүләрне хәзерләп торганга, вакыйган, аның хәле кызганыч иде. Бу эшләргә барысына да мин сәбәп идекемне белгәнгә, әлбәттә, мин аның алдында үземнең бик зур бурычлы идекемне белә идем. Шуның өчен аны кызгана идем.

*7 нче февраль, сәгать 10нар, кич берлә.*

Минем икенче кайгым — шундый әһәмиятле вакытта Россиянең идарә

мөстәкыййләсенең актык манзаралэре бөтен галәмнең күз алдыннан үткәндә үземнең төрмәдә ятып, бер эш эшли алмавым өчен иде. Тагы төрмәдә үземнең теләгән китапны укып булмау, үзең теләгәнчә язып булмау минем төрмәдәге гомеремне әрәм гомергә хисап итәргә мәҗбүр итә иде. Шуның өчен мин үземнең төрмәдә торуым өчен кайгырмасам да, төрмәдә вакыттагы гомеремнең әрәм булуы өчен кайгыра идем. Моңарга башка, төрмә минем исәнлегемә дә шактый гына зарар итәчәген, минем элгәредәй йомшак нерваларымны изәчәген белгәнгә, бу тарафтан да бераз кайгырта идем. Бу хәсрәтләрнең һәммәсе кайгыртырга яраткан кешегә кайгыртырлык нәрсәләр булсалар да, мин кайгыртып кына кайгы кимемәгәнне бик яхшы белгәнгә, кайгыртмаска уйлап куйган идем. һәм кайгыртмый да идем.

Төрмәдә бездән башка егермегә якын рус сәясиләре һәм дә җир эшләре берлә кергән 25 ләп авыл кешеләре бар иде. Бу соңгыларының ябылулары сәясиләр кебек булса да, аларның эшләрен сәясиләрнеке кебек жандармнар кулына бирелсә дә, безнең аларга сирайәт итүемездән куркып, аларны мөмкин кадәр безнең берлә бергә булудан тыярга тырышалар иде. Аларны безнең берлә йөрергә чыгармыйлар, аларны үзләрен генә бер камерада аерым тоталар иде. Башка сәясиләр күбесе учительләр иде. Калганнары төрлесе төрле ак эштәге кешеләр иде. Болар үзләренең фикерләре берлә социалист-революционерлар һәм дә социал-демократларга бүленәләр иде. Кайсылары бер партиянең дә программасын рәтләп белеп бетермәгән партиясез социалистлар иде. Болар арасында бәгъзе мәсьәләләр мондагы социалист-революционерлар да, социал-демократлар да, үзләренең төрмәдә идекләрен онытмаенча, төрмә эшләренең һәммәсендә дә бергә хәрәкәт итәләр иде. Без кергән вакытта сәясиләрнең бик күбесе фәкыйрьләр булса да, хәзер Чистайдан ярдәм килә башлаганга...... хәзер начар булса да, барысының да ашарларына бар, барысының да чәй-шикәрләре вә башка кирәкләре җитеп тора иде. Ләкин крәстиәннәрнең хәлләре көннән-көн начарлана бара иде. Читтән килгән ярдәм аларны барысын да тәрбия кылырга җитәрлек булмаганга, үзләренең бер тиен акчалары юкка, алар ачлы-туклы гомерләрен үткәрәләр иде.

Шуның өчен аларның хәлләре, алар арасында төрле авырулар күбәя бара иде. Безнең аларга иткән ярдәмемез бик аз булганга, аларга җитәрлек ярдәм итәргә акча булмаганга, без теләр-теләмәс аларның ачлы-туклы торуларына шаһит булып тора идек. Моңарга каршы бер юл берлә дә ярдәм итәргә чара таба алмаганга, мин бик кайгыра идем. Үземнең тук булып, аларның ач торуларына вөжданым газаплана иде. Шуның өчен мөмкин кадәр аларга ярдәм итәргә тырыша идем вә башкаларны да шул ярдәмгә димли идем.

Төрмәнең хезмәтчеләренең, надзирательләренең безгә караулары элгәрегә караганда бөтенләй үзгәрде. Без кергәндә иртәдән алып кичкә кадәр бертуктамаенча сүгенеп тора торган надзирательләр чәй эчәргә, аш ашарга, сәгатьләп сөйләшеп утырырга кертә башладылар. Без хәзер, нумирдагы кебек, бер-беремезгә чәй эчәргә, аш ашарга, ләскит сатарга кунакка йөри башладык. Без хәзер төннең шактый соң вакытларында бәдрәфкә ачтырып чыга башладык, сәясиләрнең күплеге бөтен төрмәгә дә тәэсир итте. Безнең югарыгы этажда хәзер элгәреге кебек бертуктамаяча шпаналар сүгешеп тормыйлар. Безнең коридорда хәзер сүгенү тавышлары бөтенләй ишетелми башлады. Шпаналар, тоз күленә төшкән ишәк кебек, үзләре дә яртылай сәясигә әйләнделәр. Хәзер элгәреге мәгънәсез урынына башка җырларын җырлый башладылар. Элгәреге ботка өчен, лампа өчен тартышулар урынына, җир мәсьәләсе хакындагы низагълар, партияләр хакындагы моназарәләр ишетелә башлады. Кыскасы гына, төрмә хәзер элгәреге бертуктамаенча кабахәт сүзләр ишетелеп тора торган төрле каракларның, кеше үтерүчеләрнең җыелган җирләреннән битәр бер мәктәпнең пансионына яисә студентларның тора торган ярлы нумирларына охшый башлады. Нуми-рыннан, пансионнан аермасы булса шул, ишекләрнең йозаклар берлә бикләнүендә, тәрәзәләрдәге тимер рәшәткәләрнең бер дә кирәкмәгән урында торуында һәм дә көне-төне револьвер таккан кешеләрнең, ни диптер, безне саклап торуларында иде. Без хәзер боларның барысына да өйрәнгәнгә, боларның берсе дә безгә искиткеч куркынычлы нәрсә кебек тоелмый иде. Төрмәнең начальствосы бик йомшак булганга, башка төрмәләрдә төшкә дә керми торган правалар берлән без монда

билфигыль файдаланып торганга, безнең берлә төрмә начальствосы арасында низагълар бер дә булмый иде. Башка төрмәдәге кебек монда тентүләр-фәләннәр булмаганга, без үземезгә кирәк һәрнәрсәне камераларымызда саклый ала идек. Һәркөнне кебек без иректән хәбәр алып тора идек. Һәркөнне гәзитә укый идек. Тагы монда күрешергә кертүләр дә бик прастуй иде. Күрешергә рөхсәт бирелгән кешегә күрешү көнендә никадәр кеше килсә дә, мин карендәш дисә, кертәләр иде. Шуның өчен безнең хәлемез башка төрмәләрдә ята торган иптәшләремезнең хәленә караганда бик күп артык иде. Тагы, шуның өстенә, шул көннәрдә җыела торган Дума да безгә төрмә начальствосының йомшак мөгамәләсенә бик зур ярдәм итә иде. Думаның якынлашканы саен алар йомшара баралар иде. Сайлауларда суллар җиңү беленгән саен аларның безгә карашлары үзгәрә бара иде... Тагы шуны да онытырга ярамый, шул көннәрдә төрле сәяси вакыйгалар безнең хәлне тиздән яхшыртып җибәрде. Без әйтү берлә безгә еракта‌н йомшак су китерә башладылар. Старший, йомшак тотасың дип, надзирательләрне йөдәтми башлады. Ул безнең берлә үзе яхшы мөгамәлә кылырга тырышып йөри башлады. Кечкенә генә бер эштә дә үзенең либераллыгын күрсәтергә тырыша башлады (бугай).

Менә без, шулай итеп, һаман әле төрмәдә торамыз. Тагы кайчанга кадәр торуымыз, тагы ниләр күрүемезне күрмәстән борын язарга мөмкин булмаганга, мин шуның берлә әлегә язуны тәмам итәм.

*8 нче февраль, сәгать 9, кич берлә.*

Әллә кичә «Зиндан»ны тәмам итеп куйгангамы, бүген язарга тагы яңа эш чыкты. Бу эш ирекtәге кешеләргә бер дә әһәмиятсез вакыйга булса да, төрмәдә нервалары ватылган кешеләргә шактый тәэсир итә торган эш булганга вә безнең шактый ук кәефемезне китәргәнгә, язмакчы булам. Без Гариф абзыйны сайлануын ишеткәч үк көтәргә тотынган идек. Кичә Гариф абзыйның кич берлән кайтачагын белдерделәр. Шуның өчен бүген көн буе без Гариф

абзыйны көттек. Ул аннан яңа хәбәрләр алып кайтыр дип, ул безгә хәзер ирекнең хәлен белдерер дип, ул безнең Думага нинди кешеләр сайланганны сөйләр дип ике күземез берлә көтә идек. Көн буе көтеп, килмәгәч, төрле шөбһәләргә дә төштек. Ахырдан без прогулкада вакытта, сәгать дүртләрдә, Гариф абзый килә диделәр.

Озак үтмәде, ул килеп җитте. Бөтен сәясиләр үзләренең ун көн элек кенә чыккан иптәшләрене Дума члены итеп күрергә дип капка янына җыелдылар. Капка ашасыннан барымыз да исәнләштек. Старший чыгып, начальниктан кертергә рөхсәт сорарга китте. Без менә хәзер кертәләр дип көтә башладык. Бераздан старший килеп, начальник рөхсәт бирми, диде. Без Гариф абзыйга, үзең барып сора, дидек. Гариф абзый үзе китте. Бераздан соң килеп, начальник йоклый дип мине кертмәделәр, диде. Безнең барымызның да бик ачуымыз килде. Гариф абзыйның да ачуы килүе билгеле иде. Ул капка ашасыннан гына сайлауларның яхшы булуын, Думада сулларның бик куәтле булачагы күренүен сөйләп, иртәгә килергә вәгъдә кылып китте.

Гариф абзыйны кертмәү бөтен сәясиләрнең ачуын китерде, бигрәк минем кәефемне җибәрде. Мин үземнең төрмәдә идекемне, шуның өчен үзем күрергә теләгән кешене күрә алмавымны, иректәге кешеләрдә һич әһәмияте булмаган бер кеше берлә сөйләшү правам да төрмә начальникларының кулында булуы мине бик хурландырды. Бу эш минем күңелемдә ябылып яткан һавалылыгыма тукынды. Мин нишләргә белмәенчә, ачуымнан кая бәрелергә урын таба алмаенча бик озак йөрдем. Эчемнән әллә ниләр уйлап бетердем.

*11 нче февраль, сәгать 10нар, кич.*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Тагы әле бетмәгән икән, кичә тагы яңа эшләр булды. Берсе —10 нчы февраль булганга, 10 нчы февральдә миңа егерме тугыз тулганга, минем туган бәйрәмем булды. Иптәшләр барсы да мине тәбрик иттеләр. Сәгать уннарда мин аларның иң якыннарын чакырып чәй эчердем. Өйләдән соң, сәгать 3ләрдә, мине кунакка чакырдылар. Мин аларга барып чәй эчтем. Бүләк бирү-фәлән

итү, әлбәттә, төрмә булганга, булмады. Алай булса да, бүген минем өчен бәйрәм төсле үтте. Мин моңынча да үземнең туган көнемне бәйрәм итәргә теләп йөрсәм дә, моңынча төрле сәбәпләр берлә бу теләгемне булдыра алганым юк иде. Быел беренче мәртәбә уларак, төрмәдә утызга чыгуымны бәйрәм иттем.

Икенче вакыйга — кичкә йөрергә чыкканда иптәшләрдән берсе конторга кереп үзенең эше тугрысында прошение язарга сорады. Капка ачучы: «Хәзер начальник та юк, старший да юк», — дип, кертмәде. Ул иптәшнең ачуы килеп, бик каты звонок бирә башлады. Шул арада контордан мылтыгын күтәреп стражник чыкты. Һәм дә әлләниләр әйтеп, ул иптәшне сүгә башлады. Ул каршы сүгешкәч, бик гайрәтләнеп: «Ә, әле синең ялгыз бүлмәдә утырасың килә икән. Без сине өйрәтермез!»—дип, старшийны эзләргә чыгып китте. (Ул иптәш әллә кайчаннан бирле ялгыз бүлмәдә утыручы иде.) Озак үтмәде, стражник старшийны алып керде. Һәм дә бик гайрәтләнеп-гайрәтләнеп сөйләргә тотынды, бөтен сәясиләр хәзер капка янына җыелып җиттек. Һәммәмез бер кеше кебек стражникка бәйләндек. Стражникның төрмә эшенә катышырга хакы юклыгын сөйләп, аның иптәшне сүгүе өчен протокол язарга требовать иттек. Стражникның безнең иптәшне һәм безне бераз өйрәтә ала алмавы өчен, әлбәттә, бик кәефе китте. Үзенең кыйнау правасының бөтен җирдә тигез, бөтен халык өчен гомуми, бөтен Россиянең гражданнарына тугрыдан-тугры, бөтен мәхкәмәләрдә яшерен дип игътикад кылган стражник, әлбәттә, үзенең бүген кыйный алмавы өчен кәефе китте.

Ул, старшийга да карамаенча үзенең мөкаддәс вазыйфасын үтәмәкче булса да, безнең ялтыраган күзләремездән, йомарлаган йомрыкларымыздан куркып, кереп китте. Ул кергәч, без барымыз да шул мәсьәлә хакында сөйләшергә тотындык. Стражникның бу эше барымызның йөрәгенә тукынган иде. Барымызның да төрмәдәлекемезне хәтеремезгә төшергән иде. Стражникның бу эше кырмыска оясына таяк тыккан кебек булып, безнең йоклаган ачуларымызны уятты. Безгә әллә никадәр гайрәт бирде. Без

кызуланып-кызуланып шуның хакында вә полиция хакында сөйләргә тотындык.

Бу кечкенә генә вакыйгага безнең бик ачуымыз килүе безнең нерваларымызның да шактый гына йомшарганлыгын белдерә иде. Без, начальник килеп, протокол язачагына вәгъдә алып, прогулканы бетереп, үз бүлмәләремезгә кердек. Тагы үз бүлмәләремездә көндәге кебек тора башладык. Хәзер без, Гариф абзый чыкканнан бирле, чәй йокыга зарар иткәнгә, көненә икедән артык чәй эчмәскә тырышамыз. Бүген, шулай итеп, кич берлә чәй эчмәдек. Мин үземнең Казан төрмәсендәге ятучы иптәшләргә багышлап «Корбан гаете» дигән бер нәрсә яздым («Тавыш» гәзитәсенең беренче номерында басылды). Дамелла аны укып чыкты. Аның хакында сөйләштек тә, сәгать 12 ләрдә йокыга яттык.

Сәгать ничә икәнен белмим, безнең ишек шалтырап ачыла башлады. Мин сикереп тордым, дамелла да уянды. Ишектән старший берлә хәзер начальник урынына калган околоточный, дамеллага карап: «Сезгә өйгә кайтырга!» диде. Без сикерешеп тордык. Тагы кемне чыгаралар икән дип, боларның аяк эзләре кая киткәнне көтә башладык Аяк тавышы Кунучевлар камерасы тугрысына туктады. Алар камерасында кеше күп булганга, кайсысын чыгаралар икән дип көтә башладык. Аларның камералары гөрләргә тотынды. «Кунучев!» «Кунучев!» дигән тавыш ишетелә башлады. Бер минутта бөтен төрмә уянды төрмә гөрләргә тотынды. Дамелла бик тиз киенде. Мин аңарга 11 нче февральдә язган «Зиндан»ның ахырын һәм «Корбан гаете» дип язган нәрсәләрне биреп чыгардым. Дамеллага «Зиндан» хакында Казан берлә белешергә һәм дә «Корбан гаете»не «Казан мөхбире»нә басарга җибәрергә куштым. (Бу вакытта үземезнең гәзитәмез юк иде.) Алар чыгып киттеләр. Мин сәгатьне карадым, сәгать дүртенче ярты иде. Мин тәрәзәгә мендем. Дамелла берлә Кунучев акрын гына китеп баралар иде. Алар артларына карый-карый гына күздән югалдылар. Мин бик озак йоклый алмаенча яттым. Часть сәгате бишне суккач кына йокыга киттем.

Иртә торгач та мин руслар бүлмәсенә Кунучев урынына күчтем. Өйләдән соң минем берлә күрешергә бик күп кешеләр килделәр. Чистайларның, дамелланың чыгуына бәйрәм ясап, кибетләр ябуларын сөйләделәр. Шул шатлык хөрмәтенә төрмәдәге фәкыйрьләр өчен акча җыюларын да сөйләделәр һәм миңа да акча китерделәр. Кунучев та күрешергә килде. Ул да руслардан җыеп акча китерде, безнең бердән йөз тәнкәләп акчамыз булды. Шуннан соң акчадан яхшырак файдаланыр өчен без «коммуна» (бергә, бүлешмәенчә ашау-эчү) ясарга карар бирдек. Һәм дә төрмәнең начальнигыннан үземезнең һәм дә җир өчен кергән авыл халкын ашатырга тотыла торган акчаны сорый башладык. Начальник безгә— сәясиләргә көненә бишәр тиен (төрмә ашын ашамаган кешенең простоена 5 тиен, мирзасына 10 тиен биреләдер) бирергә вәгъдә кылса да, авыл халкына бирмәвен катгый сурәттә белдерде. Без авыл кешеләренә, үзләре чынлап сорасалар, без аларны требовать итеп алыр өчен голодовкага кадәр барачагымызны белдердек. Ләкин алар үзләре алай каты иттереп сорый алмадылар. Шуның өчен ул мәсьәлә шулай тавышсыз-тынсыз гына бетте.

Без үзара «коммуна» ясадык: Эш бетерә башладык. Шул вакытларда начальник Казаннан барып кайтканга, безнең төрмәне тагы кыса башладылар. Безнең берлә төрмәнең начальствосы арасында тагы кычкырышлар китә башлады. Мин хәзер «Отпавший» исемле бер пьеса язарга хәзерләнә башладым. Беркөнне пьесаның пәрдәләрен бүлеп, планын бетереп, язарга гына тора идем, старший кереп безнең бүлмәдә тентү ясый башлады. Бездә әллә никадәр әйберләр булганга, китаплар, гәзитәләр, кәгазьләр алып чыкты. Һәм дә минем «Отпавший»ымның да планын алып чыкты. Безнең тагы төрмә начальствосы берлә арамыз бозылды.

Шулай итеп, дүрт-биш көн үтте. 17 нче февральдә минем берлә күрешергә дип әни берлә хатыным килде. Алар иртәгә дә күрешергә килергә вәгъдә кылып киттеләр. Бу көн тагы шулай үтте. Тагы кич булды. Кич сәгать сигезләрдә ике иптәшемезне конторга чакырып, Пермь губернасының ерак өязләренә — берсен ике елга, берсен бер елга себергә җибәрелүләрен

белдерделәр. Боларның берсе 17 яшьлек, берсе 16 яшьлек малайлар гына булганга, кылган эшләре дә бер дә булмаганга, болар өчен бу җәза бик авыр иде. Шуның өчен бөтен төрмә бүген шул эш берлә, шул уй берлә мәшгуль булды. Без бөтен камерамыз берлә ссылкага җибәрәләр дип хөкем итеп куйдык. Әгәр үз ихтыярымыз берлә булса, кайларга китәргәлекләрен уйлаштык. Этапның юлын тикшерештек. Шулай итеп, бик озак утырганның соңында, сәгать 12ләрдә яттык.

Мин бер дә рәтләп йоклый алмадым. Шулай иттереп, йоклар-йокламас яткан вакытта безнең ишек шалтырый башлады. Без барымыз уяндык. Ул ара да булмады, начальник кереп: «Исхаков, өйгә!»—диде. Мин сикереп тордым, иптәшләр сикерешеп тордылар. Тегеләр тагы икенче бүлмәләргә дә кереп әйттеләр. Без хәзер минем берлә өч кеше чыгарылганны белдек. Бөтен төрмә уянды. Төрмә тагы гөрләргә тотынды. Мин барсы берлән дә күрешеп, иртәгә килергә вәгъдә кылып чыгып киттем.

Чыккач ук минем әүвәлге уем очраган городовойлардан качу иде. Чөнки алар, күрсәләр, тагы мине частька илтеп ябарлар кебек тоела иде. Мин извозчикка барып җиткәч үк әниләрнең торган фатирына яллап киттем. Озакламаенча кайтып та кердем. Әниләрнең исләре китте. Алар үз күзләренә үзләре ышанмый иде. Аларның шатлыкларының исәбе-хисабы юк иде. Без барымыз, йоклый алмавымызны белгәнгә, чәй эчәргә тотындык. Бик озак чәй эчеп, сәгать 5ләрдә генә бер сәгать йоклап алдык. Иртә торгач, бөтен Чистай күрешергә килә башлады. Мине харчевняга чакырдылар. Анда мине 150ләп кеше көтеп тора икән! Алар берлә, барсы берлән дә күрештем, барсына да рәхмәтләр укыдым. Тагы әллә ничә төшләргә барып, кичкә таба төрмәгә иптәшләргә бүләкләр алып күрешеп килдем. Әниләр өйгә кайтып киттеләр, мин хатыным берлә ат яллап кайтырга калдым. Шулай булса да, күрешүченең күплеге аркасында без кичке сәгать унсыз Чистайдан чыгып китә алмадык.

Сәгать 12ләрдә Яуширмәгә кайтып җиттек. Иртәгесен минем берлә күрешер өчен тагы бөтен Яуширмә килде. Тагы әллә никадәр күз яшьләре түгелде, тагы әллә никадәр шатланылды. Мин тагы ирекккә чыгып тора

башладым. Тагы мин бүген ябалар, бүген ябалар дип көтә башладым.

## Хатимә

Шул язганнарым берлә бу әсәремне бетермәкче булам. Чөнки бу язылганнардан төрмәнең ничек идеке, төрмәдәге тормышның ни төрле булдыгы беленә дип уйлыйм. Шулай булса да, төрмә хакындагы үземнең фикеремне кыска гына иттереп тагы әйтмәкче булам.

«Ирек»тәге кешеләр төрмәгә керү түгел, төрмә дигән сүзне ишеткәч үк котлары оча, тәннәре калтырый башлый, йөрәкләре еш-еш суга башлый. Ирektәге кешеләр төрмәне дөньяның җәһәннәме дип уйлыйлар. Ирektәге кешеләр төрмәдә рәтләп ашап-эчеп, яхшылап йоклап булмый дип уйлыйлар. Ирektәге кешеләр төрмәдә ятарга, утырырга урын юк, бер-берең берлә сөйләргә рөхсәт юк, күрешергә ирек юк дип беләләр. Ирektәге кешеләр төрмәдәге кешеләрнең аякларын, кулларын богаулыйлар, теләгән саен ке- реп-кереп кыйныйлар дип фараз кылалар. Шуның өчен безнең халык төрмәдән бик куркалар. Төрмә дигән сүз ишеткәч үк: «Хакыннан, нахакыннан сакла!» — дип дога кылырга тотыналар. Вакыйган, төрмә шулкадәр куркынычлы урынмы? Вакыйган, төрмәнең начарлыгы кешене куркытып, үзе ышанган эшне эшләүдән тыярлыкмы? Һич юк! Төрмә, әлбәттә, куркаграк кешеләрне куркытыр өчен, йомшаграк кешеләрне кылган эшләреннән тәүбә кылдырыр өчен ясалган. Ләкин төрмә яратылганнан бирле хисаплаганда, төрмәдә ятудан туеп бер кергән кеше икенче ятудан куркып, үзенең эшли торган эшләреннән тәүбә кылганы, үзенең сөекле хезмәтеннән баш тартканы бер дә юктыр, булса да, бик аздыр. Төрмәгә ябылган вак-төяк караклар, төрмәдәге зур караклардан өйрәнеп, аларның әллә никадәр дәресләрен тыңлап, чын карак булып чыгалар. Болар термәдән чыкканның икенче көнендә үк тагы урларга тотыналар. Төрмәдән курку боларны бер эштән дә тыя алмый. Сәясиләрнең йомшаграклары иптәшләрен күреп үзләрен тотарга өйрәнәләр, төрмәнең

начальствосы берлән тартыша-тартыша табигатьләре ныгый, куркулары кими, аларның наданраклары әллә никадәр нәрсә укыйлар. Әллә никадәр сүз ишетәләр. Моңынчыга кадәр кеше әй- тмештән генә с. р. яисә с. д. булып йөргән кешеләр чынлап партия кешесе булып чыгалар. Төрмәдә вакытның йокыдан калганы бар да буш булганга, төрлесе төрле фән берлә мәшгуль булып, әллә никадәр мәгълүматларын арттыралар, төрмә боларга бертөрле мәктәп була! Шуның өстенә, үзеңне үзең саклап тотканда, ашарга-эчәргә җитәрлек булганда төрмәдә сәламәтлекне дә югалтмаска мөмкин. Шулай булгач, бу эшне эшләргә бик яратсам да, төрмәгә ябарлар дип куркам дип, эшләми калырга ярыймы? Әлбәттә, юк!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Яшь шәкертләргә, үзенең мәгълүматын арттырырга теләгән кешеләргә төрмә бик зур файда бирәчәк, аларның русча рәтләп белмәгәннәренә русча өйрәнергә бер дәресханә булачак.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Гаяз.

1907

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

Биттәге күпнокталар 1907 елгы китаптагыча бирелә.

*Тәкрар кылу* — кабатлау.

*“Сайе пәнһид әсаеш бәр кәлам”* — бу урында: буйсынучылар арасында тулы тынычлык.

*Мөхафизә* — саклау.

*Мәхкәмә* — хөкем йорты.

*Әмиранә* — түрәләрчә боерган сыман.

*“ Әлиф ятып”* —гарәп әлифбасындагы беренче (а) хәрефе сурәтенчә, ягъни таяк шикелле төп – төз ятып.

*Ливалвир* — революьвер.

*Хөббе нәфес* — үз –үзен ярату хисе.

*Кальбән* — чын күңелдән.

*Әсассыз* — нигезсез.

*Карамәт* — күрәзәлек.

*Наменә* — исеменә.

*Мәсгуд* — бәхетле.

*Вазыйфа* — хезмәт хакы.

*Тирес* — кире.

*Мотлак* — шөбһәсез.

*Лязем* — тиеш.

*Иттифакый* — очраклы.

*Гыйбта кылырга* — кызыгырга, көнләшергә.

*Вакыйган да* — чыннан да.

*Тәдбир* — чара.

*Игътикад* — ышану.

*Хасыйле* — кыскасы.

*Мөляхәзә* — фикер йөртү.

*Хатиб* — вәгазь сөйләүче, оратор.

*Идарәи мәшруталы* — конституцияле (конституция белән чикләнгән) монархия.

*Хәтем* — Коръән уку.

*Мөштәрәк* — уртак.

*Кабил* — төр.

*Низамсыз* — тәртипсез, кагыйдәсез.

*Коддуси* — изге дога.

*Сайә* — күләгә.

*Хәер хаһ* — яхшы теләк.

*Ригайә кылу* — исәпкә алу, хөрмәт итү.

*Казыя* — чишелергә тиешле мәсьәлә, тезис.

*Низамга хилаф* — тәртипкә каршы.

*Муаффәкъ булу* — ирешү.

*Шил булу* — эчкә бату, сеңү.

*Хәкыйкатән* — чыннан да.

*Мөстәкыйлә* — мөстәкыйльлек.

*Манзара* — күренеш.

*Сирайәт итү* — йогынты ясау.

*Ләскит* — ләчтит.

*Билфигыль* — чынлыкта.

**Зиндан.** — Повесть 1907 елда май ахырында Казанда Й. В. Ермолаева типографиясендә басылып чыккан. Наширләре: Габдерахман Хөсәенев, Габделгазиз Гобәйдуллин. Әсәр алдыннан әдипнең рәсеме, шулай ук тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында Сәгыйть Рәмиев белән Габдерахман Хөсәенев тарафыннан язылган «Мөхәммәдгаяз әфәнде» исемле мәкалә урнаштырылган. Әсәр Чистай төрмәсендә утырганда язылган.

Тексттан аңлашылганча, Г. Исхакый повестьның язылган өлешләрен күрешергә килгән һәм төрмәдән котылып чыккан кешеләр белән ireккә чыгара барган. Ниһаять, «Тавыш» гәзитәсенең 1907 ел 25 май санында«Зиндан»ның басылып чыгуы һәм сатыла башлавы хакында хәбәр ителә. Китап бик тиз тарала.

С.-Петербургтагы Чит ил басмалары Үзәк комитетына «әсәр революцияне пропагандалый» дип шикаять керә. 1908 елның 12 июнендә Казанның Матбугат эшләре буенча вакытлы комитетына «Зиндан» китабы белән бергә Үзәк цензурадан үтенеч килеп төшә: «Китап чыннан да Казанда басылганмы һәм, шулай булса, сатудан тыелганмы'?» *(Татарстан Милли архивы, 420 ф., 1 тасв., 115 эш, 61 кәгазь.)* Үзәк Комитет бу үтенечне түземсезләнеп тагын ике мәртәбә кабатлый һәм соңгысында китап турында тәфсиллерәк мәгълүматлар да сорый *(Шунда ук, 62, 63 кагәзьләр.)*

«Зиндан»га характеристика бирүне цензор Н. Катановка тапшыралар.

Катанов әсәрнең ун җиреннән өзек алып тәрҗемә итә һәм 1908 елның 7 июлендә үзеннән (кыскача) мондый сүзләр яза: «Әсәр 3000 данә күләмендә чыннан да Казанда басылган. Китапның шул билгеләнгән күләмендә И. В. Ермолаеваның лито-типографиясеннән алынуы турында минем тарафтан Матбугат эшләре буенча вакытлы Комитетка хәбәр бирелде, минем тәкъдимем буенча Комитет 1907 елның 2 июлендә әсәрнең 18, 31, 35, 38 һ. б. битләрендәге шөбһәле урыннар турында фикер алышу үткәрде. Китапның авторы, атаклы язучы-драматург (аның әсәрләре Казан татар сәхнәсендә хәзер дә даими күрсәтелеп килә) Мөхәммәдгаяз Исхаковның либераль әсәрләр бастырганы һәм митинглар оештырып йөргәне өчен инде кулга алынуы гына түгел, административ рәвештә (Казаннан) сөрелгәнен дә исәпкә алып, Комитет әлеге әсәр буенча суд алдында аерым эш кузгатмады. Китапның эчтәлегеннән дә күренгәнчә, аның авторы үзенең җинаятьләре өчен җитәрлек кадәр җәза алган инде». *(ТМА, 420 ф., 1 тасв., 115 эш, 64 б.)*

1908 елның 23 августында Казанның Матбугат эшләре буенча вакытлы комитеты С. Петербургтагы Чит ил басмалары цензурасы Үзәк комитетына түбәндәге җавапны җибәрә:

«Исхаков Мөхәммәдгаязның татар телендә дөнья күргән «Зиндан» («Төрмә») брошюрасы белән кызыксынып, шушы елның 12 июнендә язылган 1835 номерлы мөрәҗәгать уңаеннан минем тарафтан бу әсәрне тикшергән комитет әгъзасы профессор Н. Ф. Катановка, ул ялда булу сәбәпле, хат җибәрелде. Аңардан кирәкле җавапны ала алмау сәбәпле Үзәк комитетның югарыда әйтелгән мөрәҗәгатенә җавап җибәрүдә тоткарлык килеп чыкты.

Хәзерге көндә Матбугат эшләре комитеты Чит ил басмалары цензурасы Үзәк комитетына түбәндәгеләрне хәбәр итү мөмкинлегенә ирешә: исеме телгә алынган брошюра Казанда И. В. Ермолаева типографиясендә 3000 данәдә 1907 елның Май ахырында басылып чыкты. Комитетка килеп керү белән, тикшерү өчен Комитет әгъзасы профессор Катановка тапшырылды, ул исә кыска вакыт эчендә Комитетның рәисенә бу әсәрнең 14 битлек кереш, ягъни Мөхәммәдгаяз Исхаковның биографиясенә кагылышлы мәгълүмат

тупланганын, 80 битлек текстта аның әдәби-публицистик һәм сәяси эшчәнлеге, нинди җәзаларга тартылуы тасвирланганын хәбәр итте. Әмма брошюраның гаепкә алырлык урыннары барлыгына ишарә ясамады. Шул сәбәпле Исхаковның әлеге әсәре конфискациягә тартылмады, авторга каршы үз вакытында җинаять эше өчен эзәрлекләү булмады. Инде хәзер «Зиндан» брошюрасын Комитетның икенче әгъзасы Ашмарин әф. карап чыккач, аның эчендә, бигрәк тә 35 нче битендә (1907 елда басылган «Зиндан» китабының 35 нче бите бу басманың 296 битенә туры килә.—Л. Г.) Җинаять эшләре буенча законнар Җыелмасының 129 нчы статьясына туры килерлек урыннар калкып чыкты.

Шуның нәтиҗәсендә Комитет Исхаковның «Зиндан» дигән брошюрасына арест салырга, авторын күрсәтелгән статья буенча җавапка тартырга, һәм бу турыда Матбугат эшләре идарәсенә хәбәр итәргә карар кылды.

Бу хат белән Мөхәммәдгаяз Исхаковның югарыда телгә алынган әсәрен дә үзегезгә кайтарабыз» *(ТМА, 420 ф., 1 тасв., 115 эш, 71 кәгазь).*

Г. Исхакый «Зиндан» повестен 1907 елның 27 нче гыйнварыннан соң юа башлый.

*Бадамшии Гариф* (1865—1910 елдан соң) Чистай сәүдәгәре, I, II Дәүләт Думасы әгъзасы.

*Сәгыйть әфәнде* (Рәмиев Сәгыйть Лотфулла улы, 1880—1926) —шагыйрь һәм журналист.

*Исхак* (Бикчурин 1886 —1913) — журналист, тәрҗемәче.

*Балык базары* — Казанның хәзерге Тукай мәйданыннан алып Болакка кадәр араны биләгән урын; монда балык кибетләре күп булган, Рыб- норядская (хәзерге Пушкин) урамына кергән.

*«Москва» гостиницасы* — Московская (хәзерге Киров) урамындагы кунакханә.

*Сәгыйть әфәнде үзенең кыргыз сахраларында гомер үткәрүләрен...*— С. Рәмиев Оренбург губернасы, шул ук өязнең Акман авылында туа. 1906 ел башында Казанга күчеп килгәнчегә кадәр Оренбург өлкәсендә һәм Оренбург шәһәрендә яши, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый, укуны тәмамлаганнан соң, 1902 елдан шул ук мәдрәсәдә мөгаллим булып кала. Г. Исхакый С. Рәмиевнең кай якта туып үсүенә ишарәли.

*...1905 елның 13 нче декабрьдән бирле (нелегальный) качып йөргәнгә...*— 11 декабрьдә алынган ордер белән 14 декабрь көнне Г. Исхакыйның квартирасында тентү үткәрелә. Жандармерия агентларының үзен тотарга йөрүләрен сизеп, Г. Исхакый квартирасына кайтмый. Ул үзе бу турыда болай яза: «Артыбыздан бара торган юлдашлар күбәйгән саен, безне тикшерүче полицанын да саны арта иде. Мин 17 нче октябрь манифестын Чистай өязендәге авылларда аңлатып йөрүем өчен аннан качарга мәҗбүр булган идем. Яжа бистә мәдрәсәсендә ясаган бер җыелыш өчен тотарга дип өемә килгән полицадан качарга кирәк булганга, Казанда яшерен тора идем». *(«Яңа милли юл», 1931, №5).*

Архивта мондый белешмә бар: «Казан губернасы жандарм идарәсенә. Белешмә. Гаяз Исхаков Рыбнорядская урамындагы Марусов йортында Екатерина Захарова квартирасында бер бүлмә алып тора. Захарованың әйтүенә караганда, Исхаков 13 декабрьдә чыгып киткән һәм әлеге кадәр кайтканы юк. Казандагы 2 частьның 2 участогы приставы ярдәмчесе». *(ТМА, 199 ф., 1 тасв., 258* эш. *212 к.)*

*..тентү ясарга тотынды* —Сәгыйть Рәмиев фатирында полиция 1906 елның 30 октябрендә тентү ясый. «Казан мөхбире» гәзитәсе 1906 ел, 1 ноябрь санында бу турыда хәбәр итеп: «...кунакка килгәндә генә кунып калган мәшһүр

татар мөхәррирләреннән Гаяз әфәнде илә икесен арестовать иткәннәр иде. Сәгыйть әфәндене суд булганга кадәр дип чыгарып торганнар», дип тә өсти.

*Мокрый*—тимер юл вокзалы каршындагы урам исеме. Йортлар тоташ сүтелеп, ул урамдагы берничә йорт хәзерге Сакко һәм Ванцетти урамына карый.

*«Волжский вестникъ»* — Казанда 1883—1884 елларда журнал булып, 1884—1906 елларда гәзитә булып чыккан басма.

*...револьверның тоткалары берлән 17 нче октябрь манифестында вәгъдә кылынган граждански праваларны тутыручылар...*— сүз Россия императоры Николай II нең 1905 елның 17 октябрендә чыгарган манифесты турында бара. Революцион хәрәкәтнең көчәюеннән куркып калган патша күп иркенлекләр вәгъдә итсә дә, тиздән бу манифестның бары тик халыкны тынычландыру, алдау өчен генә чыгарылганлыгы ачык күренде. Гаяз Исхакый шуңа ишарәли.

*Хөсәен Ямаш* (Ямашев Хөсәен, 1882—1912) — татар революционеры, публицист.

*«Таң»* («Таң йолдызы») — Г. Исхакый оештырган беренче рәсми «сәяси, әдәби һәм фәнни» гәзитә. Аны чыгару өчен Гали Путиляков исеменә рөхсәт алына *(ТМА, 420 ф., 1 тасв., 76 эш).*

Гәзитәнең 10 нчы (19 июнь) саныннан рәсми редакторы Сәгыйть Рәмиев, фактик редакторы, рух, юнәлеш бирүчесе Г. Исхакый.

Гәзитәнең төп язышучылары — Г. Исхакый, Ф. Туктаров, С. Рәмиев, Ш. Мөхәммәдьяров, Х. Әбүзәрев, И. Бикчурин. «Таң йолдызы»н чыгаручыларны җәмәгатьчелек «таңчылар» дип йөртә. «Таң йолдызы» сыйнфый көрәшне пропагандалый, аның лозунгысы: «Тартышуда гына табарсың син үзеңнең

хакыңны!»

Гәзитәнең беренче саны 1906 елның 18 маенда дөнья күрә һәм ул Г. Исхакыйның «Казан, 18 май» дип исемләнгән, Россиядә халыкның авыр тормышы, азатлык өчен көрәш турындагы баш мәкаләсе белән ачыла. Калган барлык саннарында да Г. Исхакыйның публицистик мәкаләләре һәм шулай ук әдәби әсәрләре басыла.

Гәзитәнең бик күп саннарында аерым өлешләр яисә тоташ баганалар ак килеш чыккан. Болар—цензура кайчысы эзләре. Цензорлардан иң «тырышы» Эчке эшләр министрлыгының матбугат буенча Казан инспекторы Николай Ашмарин, татар басмаларын күзәтүче буларак, 1906—1908 елларда бик авырлык белән оештырылган, бик авырлык белән чыгып килә торган татарча газета һәм журналлар өчен бер бәлага әверелә. «Таң йолдызы», «Казан мөхбире», «Бәянелхак» гәзитәләренең, «Таң мәҗмугасы» журналының аерым саннарына арест салып, мөхәррирләрен суд җаваплылыгына тартуны сорап югары инстанцияләргә бертуктаусыз үтенечләр яза. Шул аркада цензорлар, наширләр гәзитә нөсхәләре чыкканчы ук, типографияләрдә үк җыелган гранкаларны тырышыбрак туныйлар, юкка чыгаралар. «Таң йолдызы»нда бу турыда ачынып болай язалар: «Инспектор пичәте кичә гәзитәмез өчен хәзерләнгән баш мәкаләмез берлән «Бюрократлардан өмет итәргә ярамый» дигән мәкаләләремезнең гәзитәгә басылуын 129 нчы статьяга хилаф тапканга, типография хуҗамыз Ермалаев шул статьяларны кертеп басарга риза булмаганга, гәзитәмез чыга алмаенча калды. *(Имзасыз.— Идарәдән. Таң йолдызы. 1906. 44 сан.)*

«Таң йолдьпы»ның шул ук санында имзасыз басылган «Казан, 20 нче сентябрь» дигән мәкаләгә игътибар итик: «Һәркемгә мәгълүм, безнең Россиядә матбугатта хөрriят бирелде... цензура дигән сүз бетеп, матбугат тарихыннан чыгарылды. Теләсе кемгә теләсә нәрсә язарга рөхсәт бирелде.

Менә шул «хөррияте матбугат» һәр нумирымызда диярлек статья-ларммызның я башын, я кулын, я борынын кисеп калалар. 44 нче нумирны да ...әллә нинди статьяларга тугры килмәгән өчен типография хуҗасы куркып

гәзитәне бастырмады. Шуның сәясендә сишәнбе көн чыга торган нумирымыз ул көнне чыга алмады. Шул «хөррияте матбугат» хакында гәзитәмез әллә никадәр үзенең төсен югалтты. Гәзитәмезнең кызыл төсе әллә никадәр уңды. Моннан соң даниләр булачагы, хөррияте матбугат сәясендә язучыларымызның күрәчәге мәгълүм булмаса да, бюрократлардан рөхсәт алмаячагыбызны, бик күбемезнең урыннарымыз төрмәләр идекен белеп, һаман язуда дәвам итәмез. Моннан соң да нинди «Хөррияте матбугат» законнары чыкса да һаман дәвам итәчәкмез. Безнең гәзитә язудан максатымыз акча җыю яисә үземезгә исем алу булмаенча, халкыбызга хезмәттер.

Шуның эчен шул юл никадәр авыр булса да, никадәр куркынычлы булса да, бюрократлар никадәр аяк чалып егарга теләсәләр дә, без һаман үземезнең тартышу юлымызны ташламаячакмыз. Һаман алга таба хәрәкәт итәчәкмез. Үземезнең файдалы дип ышанган фикеремезне аңлатырга тырышачакмыз. Ләкин шул «хөррияте матбугат» сөясендә әйтәчәк сүзләрсмезне әйтә алмаганга, язачак сүзләремезне язып бетерә алмаганга, укучыларымызга тагы бер мәртәбә юл арасыннан чынлабрак укырга, чынлабрак уйларга тиеш булачактыр.

Гәзитәмездәге һәр ак йерләр, нокталар төртеп киткән юллар барысы да кып-кызыл җөмләләр, йөрәктән чыккан ачы сүзләр идекен һич онытмаенча укуда дәвам итеңез. Бар куәтемез берлән сезгә аңлатырга тырышырмыз. Сезне «Таң»сыз калдырмаска бөтен көчемезне сарыф кылырмыз. Шулай итә-итә «Таң» дәвам итсә, безнең тормышта да кояш чыгу якынлашыр, безнең тормышның да караңгылары югалып, асты-өсте күренә башлар. Безгә дә иркенлек якынлашыр. Безнең дә чарлактан подвалга, подвалдан чарлакка качып йөргән язучыларымыз кеше кебек йөри башларлар. Алар да хөр булырлар». Бу мәкаләләрнең теле, стиле, аһәңе аларның Г. Исхакыйныкы булуында шик калдырмыйлар.

1906 елның 11 июлендә Ашмарин «Таң йолдызы» гәзитәсенең 15 нче санына арест салуны сорап Казан полицмейстерына болай яза; «1905 елның 24ендә кабул ителгән Вакытлы матбугат буенча Кагыйдәләрнең VII бүлеге, 5

нче маддәсе, 6 нчы пунктына туры килгән җинаять билгеләре табылган мәкаләләр бастырган өчен «Таң йолдызы» гәзитәсенә арест салып, аны типографиядән, редакциядән, сатучылардан һәм гомумән бу сан сатыла торган бөтен җирдән бик тиз генә җыеп алырга кирәк. Бу күрсәтмәмне раслату өчен һәм гәзитә мөхәррире Сәгыйть Рәмиевне кулга алып, суд хөкеменә бирү өчен мин аны Баш прокурорга да җибәрәм...» Икенче хат: «Округ суды прокурорына... Сез Галиҗәнабтан гәзитәгә мин салган арестны раславыгызны һәм мөхәррир Сәгыйть Рәмиевне суд җаваплылыгына тартуыгызны үтенәм...» Өченче хат: «Казан губернаторына... мин атаган гәзитәгә арест салырга һәм мөхәррир Сәгыйть Рәмиевкә карата суд эше кузгатырга боерык бирүегезне үтенәм...» Дүртенче хат: «Петербургтагы Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә... Минем тарафтан «Таң йолдызы»ның 15 нче санына арест салынды һәм мөхәррир Сәгыйть Рәмиев суд хөкеменә тартылды. Бу хат белән бер үк вакытта аерым пакетта 3 данә әлеге гәзитәне дә җибәрәм».

1906 елның 18 июлендә Н. Ашмарин Казан Округ суды прокурорыннан мондый кәгазь ала: «Вакытлы матбугат буенча Казан инспекторына. Хөрмәтле әфәндем, Сезгә белдерәм ки, Казан Округ суды үзенең шушы елның 14 июлендә уздырылган утырышында «Таң йолдызы» гәзитәсенең 15 нче санына Сез салган арестны раслады». *(ТМА, 420 ф., 1 тасв., 56 эш, 29—35 к.к.)*

Гәзитәнең 25 нче саны турында да Ашмарин шул ук инстанцияләргә шундый ук эчтәлектәге хатлар җибәрә (шунда ук, 145 к.). Гәзитәнең 9 саны конфискацияләнә, һәм, ниһаять, 65 саны чыкканнан соң, 1907 елның 17 ноябрендә губернатор боерыгы белән «Таң йолдызы» гәзитәсе ябыла.

*Мария Спиридонова* (1884—1941)—сул эсерлар партиясе лидерларыннан.

*Яушырмә*—Гаяз Исхакый туган авыл. Элек Малая Калеева, Малая Бахта исемнәре белән йөргән. Хәзерге көндә татарча Яушырмә, русча Кутлушкино дип аталып йөртелә.

XVI йөздә хәзерге Яүширмә урынында Кәләй авылы булган. Кәләй—бу авылны нигезләгән кешенеӊ (Кәлимулла) исеме. Бахта—авыл янынннан ага торган елга исеме. (Хәзер аны «Елга» дип кенә йөртәләр.) Октябрь революциясенә кадәр авылныӊ адресы русча «Деревня Калеева, Малая Бахта тож» дип язылган. Туу, үлү, өйләнешү турында авыл муллалары язып барган метрика дәфтәрендә дә авыл исеме «Малая Калеева-Бахта» дип бирелгән.

Профессор Фирдәүс Гарипова XVIII йөздә үк Д. А. Корсаков хезмәтендә авыл «Калеева, Малая Бахта, Кутлушкино тоже при речке Гаушерма» дип бирелүен әйтә. Ул «Яүширмә» атамасыныӊ килеп чыгышы турында болай ди: «Татарстан җирендә «ширмә» сүзе катнашкан тагын шактый атамалар сакланып калган... Каραширмә, Орымширмә, Икширмә... «Ширмә» сүзе су-елга белән бәйләнешле булып, җырма- җырмак (ермак) сүзенә барып тоташуы бик ихтимал». «Кутлушкино» атамасы турында галимә болай яза: «Шушы исем белән ул XIX йөз урталарындагы тарихи чыганакларда искә алына. Авыл халкы атаманы болай аӊлата: авылныӊ аксакалы Котлыиш бабай була. Ул авылныӊ хөрмәтле кешесе исәпләнә, киӊәшче вазыйфасын үти. Котлыиш исеменә мөнәсәбәтле рәвештә руслар аны Кутлушкино дип атый башлыйлар. Котлыиш (Кутлушкино) кебек кеше исеменнән барлыкка килгән авыл атамалары аз түгел». *(Фирдәүс Гарипова.—Авыллар һәм калалар тари-хыннан.—Казан. 1997. 461—466 бб..),*

Яүширмәдә гомерен уздырган Садыйков Гариф Зариф улы язып калдырган мәгълүматларга һәм өлкән буын кешеләренеӊ сөйләвенә караганда, авылга төрле яктан төрле нәсел кешеләре килеп урнашкан. Мәсәлән, 1903 елда туган, исемен Яүширмәдәге 1 нче җамигъ мәчете мулласы Гаяз Гыйләҗетдин улы Исхакый кушкан Һади Нуретдинов үзенеӊ ерак бабасы. генерал Моратныӊ Чирүле Шонталысы авылында яшәгәнлеген сөйли. Бер нәсел Тәтеш өязе Тархан авылыннан килеп урнаша. Шулай *ук* Сембер ягыннан, Зөя өязеннән килеп тә урнашканнар.

ХП1 йөздә Кама буендагы халыкларны көчләп чукындыру башланып, Кәләй авылы халкыныӊ да бер өлеше чукындырыла. Соӊыннан керәшеннәр

кире мөселманлыкка кайталар.

Авылда ике мәчет эшләгән. 1 нче җамигъ мәчетендә 1873 елдан башлап 29 ел буена имам-хатиб, мөдәррис булып Г. Исхакыйның этисе Гыйләҗетдин Исхак улы торган. 1902 елның 16 июнендә (иске стильдә) муллалыкка алынган указ нигезендә 1903 елның 31 мартында (иске стильдә) Г. Исхакый муллалык вазыйфаларын үз өстенә ала. («Самара губернасы, Бөгелмә өязе, Лашман авылы крэстияне Мөхәммәдгаяз Гыйләҗетдинов Исхаковны Чистай өязе, Кутлушкино авылындагы 1 нче җамигъ мәчете имамы итеп билгеләү турында». *(ТМА, 2 ф., 2 тасв., 6838 эш, 14 к.)*

Яүширмәдә Советлар Союзы Геройлары Г. Н. Шәмсетдинов, А. 3. Вәлиев, күренекле татар артисты Барый Тарханов, Татарстанның атказанган артисты Фәйзи Йосыпов һәм башка күп кенә күренекле шәхесләр туып үскән.

Хәзерге вакытта Яүширмәдә 265 хуҗалыкта 755 кеше яши. Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, балалар бакчасы (Г. Исхакый туып үскән йорт урынында), мәчет, Г. Исхакый музее бар.

1919 елда Чистай шәһәре типографиясендә Хәбиб Хәкимовның Яүширмә турында «Чехлар заманында» исемле китабы басылып чыккан. (Кечкенә форматта, 31 бит.)

*...егерме дурт сәгатьтә китәргә дип кул куйдырдылар* — Г. Исхакый Казан төрмәсеннән 1906 елның 2 ноябрендә азат ителә.

*Проломный* — хәзерге Бауман урамы.

*«Болгар»* — кунакханә; хәзерге Татарстан урамының 14 йорты бинасында урнашкан була. Бу урында сүз кунакханәнең ашханәсе турында бара.

*Хөсәен* — Хөсәен Әбүзәрев (?—1917) нашир-матбагачы, журналист.

*Шакир* — Шакир Мөхәммәдьяров (1883—1967), юрист, журналист, педагог.

*Бөтен татар гәзитәләрендә минем хакымда мәкаләләр булуын сөйләделәр.*—«Казан мөхбире» гәзитәсе һәр санында Г. Исхакый турында хәбәр биреп бара: «Тәүкыйф телгән мәшһүр мөхәррир Гаяз әфәнде Исхакый төрмәдән чыгарылды. Ләкин 24 сәгать эчендә Казаннан китәргә шарт иткәннәр. Ватанына кайтып китте» *(1906 ел, 5 ноябрь).* «Гаяз әфәнде Исхаковны янә арестовать иткәннәр. Чистай өязе крәстияннәре аны Думага сайларга ният итәләр иде». *(1906 ел, 25 декабрь.)* «Чистайдан хәбәр итүләренә күрә, Гаяз әфәндене хибес итүгә сәбәп— мөселманнардан берәүнең полициягә донос ясавы булган». *(1907 ел, 3 гыйнвар.)*

«Казан мөхбире»нең 1906 ел, 5 нче ноябрь санында Йосыф Акчураның «Гаяз әфәнде» исемле мәкаләсе басылып чыга: «...Гаязның тәүкыйфе хөкүмәтнең Максудына бер дә хезмәт итәчәк түгел, билгакес, аның фикеренең тагы да артыграк җәелүенә ярдәм кылачак».

«Таң йолдызы» гәзитәсе: «Гаяз ике ел буена һичбер җылы урын күрмичә, ике ел буена үзенең чын исеме белән хитаб кылган бер тавышыны ишетә алмыйча, шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга йөреп, халыкның дөньяда рәхәт яшәве, халыкның эшләгән эшенең барының да халыкның, үзе өчен булуы, эшлим дигән кешегә эшнең табылуы, эшләп, дөньяда иркен торуы өчен хезмәт итеп йөргән, татарларның күзләрен ачкан, фикерләрен киңәйткән бик күп әдәби әсәрләре илән татарларның йөзен агарткан, татарларны дөньядагы халык арасына кергезгән мәшһүр әдип, мөхәррир Гаяз әфәнде Исхаков җәнабләре дә, беренче мәртәбә уларак, халык корбаны булды». *(1906 ел, 1 ноябрь.)*

«Тәрбиятел-этфаль» гәзитәсендә Ф. Әмирхан мәкаләсендә мондый сүзләр бар: «Хөкүмәт тарафыннан бу көннәрдә Казаннан нәфи ителеп халык корбаны булган мөхәррир вә әдип мәшһүр Гаяз әфәнде Исхаков..,»[1] *(1906 ел, 1 гыйнвар )*

*Губу*—гауптвахта.

*Әни*—Яүширмәдән 12 чакрым ераклыктагы Мөслим авылы (хәзер Чистай районына керә) Габделвәли хәзрәт белән Мәхфүзә остазбикә кызы Бибикамәрия. 1858 елда туган. Әтисе ягыннан бабасы— Габделислам.

Г. Исхакый үзенең төрек телендә гарәп хәрефләре белән язган, берничә вариантта каралама килеш калган «Тәрҗемәи хәлем» кулъязмасында: «Әниемнең этиләре, әниләре дүрт буынга кадәр голяма (укымышлылар) зөмрәсеннән, Казанның хәле авыр вакытта Кырымнан Кырым шаһзадәләре идарәсеннән Казанга ярдәм итәргә килгән, «Чура батыр» хикәясенә тема биргән кешеләр токымыннан»,—ди.

Гаяз Исхакый 11 ел буена Берлинда үзе чыгарган «Милли юл», соңыннан «Яңа милли юл» журналында байтак мәкаләләрен «Чура батыр» псевдонимы белән язган.

Камәрия остазбикә авыл кызларың өенә китереп укыткан. Кызлары үсеп буйга җиткәч, һәркайсысы авыл кызларын укытуга кушылган. Камәрия абыстай алар өчен җитәкче-мөдир ролен үтәгән.

1921 елгы ачлыкта Камәрия улы Әхмәтхәсәнне, оныгы Сәгадәтне алып Ташкентка китә. Алар анда 1 ел чамасы яши.

Камәрия Габделвәли кызы 1923 елда Яүширмәдә тифтән үлә.

*...кызымны алып чыктылар* —Мөхәммәдгаяз белән Бибимәрьям кызы Сәгадәт Исхакый, 1905 елның 15 июлендә (яңа стильдә 28 июль) Яүширмәдә дөньяга килә. Әтисе Казан төрмәсеннән котылып авылга кайтканда Сәгадәткә 1 яшь тә 3 ай ярым була.

Бер ел чамасы ул Петроградтагы кызлар гимназиясендә укый. Бераздан Сәгадәт, кире Яүширмәгә әбиләре янына кайта, 1921 елгы ачлыкта әбисе Камәрия белән Ташкентта туганнары янында бер ел чамасы яшәп кайтканнан соң, 1922 елда Сәгадәт әтисенең чакыруы буенча Петроградка китә һәм Финляндия татарлары ярдәме белән чикне үтә. Берлинда гимназиядә укый. 1932 елда Берлин университетының фәлсәфә факультетын тәмамлый.

Аспирантурада укып, диссертация яклый. 1932 елда үзбәк егете Шакир улы Таһирга (Чагатай) кияүгә чыга. Икесе дә Берлинда Г. Исхакыйга «Милли юл» мәҗмугасын чыгаруда булышалар. Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, мәҗмуга ябыла һәм 1940 елда Сәгадәт белән Таһир Чагатайлар Төркиягә күчеп китәләр, икесе дә Анкара университетында укыталар. Сәгадәт төрек теле һәм әдәбияты белеме профессоры, Таһир—социология белеме профессоры.

Сәгадәт Чагатайның «Чура батыр» (1935), «Алтын ярук»тан ике парча» (1945), «Төрек ләһҗәләре үрнәкләре» (I т., 1963), «Казакъча мәтеннәр» (1961), «Төрек ләһҗәләре үрнәкләре» (II т., 1972) һәм башка хезмәтләре бар.

Сәгадәт Чагатай-Исхакый 1988 елда Айаз-Таһир (Төркстан-Идел- Урал) фондын төзи, 1989 елның 24 нче июлендә 84 яшендә Анкарада вафат була.

*...элгәреге хатынымның...*— Г. Исхакыйның хатыны Бибимәрьям Фәтхетдин бай кызы 1884 елның 25 августында (иске стильдә) Яүширмә авылында туган. Г. Исхакый белән 1903 елның 3 ноябрендә (иске стильдә) никахланалар. Метрика дәфтәрендә бу вакытта Яүширмәдәге 1 җамигъ мәчете мулласы булып торган Г. Исхакыйның үз кулы белән болай язылган: «Шушы Кәләй авылының Фәтхетдин Шәриповның Мәрьям шушы Кәләй авылының имамы Мөхәммәдгаяз мелла Гыйләҗетдин улы Исхаковка никахландырылды. Кыз—егеткә. Кызга 19, егеткә 25. Кыз тарафыннан вәли вәкил — агасы Мөхәммәтгали Фәтхетдин улы Шәрипов. Кияү тарафыннан — атасы мелла Гыйлаҗетдин Исхаков. Шаһитләр: Тигәнәле имамы мелла Габдрахман Фәхретдин, Габдуллаҗан Фәхретдин...Мәһәре дүрт йөз сум...». «Хотбә укыдым. Чистай имамы Ибраһим Камалов» (соңгы җөмләне И. Камалов язган).

Агалары сәбәпче булып, Г. Исхакый белән Бибимәрьям 1906 елның 26 июлендә аерылышалар. Метрикә дәфтәрендә мондый юлларны укыйбыз: «Самара губернасы Бөгелмә өязе Кармалы волосте Лашман авылының Мөхәммәдгаяз мелла Гыйләҗетдин угылы тәхте никахында булган хатыным Мәрьям Фәтхетдин кызыны хәлгы кылдым». Шул ук елның 28 ноябрендә алар

никахларын яңартып тагын кушылалар.

Әмма 1908 елның 21 июлендә Гаяз белән Мәрьям бөтенләйгә аерылышалар. Архангел губернасыннан язган документта болай диелә: «...Мин, Казан губернасы, Чистай өязе, Краснояр волосте Яүширмә авылының крәстияне Мөхәммәдгаяз Гыйләҗетдин угылы Исхаков, үземнең никахымдагы хатыным Мәрьям Фәтхетдин кызыны үзенең мәһаре бәрабәренә, габде нәфкасы бәрабәренә хәлгы кылдым. Мөхәммәдгаяз Исхаков».

1909 елда Мәрьям Чистайдагы сәүдәгәр Баһаветдин улы мөгаллим Ибраһим Камалетдиновка кияүгә чыга. 1922 елда алар аерылышалар. Мәрьям Казанга күчеп килә. Соңгы елларын Ибраһимнан туган кызы Суфия тәрбиясендә үткәрә. 1970 елда вафат була.

Мәрьям белән кызы Сәгадәтнең мөнәсәбәтләре турында төрле сүзләр йөргән. Әмма Сәгадәт бик яшьли әтисе янына чит илгә чыгып китсә дә, Чистайда, соңыннан Казанда яши торган әнисе белән араларын өзмәгән. Алар хатлар алышканнар. Моны исбатлый торган фактлар бар. Мәсәлән, Сәгадәт Исхакый-Чагатайның фоторәсемнәр альбомында Мәрьям белән кызы Суфия төшкән рәсем артына «21 август 28 ел. Сәгадәт апага истәлек. Суфия. Чистай» дип язылган, 1928 елда төшкән рәсем: «Сөекле балам! Илһамия белән төшкән рәсememне җибәрәм. Сагынганда карарсың. Әниең». 1925 елдагы рәсем: «Сөекле балам Сәгадәт!.. Сагынганда карарсың. Мәрьям». Альбомда Суфияның 1933 елда үзе генә төшкән рәсеме дә бар.

Илләр арасында чикләр ябылгач, Мәрьям белән Сәгадәтнең дә бәйләнешләре өзелгән.

*Әти* —Г. Исхакыйның әтисе Гыйләҗетдин Исхак улы. 1838 елда хәзерге Чирмешән районының Лашман авылында туган. Мәдрәсә тәмамлап, 1873 елның мартында муллалыкка указ ала. Яүширмәгә килеп, 1873 елдан 1902 елның гыйнварына кадәр авылның 1 нче җамигъ мәчетендә имам-хатиб, мөдәррис булып тора. Г. Исхакыйның әнисе Камәрия Габделвәли кызы белән 1873 елның 3 августында Яүширмәдән 12 чакрымдагы Мөслим авылында

(Камәриянең туган авылы) никахлананалар.  Аларның унбер балалары туа: Мәрьям, Габдрахмаң, Мөхәммәдгаяз, Салихабану, Гайнелмәрзия, Габдрахман, Мөхәммәдхәнис, Әхмәтгали, Фәридәбану, Хәлимәбану, Әхмәтхәсән. Шуларның бишесе—Мөхәммәдгаяз, Гайнелмәрзия, Фәридәбану, Хәлимәбану, Әхмәтхәсән—исән-сау үсеп  җитәләр.

Гыйләҗетдин, күзе начар күрү сәбәпле, 1901 елның 31 декабрендә Казан губернасы Идарәсенә үз урынына улың —Мәхәммәдгаязны мулла итеп куюларын сорап үтенеч яза. 1902 елның 21 гыйнварында Гыйләҗетдин Исхак улы муллалык вазыйфаларыннан азат ителә. (ТМА, 2 ф., 2 тасв., 6626 эш, 1—30 к.к.)

Гыйләҗетдин Исхак улы 1919 елда вафат була.

*Кияу — Г.* Исхакыйның сеңелесе Гайнелмәрзиянең ире, Яүширмәдә имам Мөхәммәтвафа Мәхмүтов.

*Сеңелем*—Г. Исхакыйның иң зур сеңлесе Гайнелмәрзия (1882—1965). Ул 1938 елда кулга алынып, 1906—1907 елларда абыйсы Гаяз Исхакый утырган Чистай төрмәсенә ябыла. Абыйсыннан килгән хатларны таптырып, туганың белән кемнәр аша элемтә тотасың, дип, бик газаплыйлар. Салкын су сибелгән таш идәндә сәгатьләр буена бастырып тоталар.

Озак гомер яшәсә дә, төрмәдә 14 ай буена күргән газаплары аркасында Гайнелмәрзия, аяк-куллары сызлаулы булып, стенага тотынып кына йөрерлек хәлдә була.

Шундый ук язмышка Г. Исхакыйның бертуган энесе Әхмәтхәсән дә дучар була. Совет власте дошманы Г. Исхакыйның туганы булганы өчен төрмәләрдә утырып, котылып чыккач та, берөзлексез НКВДга чакыртылып йөрүләргә түзә алмыйча, 1940 нчы елда асылынып үлә.

*Бурнаш*—Татарстанның хәзерге Чистай районындагы авыл.

*Змёево*—"Татарстанның хәзерге Чистай районындагы авыл.

*...урәтникләр баягы Шәйхи атлы куштанга килеп, мине бөтенләй каравыллап тора башладылар.*—Шәйхетдин Җамалетдиңов (1866—1918)—доносчы, провокатор. Архивта 1907 елның 10 февралендә Чистай өязе суд тикшерүчесе тарафыннан шаһитләрдән сорау алу белешмәсендә Шәйхетдин Җамалетдинов авызыннан мондый сүзләр язылган: «Гаяз Исхаков элек безнең авылда указлы мулла иде. 1905 елда тәртипсезлекләр башлангач, авылдан чыгып сызды. Полиция аны озак эзләде, һәм, ниһаять, үткән көздә Гаяз Исхаков авылга кайтты. Ул күренү белән үк мин үрәтниккә хәбәр бирдем һәм үрәтник авылга килеп аны шәһәргә алып китте. Ләкин Гаяз шәһәрдә озак тормады, тагын авылга әйләнеп кайтты. Үрәтник минем өемә килеп яши башлады. Ул Гаязны берәр кая китмәсме дип күзәтте. Шулай ук Александровкадан килеп стражник та күзәтте.

Узган елның 26 декабрьләре тирәсендә бугай, сәгать уннарда мин Чистайда Базар урамында Кәбестә рәтенә каршы гына торган Назимов трактирына чәй эчәргә кердем. Трактирда миннән башка кеше юк иде. Бераздан Гаяз Исхаков килеп керде һәм үзен, шулай ук Бадамшинны Даүләт думасына сайларга кирәк дип сөйли башлады. Шуны әйткәндә ул кесәсеннән эре акчалар чыгарды, минемчә, бер 300—500 сумлап булгандыр Һәм мина: «Менә күрәсеңме, сайлау өчен безнең күпме кирәк, шуның кадәр акча бар. Алар Дәүләт банкында ята. Күпме кирәк, шул кадәр бирәчәкләр, тик мине һәм Бадамшинны гына сайласыннар. Без Думада булсак, яңа законнар чыгартуга һәм Романовларны тәхеттән куарга ирешәчәкбез»,—диде.

Шул чагында трактирга Сәлахетдин Сәйфстдинов килеп керде һәм бер читкәрәк китеп басты. Мин сүгенеп куйдым һәм Сәлахетдингә: «Гаяз әнә нәрсәләр сөйли, иң яхшысы — моннан чыгып китик»,— дидем, һәм без Сәлахетдин белән трактирдан чыгып киттек. Гаяз Исхаков шунда торып калды.

Бераздан мин тагын шәһәргә килдем һәм стражникка Гаяз белән элеге

очрашуым турында сөйләдем. Ул соңыннан Сәлахетдинне чакырып сорау алды. Соңыннан Яүширмәгә надзиратель белән үрәтник килде һәм һәркайсыбыздан сорау алдылар. Гаяздан башка андый сүзләр ишетмәдем. Ләкин башка кешеләрдән Гаязның шул ук сүзләрне сөйләвем ишеттем. Мәсәлән, миңа Хәлиулла Хәмитов әйтүенчә, Гаяз үзенең хатыны Мәрьямгә укырга килгән кыз балаларны әтиләрегезгә әйтегез дип, үгетли икән. Имеш, ул Кызыл Хач җәмгыятеннән кызларны да ашатуны юллаячак. Сәхәбетдин Сәйфетдинов Гаяз Исхаковнын кияве Вафа Мөхмүтовтан ишеткән сүзләрне миңа да әйтте. Имеш, Гаяз Исхаков югарыдан килгән бер кәгазь күргән. Анда Кызыл Хачтан килгән акчага барлык балаларны да ашатырга кирәк, ә аерым балаларны гына түгел, дигән. Имеш, түрәләр акчаның бер өлешен яшереп калдыралар һәм бу кәгазьне беркемгә дә күрсәтмиләр. Мин бу турыда надзирательгә әйткәнем юк иде әле. Югыйсә аны (Г. Исхакыйны. - *Л. Г.)* хөкүмәткә буйсынмаганы өчен күптән куган булырлар иде. Болар турында надзирательгә Сәхәбетдин Хөснетдинов сөйләгән иде.

Мин сөйләгәннәр дөрес язылган. Башка берни дә күрсәтә алмыйм. (Имза)» *(ТМА, 51 ф., 6 тасв., 916 эш, 14—15 к.).*

Суд тикшерүчесе Шәйхи куштан доносында исемнәре телгә алынган һәммә кешедән сорау ала. Шулар арасында Гаяз Исхакыйның иң өлкән сеңелесе Гайнелмәрзиянең ире Мөхәммәдвафа Мәхмүтов та бар. Ул болай сөйли: Гаяз Исхаков минем каен энем, мин аның сеңелесенә өйләнгән. Мин авылда Кызыл Хачтан ашатыр өчен исемлек төзедем. Ул исемлеккә бары малайларны гына яздым. Сәхәбетдин Габитов (Сәйфетдинов) миңа исемлеккә үзенең кызын да кертергә сорап мөрәҗәгать итте. Мин аңа, моны эшләргә минем хакым юк, миннән торса, мин барысын да ашатыр идем, дидем. Сәлахетдингә кайнешем Гаяз турында бер сүз дә әйткәнем юк. «Барысын да ашатырга тиеш дигән кәгазь бар» түрәләр акчаны үзләренә яшереп калдыралар» дигән сүзләрне минем Гаяздан ишеткәнем юк». *(Шунда ук, 15 к.)*

Шәйхетдиннең соңгы язмышы нинди була соң? Керенский хөкүмәте җимерелгәч, ерак төбәкләрдә, властьның булмавы аркасында, анархия хөкем

сөрә. Нәкъ шул вакытта Шәйхетдин Җамалетдинов шайка оештырып, өй саен кереп, талап йөри башлый. Төнлә басып кереп, ялгыз хатын-кызны көчләүдән дә тартынмыйлар. Октябрь революциясе булгач, «большевиклар боярларны таларга рөхсәт итәләр» дип, кылган яманлыкларын большевиклар өстене ташлап, тирә-яктагы байларны талап, әйберләрен өйләренә ташып бетерәләр.

Чистайда да бер итек кибете таланып, авылга милиция килгәч, авыл халкы, ярсып, «Шайка башлыгы Шәйхине бетерергә кирәк!» дип, Шәйхи йортына бара һәм кешеләрдән талаган әйберләрне алып чыгалар. Байтак карак тотыла, Шәйхи качып йөри.

Әле яна гына фронттан кайткан Гаяз Садыйков халык үтенүе буенча җитәкчелек итәргә ризалык биреп, караклардан табып алынган малларны кайсын очсыз бәягә фәкыйрьләргә биреп, кайсын сатып, акчасын авыл җәмәгатьчелеге кулына калдыра.

Гаяз Шәйхине эзләтү эшенә керешә һәм аны тотып төрмәгә яптыра. Шәйхи төрмәдән бер чыгып, бер ябылып торганда авылга чехлар килеп керә.

Чехлар заманында 1918 елның 29 августында Яүширмәдә бик күп кешеләрне кулга алалар. Чехларга хезмәт итәргә дип антлар бирдереп, кешеләрнең кайберләрен азат итәләр. Төрлесенә төрле җәза бирелә. Яүширмәдә биш кеше — Гаяз Садыйков, Муса Сафин, Гайса Кәбиров, Габдрахман Әхмәдиев, Вафа Садыйков—үлем җәзасына хөкем ителәләр.

Үлем җәзасы бирү турындагы карарда бу бишәүнең мондый гаепләре күрсәтелә: «Нимесләргә хезмәт итүләре өстенә Яүширмәдә Шәйхетдин Җамалетдиновның йортын туздырып, аның нәрсәләрен талаганнары өчен гаепләнәләр»: *(Хәбиб Хәкимов. Чехлар заманында. Чистай типографиясе, 1919 ел).* Автор Гаяз Садыйковның: «Моннан без Шәйхи доносы белән бу көнгә төшүебезне аңладык»,—дигән сүзләрен китерә.

Бу биш кешене (башка авыллардан тагын бишәүне) баржага төяп алып китәләр һәм Кама уртасына алып чыгып, кулларын артка каерып тимер чыбыклар белән бәйләп баржа кырыена бастыралар да, берәм- берәм сугып төшерәләр. Шуларның берсе генә—Гаяз Садыйков исән кала. Ул

тимерчыбыктан кулларын ычкындырып яр кырыена йөзеп чыга ала. Төрле авылларда качып ятканнан соң, бик күп михнәтләр күреп, Яүширмәгә кайтып җиткәч (гаскәр авылдан киткән була инде) авылдашларын харап иткән Шәйхине эзләп бара. Яүширмә халкы бу вакыйганы болай искә төшерә: Гаяз Садыйков берничә иптәше белән Шәйхиләргә килеп керә. Шәйхине, өйдә юк, диләр. Берсенең күзе Шәйхинең әнисе менеп утырган сандыкка төшә. Әбине төшереп, сандыкны ачып карасалар— Шәйхи ята. Җилтерәтеп торгызып урамга алып чыгып, Гаяз аны атып үтерә.

Озак еллар буена донослары белән Гаяз Исхакыйга, туганнарына, авыл халкына күп җәфалар китергән Шәйхи куштанның язмышы әнә шулай тәгәлләнә.

*...күрше авылларга барырга рөхсәт булды*—Г. Исхакыйның Кызыл яр авылына баруы турындагы доноста: «Крәстияннәрне үзен Думага сайларга үгетли. Монда үткәрсәләр, алда аны үзләренең ниндидер партияләре дә сайлаячак. Әгәр алар партиясеннән депутатлар сайланмаса, түрәләр халыкны алдаячак, берни дә бирмәячәк, ди. Крәстияннәрдән ниндидер приговорга кул куйдыра» диелә. *(ТМА, 51 ф.,*6 тасв., 916 эш, *7* к.)

*«Тәрбиятел-әтфаль»*—Мәскәүдә «унбиш көндә бер чыга торган, сабак балаларына махсус әдәби, фәнни һәм рәсемле мәҗәллә»; 1907 елның 1 гыйнварыннан 1 мартка кадәр барлыгы 5 сан чыгып кала.

*Заһид әфәнде Шамил* — Заһид Мөхәммәд-Шәфикъ улы Шамил 1868—1920). Дагыстан халыкларының патша колонизаторларына каршы бәйсезлек көрәшенә җитәкчелек иткән Шәех Шамилнең (1997 елда тууына 200 ел тулды) оныгы. Калугада һәм Истанбулда белем алган. Заһидның әтисе Мөхәммәд Шәфикъ (?—1906) патша хөкүмәтенә хезмәт итеп, генерал дәрәҗәсендә отставкага чыга һәм Казанга килеп сәүдәгәр Ибраһим Апаковның кызы Мәрьямгә өйләнә. Заһид аларда 1900 елга кадәр тора да Мәскәүгә күчә,

Мәскәүдә ул Касыйм татарларыннан Хөсәен хаҗи Байбеков кызына өйләнә. Хәзерге көндә Казан шәһәрендә Тукай урамында Габдулла Тукай музее Апаковлар салдырган, халыкта «Шамил йорты» дип йөртелгән йортка урнашкан.

*Дамелла Нәҗип* (1859 1921) — мәгърифәтче, тарихчы, дин әһеле Хөсәен Әмирханның улы. Фатыйх Әмирханның әтисе Мөхәммәдзирифның бертуган энесе. Чистайда хәзерге Вахитов урамындагы мәчет имамы. Мактап, мәдрәсәләр тоткан. Алдынгы карашлы, хөр күңелле Нәҗип дамелла 1893 елдан алып бервзлексез полиция күзәтүе астында яшәгән.

*... мөселманнарның кадетлар белән блок ясауларыннан...* Кадет патша Россиясендә либераль-монархистик буржуазия интересларын чагылдырган конституцнон-демократик партия әгъзасы. «1906 ел башында I думага сайлаулар вакытында Чистай карагруһчылары выборщнклыкка гына булса да үз вәкилләрен үткәрергә омтылалар. Тик мөселманнар арасында зур абруйга ия булган, киң радикаль карашлы Нәҗип хәзрәт» карагруһчыларның юлын кисү өчен, Чистайда һәм өяздә мөселманнарның кадетлар белән блокка керүен куәтли. Блок җиңеп чыга, I Думага күбрәк кадетлар үтә». (Равил Әмирхан — Чистайлы Әмирханнар. Татарстан. 1996, 2 нче сан, 67 бит.)

*Мәхмуд Уразгильдиев* — Чистай сәүдәгәре, карагруһчы.

*Зәңгәр Сәлах* — Сәлахетдин Габделваһапов, карагруһчы.

*Дамелла белән Гариф абзыйны япкач, мин Ч ис тайга килдем.* — Архивта Чистай төрмәсендә Гаяз Исхакыйдан сорау алу турындагы документта Г. Исхакый үзеннән алдарак аның өстеннән шаһитлек иткән кешеләрнең сүзләрен кире кага. Мәсәлән, ул Шәйхи куштанның, Гаязны 26 декабрьдә Чистайда Назимов трактирында очраттым, дигән сүзләренә каршы болай ди:

«Мин Чистайга пристав рөхсәте белән ике тапкыр килдем. Берсендә 25еннән 28 ноябрьгә кадәр, икенчесендә 18еннән 20 декабрьгә кадәр тордым... 23 еннән 24 каршы төндә Яүширмәдә кулга алындым. Өч тәүлек Чистайда полициядә тоттылар, ә 27 декабрьдә Чистай төрмәсенә яптылар». *(ТМА, 51 ф., тасв., 916* эш, *20 к.)*

*Йосыф та тугрылык өчен зинданда яткан* — кол итеп Мисыр шәһәренә китерелгән Йосыфны патшаның вәзире уллыкка ала. Вәзирнең хатыны Зөләйха Йосыфны күреп, эзләгән егете икәнлеген таный. Хисләрен яшерә алмый. Әмма Йосыф гөнаһтан ерак булуны мәгкуль күрә. Моңа Зөләйханың ачуы килә һәм аны зинданга яптырып куя. Г. Исхакый шушы ривайәткә ишарә итә.

*Муса тугрылык өчен үзенең туган-үскән җиреннән качкан* — Мисыр патшасы—фиргавен Алланың берлегенә ышанырга өндәргә килгән Муса пәйгамбәргә каршы көрәшә. Аны үзенә ышанган халкы белән бергә туган иленнән китәргә мәҗбүр итә. Г. Исхакый шушы ривайәткә ишарә итә.

*Морозов Николай Александрович* (1854—1946)—революционер, галим һәм язучы.

*Вера Фигнер* (1852—1942)—революционерка.

*Сазонов* Егор Сергеевич (1879—1910)—революционер, эсер.

*Каляев Иван Платонович* (1877—1905)—революционер, эсер.

*Чарныш Мәхмүди*—Чистай сәүдәгәре, доносчы.

*Учитель Мирсәет* Юнысов—рус теле укытучысы, доносчы.

*...сеңелләрем...*— Гайнелмәрзия (1882—1965), Фәридәбану (1891— 1961), Хәлимәбану (1893—1978). Алар өчесе дә авыл кызларын өйләренә китереп укытканнар. Кызларның уртанчысын — Фәридәбануны бик яшьли 54 яшьлек сәүдәгәргә Сәйфетдингә кияүгә бирәләр. Сәйфетдиннең Яүширмә авылы уртасында, ул чагында авылда бердәнбер, ике катлы таш йорты була. Ул анда бик бай кибет тә тоткан. Хәзерге көндә шул таш йорт Г. Исхакыйның музее итеп реконструкцияләнә.

*...Думага бармакчы буласыңмы?* — сүз II Дәүләт Думасы хакында бара. II Дума 1907 елның 20 февраленнән 2 июненә кадәр эшли.

*...рождество бәйрәмнәре*—христаннарның Иисус Христос туу истәлегенә 7 гыйнварда үткәрелә торган бәйрәмнәре.

*Толстой Лев Николаевич* (1828—1910)—рус язучысы.

*...129 нчы статья белән гаепләп төрмәгә яптылар.*— Бик тырышып җыелган досье нигезендә Чистай өязе исправнигы Илевский карар чыгара: Җинаятьләр турындагы законнар Җыелмасының 129 нчы статьясына туры килгән җинаяте (хөкүмәткә каршы җинаять) өчен Г. Исхакыйны Чистай төрмәсенә ябарга (ТМА, 51 ф., 6 тасв., 916 эш, 11 к.). Шул ук көнне исправник Казан губернаторына мондый хәбәр җибәрә: «Самар губернасы Бөгелмә өязе Карамалы волосте Лашман авылы крәстияне Мөхәммәдгаяз Исхаковка (28 яшендә) кагылышы булган язмаларны җибәрү уңаеннан Сез Галиҗанәбкә шуны да хәбәр итәм: үзем җитәкләгән идарәдә **агентлардан җыелган, дөреслеге шиксез булган мәгълүматларга караганда,** әлеге телгә алынган Исхаков социалист-революционерлар партиясе әһеле, Чистай өязе Кызыл Яр волосте Кутлушкино (Яүширмә) авылында, үзенең атасы йортында яшәп ята. Ул хөкүмәткә каршы җина ятчел пропаганда алып бара—әле телгә алынган

волостьтагы мөселманнарны хөкүмәттә үзгәрешләр үткәрергә, социалист-революционерлар партиясенең җирле вәкиле сыйфатында үзен Дәүләт Думасына сайларга агитация алып бара.

Сак астында тоту максаты белән 1906 елның 27 декабрендә Исхаковны, Җинаять Эшләре Җыелмасының 126, 130 статьяларына таянып, Чистай төрмәсенә ябып куйдык». *(ТМА, 199 ф., 1 тасв., 538 эш, 8 к.)*

*Бәди карчык нумирлары* — автор төрмә бүлмәсен Казанда кунып чыгар урыны булмаганнар өчен гомуми сәке биреп торучы хуҗаларның йортлары белән чагыштыра.

*Герасимов* — I Дәүләт Думасы әгъзасы.

*...җир эшләре берлән кергән авыл халыклары...*— архивта Чистай өязе волостьларындагы крәстиән чуалышлары турында байтак материал бар.

Бу елларда волостьлардагы хәлләр турында аена 12 сум хезмәт хакы бәрәбәренә жандармериягә донослар язып торучылар «Казанец» һәм «Перс» исемнәре астына яшеренеп эш итәләр. Бик күп крестиәннәр шул донослар нигезендә төрмәгә ябылалар. (ТМА, 199 ф.,1тасв.,589 эш.)

*Мамыйк* («Мамыково) Татарстанның хәзерге Октябрь районына кергән рус авылы. Чистайдан 90 чакрым ераклыкта.

*... үземнең якыннарыма күрешергә рәхсәт сорап жандармскийга телеграмм биргән иде.* —Телеграммны Г. Исхакый 1906 елның 28 декабрьдә җибәрә: «Казан жандарм идарәсенә Туганнарым белән күрешергә рөхсәт биргүгезне сорыйм. Тоткын Исхаков». Чистай исправнигына Казан губернасы идарәсе начальнигы полковник Калининнан телеграмма килә. «Тоткын Исхаковка хәбәр итегез. Безнең тарафтан аңа туганнары белән күрешергә рөхсәт ителде». *(ТМА,* 199 *ф.,1* тасв., *538 эш, 3. 4 к.к.)*

*Корбан гаете* — мөселманнарның дини бәйрәме. Бәйрәм Зөлхиҗҗә аеның (һиҗри елның 12 нче ае) 9—13 нче көннәрендә уздырыла. Корбан чалуның да үз тарихы булган. Ривайәтләргә караганда, Ибраһим пәйгамбәр Аллаһе Тәгаләгә чиксез бирелгәнлек билгесе итеп үзенең улы Исмәгыйльне корбан итәргә әзер булуын белдергән. Ләкин Алла кодрәте белән аның алдына корбанга сарык килеп баскан. Бу вакыйга Коръәннең 37 нче сүрәсендә (97—110) һәм хәдисләрдә тасвирлана. Корбан өчен сарык, кәҗә, сыер һәм дөя кебек пар тояклы хайваннар тәкъдим ителә. Бер генә тояклы булганга, ат рөхсәт ителми.

*Фуад* (Мәхмүдфуад Фәсах улы Туктар, 1880—1938)—публицист, педагог, сәясәтче. Г. Исхакыйның көрәштәше. 1919 елның ахырында Исхакыйлар белән бергә чит илгә чыгып китә. Анда укытучылык эше белән шөгыльләнә. Ф. Туктар үлгәч, Г. Исхакый үзе чыгарган «Яңа милли юл» журналында аның тормыш юлы турында «Солых һәйәте әгъзасы Фуад бәк Туктар вафат» исемле мәкаләсен бастыра (Яңа милли юл. 1939, 2, 3 саннар).

*Кунучев* Иван — революционер, кадет.

*Дерагин* — Чистайда врач, кадет.

*Димрат* — революционер, кадет.

*Якубович* — генерал, карагруһчы.

*Октябристлар* — патша Россиясендә помещиклар һәм сәүдә-промышленность буржуазиясе партиясе («17 октябрь союзы») әгъзалары.

*Минем дә правам кайтарылса, сайлануымда шөбһә юк иде.*— Архивта

«Срочно!» килгән кисәтү һәм «1907 ел, 21 февраль» дип язылган документта Казан округ судының Чистай өязе 1 нче бүлек суд тикшерүчесе Чистай земский идарәсенә мөрәҗәгать итеп, Гаяз Исхакыйга үзен Икенче Дәүләт думасына сайлаучы вәкилләр ( выборщиклар) сайлау хокукы бирелгәнме? — дип сорый *( 51 ф., 6 тасф., 916 эш, 26 к.)* . Бу сорауга җавап Икенче Дәүләт Думасына сайлау эшләре буенча Чистай өязе комиссиясе җавап бирә: "Өяз комиссиясе Сез Галиҗәнабкә шуны белдерә: Самар губернасы крәстияне , Кызыл Яр волосте, Кутлушкино (Яүширмә) авылының элеккеге мулласы Мөхәммәдгаяз Исхаковка Чистай өязе буенча Икенче Дәүләт Думасына сайлаучыларны (выборщикларны)сайлау хокукы бирелмәде. *(Шунда ук, 27 к.)*

*... гаепсез кешене ябып, кырык көннән соң гаепсез дип чыгарып җибәрүне безнең гакыл аңлашмый. Безнең мантыйк сыйдырмый иде.* — Бу сүзләр Г. Исхакыйның төрмәгә ябылу сәбәпләре турында йомгак ясавы кебек аңлашыла.

Ә документларда Г.Исхакый «Эш»енә йомгак ясау түбәндәгечә бара. Г. Исхакый бөтен нәрсәнең юри, вакытны сузар өчен генә эшләнгәнем аңласа да, үзе ягыннан Яүширмадән, Чистайдан шаһитларны чакыртуларын сорап ике тапкыр мөрәҗәгать ите. 1907 елның 6 гыйнварында ул мондый үтенеч яза: «Чистай өязе 1 нче участок суд тикшерүчесенә, Чистай төрмәсендәге сәяси тоткын Мөхәммәдгаяз Гыйләҗетдинов Исхаковтан. Яүширмә авылы крәстияннәре Шәйхетдин Җамалетдинов һәм Сәхәбетдин Габитовларның ялган донослары аркасында мин Җинаять эшләре Җыелмасының 129 статьясы буенча хөкемгә тартылдым. Җамалетдяновның ялган донослары миңа шәхси үчлегенә нигезләнә. Җамалетдиновның туганы мәчеттә азанчы булырга теләгән иде. Әхлаксызлыгы, сәләтсезлеге өчен мнн бу эшкә каршы килдем. Җамалетдинов коткысы белән шаһитлык иткән Сәхәбетдин Габитов исә өяз исправнигы Илевский әфәнде сорау алганда 1 стан приставына әйтеп яздырган сүзләреннән бөтенләй баш тарткан һәм приставка берни дә сөйләмәдем дип белдергән. Моны исправник Илевский үзе, шулай ук аның сорау алу

вакытында шунда булган хатыны һәм Яүширмә авылы крәстияне Шәфигъ Хәсәновраслый алалар. Миңа тагылган гаепләүнең уйдырмалардан укмаштырылган булуын минем яктан шаһитлар Шәрәфетдин Хәмитов һәм Гата Бәдыйгин(Яүширмәдә яшиләр) раслый алалар.

Сез Галиҗанәбтан минем эшем буенча тикшерү барышында мин күрсәткән шаһитларны — исправник Илевский белән аның хатынын, Шәфикъ Хәсәнов белән Шәрәфетдин Хәмитов һәм Гата Бәдыйгинны чакырып сорау алуыгызны үтенәм. Мөхәммәдгаяз Исхаков» *(51 ф.. 6 тасв., 916 эш, 24 к.)*

Чистай төрмә начальнигы Г. Исхакыйның бу үтенеченә 1 айдан соң гына —1907 елның 7 февралендә генә кул куя, һәм Казан округ судының Чистай участогы прокурор ярдәмчесе исә суд тикшерүчесенә үтенечне 12 февральдә тапшыра. *(Шунда ук, 23, 24 к.к.)*

1907 елның 14 февралендә суд тикшерүчесе Гаяз Исхакыйдан сорау ала. 5 биткә сузылган беркетмәдә Г. Исхакый тагын үзенең үтенечен кабатлый: «...исправник Илевскийның хатынын да чакыртуыгызны үтенәм. Миңа әйтүләренчә, ул Сәхәбетдин Габитовтан сорау алу вакытында шунда булган һәм ул, кешеләрне кемнәрнеңдер ялганнардан укмаштырылган донослары буенча кулга алалар, дип ачуланган. Исправник аны тынычландырып: «Исхаковны Дәүләт Думасына сайлаулар үткәч чыгарырлар мөгаен», дигән. *(51 ф., 6 тасв., 916 эш, 21 к.)*

Суд тикшерүчесе 1907 елның 14 февралендә, Г. Исхакыйдан сорау алган көнне мондый карар чыгара: «1907 елның 14 февралендә Казан округ судының Чистай өязе, 1 нче участок суд тикшерүчесе Вазыйфаларын башкаручы Самара губернасы, Кызыл Яр волосте, Чистай өязе, Кутлушкино (Яүширмә) авылының элеккеге мулласы Гаяз Исхаковның Җинаять эшләре Җыелмасының 126 һәм 129 статьяларына туры килә торган җинаять эшчәнлеген карап һәм 1) «Эш»тә Гаяз Исхакыйны югарыда аталган статьялар буенча хөкем итәрлек гаепләрнең җитәрлек булмавын, 2) бу «Эш» буенча тагын берничә шаһиттан сорау алырга кирәклеген (а бу шактый озак вакыт таләп итә), 3) Исхаковның суд тикшерүләреннән качу ихтималы юклыгын, 4)

һәм шулай ук Исхаковның Яүширмә авылында ата-анасы, хатыны һәм баласы калганлыгын исәпкә алып, карар бирә: Гаяз Исхаковны хөзер үк сак астыннан азат итәргә.Бу турыда Чистай өяз төрмәсенә хәбәр җиткерергә. *(ТМА, 51 ф.,*6 тасв., 916 эш, 22 к.)

Бу карар Казан губернаторына да җибәрелә һәм губернатордан килгән боерык нигезендә 1907 елның 17 февралендә Г. Исхакый Чистай төрмәсеннән азат ителә: «Минем карамактагы төрмәдә тотылучы Гаяз Исхаков Казан губернаторының 17 февральдә 115 нумир белән җибәргән телеграммасы нигезендә минем тарафтан шул ук көнне азат ителде. Төрмә начальнигы». *(Шунда ук, 25 к.)*

Ләкин эш моның белән генә бетми, Г. Исхакыйның «җинаять эше» ябылмый тора. Г. Исхакый атаган шаһитларны суд тикшерүчесе үтенеч язылганга 1 ай да 22 көн үткәч кенә, Думага да сайлаулар узгач кына үзенә чакыртып сорау ала. 28 февральдә 7 кеше,6 мартка 6 кеше чакырыла. Түбәндә кайбер шаһитларның сүзләрен китерәбез.

Миннабетдин Хөснетдинов: «Шәйхетдин Җамалетдинов миңа: «Гаяз Исхаковны Дәүләт Думасына сайлатмаска һәм төрмәгә яптырырга кирәк. Аңа каршы минем бер шаһитым бар инде, тагын берәү кирәк. Менә син бәлки аңа каршы берәр нәрсә әйтерсе»», диде. Мин аңа: «Андый нәрсә эшләргә ярамый», дип, баш тарттым». *(24 февр. 1907, ТМА, 51 ф..*6 тасв., 916 эш, 31 к.)

Сәяр Йосыпов: «Шәйхетдин Җамалетдинов бездә бик әшәке кеше исәпләнә, ул «куштан». Ул авылга мулла итеп башка кешене сайлатмакчы иде, ә авыл халкы Гаяз Исхаковның мулла булуын теләде, Гаязның әтисе дә бездә 30 ел мулла булып торды. Шул вакыттан Шәйхи Гаязга үчле. Ул миннән Гаязга каршы донос бирергә сорады, мин, «бу эш — гөнаһ», дип, баш тарттым». *(28 февр. 1907, шунда ук, 51 ф.. 6 тасв., 916 эш, 34 к,)*

Шакир Сафин: «Шәйхетдин Җамалетдинов Гаязның мулла булып сайлануын теләмәде. Чөнки Гаяз халыкны гел яклый, ә Шәйхетдин кешеләрне бик рәнҗетә иде. Ул «куштан», бик әшәке кеше, халык Шәйхетдинне авылдан сөрү өчен приговор җыярга тели. Шәйхетдин бөтен эшләрдә һәрвакыт ялган

шаһитлык итә». *(28 февр. 1907, шунда ук, 51 ф., 6 тасв., 916 эш, 35 к.)*

Шәрәфетдин Хәмитов: «Гаяз Шәйхетдин әләге белән казематка эләкте. Безнең Гаяз бик әйбәт кеше. Шәйхетдин исә әләкче, әшәке кеше булып санала». *(28 февр. 1907, шунда ук, 36 к.)*

Шәрәфетдин Кәбиров: «Бервакытны Шәйхетдин Җамалетдинов фәхешханәдән бер хатынны өенә алып кайтып, аның берлән никахсыз гына тора башлады. Картлар бу хәлгә ризасызлык белдереп, узебезнең указлы муллабыз Гаяз Исхаковка бардылар. Гаяз Шәйхетдинне ул фахишәне авылдан җибәрергә мәҗбүр итте. Шуннан соң инде Шәйхетдин, үч итеп, гел Гаяз өстеннән әләкләп торды. Шәйхетдинне бездә беркем яратмый, ул һәркемне рәнҗетә. Гаязны исә барысы да ярата, чөнки ул яхшы кеше». *(6 март, 1907, шунда ук, 36 к.)*

Гата Бәдыйгин: «Узган елның декабрь аенда беркөнне үземнең капка төбендә утыра идем. Шәйхетдин Җамалетдинов та минем янга килеп утырды да Гаяз Исхакыйга каршы сүз сөйләргә үгетләргә тотынды. Мин: «Нәрсә сөйләргә кирәк соң?» дигәч, «Патшаны аты-юлы белән сүкте, патша тиздән төшерелер, байларның җирләрен крәстияннәргә бирерләр» дип әйтте диярсең, диде. «Мин кеше җанын кыя алмыйм», дип, баш тарттым. Шәйхетдин мине үгетләвен дәвам итте, «мин сиңа чәйгә ун сум бирермен», дип вәгъдә итте. Мин риза булмадым. Шәйхетдин күптәннән инде Гаязны күрәлмый, ул бездә куштан, мироед, Гаяз аңа халыкны рәнҗетергә бирми иде.

Өстәп шуны әйтәм, минем яннан киткәндә Шәйхетдин бу сөйләшүне беркемгә дә әйтмәскә кушты. Ләкин мин кемгәдер сөйләгән идем. Шуны Гаяз Исхаков ишеткән дә мине чакырып: «Шәйхетдиннең сине үгетләве дөрестме?»—дип сорады. Мин расладым һәм әгәр дә миннән сорасалар, ничек булган — шулай сөйләячәкмен, дидем». *(28 февр., 1907, шунда ук, 35 к,)*

Сәхәбетдин Хөснетдинов: «Мин 24 нче ел инде Яүширмәдә мөәзин булып торам. Гаяз Исхаков указлы мулла булып бездә бер ел гына эшләде. Ул үз теләге белән түгел, ә этисе Гыйләҗетдин Исхаковның теләге белән мулла итеп куелган иде. Гаяз үзенең вазыйфаларына салкын карады, мәчеттә бер 10 мәртәбә генә имам торып намаз укытты. Ул һаман өяз буенча һәм Казанга

йөрде. 17 октябрь манифесты чыккач, авыллар буенча шуны аңлатып йөрде. Шәйхетдингә мин беркайчан да Гаяз патшага каршы котырта дип әйткәнем юк. Эш болай булды: авылда безнең элекке указлы мулла Гыйлаҗетдиннең кияве имам Вафа Мәх-мүтовны Шәйхетдин әләге белән пристав алып китәргә килә икән дигән сүз таралды. Гыйләҗетдин карт мәчеттә, Вафаны полициягә бирмәгез, пристав янына тиз генә халыкны җыегыз, дип, картларга мөрәҗәгать итте. Мин Шәйхетдингә шуны гына әйткән идем. Безнең авылда Шәйхетдинне чыннан да беркем дә яратмый». *(6 март, 1907 ел, шунда ук, 36—37* к)

Шаһитлардан сорау алган көнне, 1907 елның 6 мартында Чистай өязе суд тикшерүчесе түбәндәге карарны чыгара: «...бу тикшерү эшен карап һәм Кызыл Яр волосте, Яүширмә авылының элекке мулласы, Самара губернасы крәстияне Мөхәммәдгаяз Исхаковны Җинаять эшләре Җыелмасының 126 һәм 129 статьялары буенча **гаепләүнең бары тик Яүширмә авылы крәстияне Шәйхетдин Җамалетдинов биргән мәгълүматларга гына нигезләнгән** булуын һәм ул мәгълүматларның берничә шаһит тарафыннан кире кагылуын, Шәйхетдин Җамалетдиновның Гаяз Исхаковка карата үч тотып, аңа каршы ялган шаһитлек итүен тикшереп аныклаганнан соң карар бирә: Мөхәммәдгаяз Исхаковны гаепләү өчен җинаять билгеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, бу «Эш»не Чистай участогы прокурор ярдәмчесенә җибәрергә һәм Казан округ судыннан «Эш»не туктатуны сорарга». *(Шунда ук, 40 к.)*

Ниһаять, 1907 елның 4 маенда Казан Суд палатасы да үзенең карарын игълан итә: «...Суд палатасы Җинаять эшләре Җыелмасының 126 һәм 129 статьялары буенча гаепләнүче Мөхәммәд Гаяз Исхаковка карата кузгатылган җинаять эшен тикшерү барышында аны гаепләрлек җинаять билгеләре җитәрлек булмавын исәпкә алып, шулай ук Чистай суд тикшерүчесенең 1907 елның 6 мартында чыгарган карары белән һәм Прокурор ярдәмчесе ясаган нәтиҗәләр белән килешеп карар итә: Җинаять эшләре Җыелмасының 126, 129 статьялары буенча гаепләнүче Мөхәммәд Гаяз Исхаковка карата кузгатылган тикшерү эшен җинаять билгеләре җитәрлек булмау сәбәпле туктатырга». *(Шунда ук, 42 к.)*

*...бүген язарга тагы яңа эш чыкты* — сүз Г. Исхакыйның «Корбан гаете» исемле хикәясен язу турында бара.

*Думада сулларның бик куәтле булачагы...—1905 елның 11 декабрь* законы буенча уздырылган сайлауларда I Дәүләт Думасындагы депутатларның 43% крәстиәннәрдән тора. Алар җир таләп итәләр. Патша хөкүмәте моңа эре җирбиләүчелекнең кагылгысызлыгы турында белдерү, 1906 елның 27 апрелендә ачылган I Дәүләт Думасын шул ук елның 8 июлендә куып тарату белән җавап бирә.

II Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан Сенат Дәүләт Думасына сайлаулар турындагы 1905 елның 11 декабрь законына аңлатмаларын игълан итә. Алар буенча эшче, крәстиян һәм рус булмаган милләтләрнең яңа төркемнәре сайлау хокукыннан мәхрүм ителә.

Шулай булуга карамастан, II Дәүләт Думасына суллардан шактый күп депутат сайлана. «Тәрбиятел-әтфаль» гәзитәсенең 1907 ел, 15 февраль санында Думага сайланучыларның төрле төркемнәре исемлеге китерелә, шулар арасында мөселманнардан 25 депутатның исемлеге дә бар. Гәзитәдә: «Әлхасыйль, бу Думада суллар әүвәлге Думадагыдан күбрәк булып, хакыйкатен хөкүмәткә мохалиф (каршы) тора торган исемене алырга муафикъ буласыдыр», диелә.

Әмма 1907 елның 20 февралендә ачылган II Дәүләт Думасы да шул ук елның 2 нче июнендә куып таратыла.

*...10 нчы февральдә миңа егерме тугыз тулганга...*—Татарстан Милли архивында саклана торган Казан губернасы Чистай өязе буенча туу, никахлашу, үлү турындагы метрика кенәгәләре Коллекциясенең 1878 елгы 1 нче томында, 20 нче нумирлы кенәгәдә мондый юллар язылган: «Туган көне—10 февраль. Исеме—Мөхәммәдгаяз. Атасы—имам Гыйләҗетдин Исхак угылы, анасы—Камәрия. Исем куйды—мулла Гыйләҗетдин ибн Исхак». 1878

елда Яүширмәдә гыйнвар аенда 10, февральдә 7 бала дөньяга килгән, Гаяз февраль аенда туучылардан икенче булып язылган. Метрикә кенәгәсендә теркәүләр тәмамлангач, «Имам Гыйләҗетдин кулым куйдым», диелгән.

Г. Исхакый үзе «Тәрҗемәи хәлем» кулъязмасында: «Мин 1878 елның иске стиль белән февральнең 10 ында (яңа стильдә 23 февраль)* җомга көн кояш чыкканда Яүширмә авылында дөньяга килгәнмен»,—дип яза. «...Мөхәррир мин дә голяма зөмрәсеннән йитмешмен вә беренче милли аңны бу мохиттан алганмын. Атам Яүширмә авылында Гыйләҗетдин хәзрәттер. Аның атасы Исхак хәзрәт тә имамдыр, аның атасы Хәмзә хәзрәт вә аның атасы Сөбханколый хәзрәт тә вә аның атасы Бакый хәзрәт тә имамнардыр», ди. (Бакый►Сөбханколый►Хәмзә-►Исхак►Г ыйләҗетдин ► Мөхәммәдгаяз.)

Гаяз—Гыйләҗетдин белән Камәриянең беренче ике балалары яшьли үлеп киткәннән соң туган өченче бала.

Г. Исхакый үзе язганча, беренче дәресне ул биш яшендә әбисе остазбикә Мөхфүзәдән ала. Корънәннең бер өлеше булган «Һәфтияк»не укырга өйрәнә. Аннан соң укуын әтисе Гыйләҗетдин хәзрәт дәресләрендә дәвам итә. «Иман шарты»ннан соң шигырь белән язылган, һәр мисрагы «Аллаһ дигән бәдәвам» җөмләсе белән беткәнгә, «Бәдәвам» исемен алган китапны, Суфи Аллаһиярның «Сөбателгаҗизин» китабын (шигырь белән), «Рәүнәкыл ислам» китапларын укыдым... Кулыма эләккән һәрбер төркичә китапны укый башладым. ...Гарәпчәдән «Кырык хәдис», «Әрбаб», «Тәгаллеме-ссалават», «Төхфәтелмөлек», «Мөхтасарел викая» китапларын укыдым. Фарсычадан ике хикәя ... укыдым. Моннан соң гарәп хәрефенә кердем. «Тәгъриф» исемендә бер китап укып чыктым һәм аннан соң ... нәхү китапларын укыдым. Бу дәресләрне әтием Гыйләҗетдин хәзрәттән укыдым. Әтием гарәпчәгә кадәр фарсычага оста булганы хәлдә, Сәйф Сарайның «Гөлстан»ыннан күп шигырьләрне яттан белсә дә, нидәндер фарсычага артык әһәмият бирмәдем һәм өйрәнгән фарсычам ярым- ямалак хәлдә калды.

Яшем уникегә җиткәндә әтием мине... Чистай шәһәрендәге... Закир хәзрәт мәдрәсәсенә күндерде.». Г. Исхакый туган өеннән чыгып киткәнгә

кадәр булган тормышын саран гына менә шулай тасвирлый.

*«Тавыш»*—«Таң йолдызы» ябылгач, аның дәвамы буларак, Казанда 1907 елның 25 маена кадәр Хөсәен Әбүзәрев редакторлыгында нибары 6 сан чыгып калган гәзитә. Гәзитәнең 1 нче санында ук Г. Исхакыйның ике мәкаләсе һәм бер хикәясе басылып чыга.

*«Казан мөхбире»*—Казанда чыккан беренче татар гәзитәсе *(29 окт. 1905—22 дек. 1911).*

*«Отпавший» исемле бер пьеса язарга хәзерләнә башладым... планын алып чыктылар.*— Шакир Мөхәммәдьяров болай яза: «Г. Исхакый Истанбулда 1905 еллардан бирле башында йөргән бер әсәрне яза башлаган. Бу әсәр—гасырлар буенча газиз диннәре өчен мужик үрәтниктән җәбер күреп килгән мөселман гаиләсен тасвир иткән дәһшәтле, авыр бер трагедиядер. Исеме «Отпавший»—«Мәкруһ», яһуд «Зөләйхадыр». Бу әсәрнең язмышы—эчендәге хәлләре кебек. Күптән язылган башы жандармнар кулында кала. Әсәр Петербургта язылып бетә». *(Гаяз әфәнде.— Вакыт. 1913, 2 май, 1190 сан.)*

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 1 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1998. Б. 273-328.
Текстны әзерләүче: Лена Гайнанова